МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№8-9 / октябрь 2012

...ХӘТӘР КИТӘ – ХӘТЕР КАЛА...

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ



Шәех Әхмәткә һәм аның туганнарына бирелгән Сәхибгәрәй хан ярлыгы. 1523 ел.
Татарстан Республикасы Милли музее фондларыннан

Журнал «Татмедиа» ААЖ
тарафыннан гамәлгә куелды.

Индекс 54132

Баш мөхәррир —
Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов
Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Иҗат төркеме:
Рамил Ханнанов
Илдус Заһидуллин
Диләрә Нәүрүзова
Дания Фәйзуллина
Ленар Гобәйдуллин
Ренат Миңнегалиев
Алия Мөбарәкшина

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Телефон: (843) 222-09-83 (17-90)
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Татмедиа» Матбугат һәм
массакүләм коммуникацияләр
агентлыгы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Заказ № М-1154.
Тираж — 2000 данә.
Формат 70 x 108 1/16
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды: 05.10.2012

МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№8-9 / октябрь

Эчтәлек

3 **Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов юлламасы (Өземтә)**

ТАРИХ

6 **Казан ханлыгының барлыкка килүе турында.** *Әнвәр Әхсанов*

12 **Күчмәннәр җәмгыятьләренең үзенчәлекләре.** *Николай Крадин белән әңгәмә. Илдус Заһидуллин*

24 **Казан Кремлендә ханнар төрбәсе.** *Фаяз Хуҗин, Айрат Ситдыйков*

40 **Казан — ханлык башкаласы.** *Айрат Ситдыйков*

50 **Сәхибгәрәй ханның Казан ярлыгына карата берничә фикер.** *Ильяс Мөстәкыймов*

56 **Казан ханлыгында төрки ислам мәдәнияте.** *Зәки Вәлиди Туган*

61 **Казан ханлыгының тышкы сәүдәсе.** *Шамил Мөхәммәдьяров*

68 **Алман тарихчылары Казан ханлыгының яулап алыну сәбәпләре һәм нәтиҗәләре турында.** *Марат Гатин*

76 **Мәскәү һәм Казан: дала дипломатиясе моделе турында кайбер гомуми фикерләр.** *Эдвард Кинан*

86 **Казан алыну сәбәпләре һәм нәтиҗәләре: XXI гасыр югарылыгыннан бәяләү.** *Илдус Заһидуллин*

100 **Габдерәшит Фәхреддиновның «Русия тарихы» дәреслеге (1919).** *Ленар Гобәйдуллин*

108 **Хәтәр китә — хәтер кала.** *Абдулла Дубин, Ленар Гобәйдуллин*

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.

Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.

Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Бу санда авторлар, А.Дубин, Л.Гобәйдуллин, Н.Гарифның шәхси архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

Тышлыкның 1 нче битендә — «Кол Шәриф шәкертләре белән» (фрагмент). *Н.Хаҗиәхмәтов рәсеме;*
4 нче биттә — Каеш аеллары. Скань, чүкеп ясалган. XIV г. Казань-Kazan: 1005-2005 (СПб., 2005) китабыннан.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Безнең журналга сез
54132
ИНДЕКСЫ
буенча һәр элемтә бүлегендә языла аласыз.

СӘНГАТЬ

115 **«Казан кыйссасы».** *Розалина Шаһиева*

ӘДӘБИЯТ

125 **Гаяз Исхакый: «...Кара көннәребезнең бетеп килгәненә, кояш тууының якынлашуына сөенә алабыз...»** *Гөлназ Хөснетдинова*
126 **Матәм көне.** *Гаяз Исхакый*
133 **И күңел...** *Кол Шәриф*
135 **Шагыйрь Кол Шәриф Хаҗи Тархани.** *Марсель Әхмәтҗанов*
138 **Шигырьләр.** *Кол Шәриф*
142 **Соңгы сугыш** (Бөек сәед Кол Шәриф турында тарихи эссе). *Дамир Исхаков*
148 **Казан ханлыгы чоры — милли әдәбият дәверенә капка** (XV йөзнең икенче яртысы — XVI йөзнең беренче яртысы). *Дания Заһидуллина*
151 **Синең кулда каләм...** *Мөдәррис Әгъләмов*
152 **Хакыйкать.** *Габдулла Буби*
159 **Хан мәчетендә.** *Гали Рәхим*
162 **Тукай энциклопедиясенә.** *Резеда Ганиева*
164 **Явыз Иванның ачы теле.** *Фәнзаман Баттал*
167 **Без исән!** *Айдар Хәлим*
168 **Йолдызлар төстән язганда...** *Рифә Рахман*
174 **Тыйнак холыклы, басынкы табигатьле...** *Лирон Хәмидуллин белән әңгәмә. Гөлзадә Бәйрәмова*
179 **Гъикаб.** *Мөхәммәт Әмин*

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

182 **Үз халкыңны үз итсәң, ят халыкка кол булмассың.** *Гүзәл Нәбиуллина, Лилия Гыйләҗева*
188 **Яңа китаплар.** *Илдус Заһидуллин*
191 **Тарих сәхифәләреннән**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ
Р.Н.МИҢНЕХАНОВНЫҢ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА

ЮЛЛАМАСЫ

(Өземтә)

[...]

Мәгълүмат киңлекләрендә сизелерлек үзгәрешләр бара. «Традицион» массакүләм мәгълүмат чараларына җитди конкурент һәм йогынтылы иҗтимагый көч буларак, электрон ресурслар һәм социаль челтәрләр барлыкка килде.

Безгә барыбызга да яңа шартларда эшләргә өйрәнергә кирәк. Шул ук вакытта социаль җаваплылык массакүләм мәгълүмат чараларының җитәкчеләренә, журналистлар корпусына төшә, аларның һөнәри һәм гражданлык позициясе әлеге мәгълүмат ташкынында кыйбла булырга тиеш.

[...]

Тарихи-мәдәни мирас елында без матди һәм рухи мәдәният ядкәрләрен саклап калу өчен байтак эш башкардык. Яңа музей комплекслары һәм торгызылган объектлар мөһим мәдәни һәм мәгърифәти үзәкләр булыр.

Тарихыбызга сакчыл карашны нинди дә булса бер акция яисә программа кысаларында формалаштырып булмавын билгеләп үтәргә кирәк. Бу бурыч — мәңгелек.

Без республикабызда яшәүче барлык халыкларның гореф-гадәтләрен хөрмәт итәбез. Хәзерге заман мәдәнияте күпкырлы. Нәкъ шуңа да кеше мөнәсәбәтләренең гомуми культурасын, милләтара аралашу осталыгын, сәяси культураны күтәрү мәсьәләсен алга куярга кирәк.

Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең уңай торышы, төрле этник төркемнәр һәм дин тотучылар вәкилләренең үзара тату хезмәттәшлек рухы, һичшиксез, безнең казанышыбыз булды һәм шулай булып кала да.

Идел Болгарстанының Ислам динен кабул итүенә, Казан Мәрьям Ана Иконасын данлауга багышланган чаралар, мәдәни ядкәрләрне торгызу буенча киң колачлы эшчәнлек безнең бай мирасыбызга ихтирамлы карашны һәм Россия Федерациясе мәдәниятен, рухи байлыкларын саклауга һәм үстерүгә сизелерлек өлеш кертүне басым ясап күрсәтә.

[...]

2012 ел
Казан шәһәре

ТАРИХ

Ә тарих — чәч,
Тараламаган чәч ул,
Адәм төсле юып тарыйк кына,
Ачылачак аның күп серләре,
Укмаш төеннәре чишеләчәк...

Мөдәррис Әгъләмов

КАЗАН ХАНЛЫГЫ: ИҖТИМАГЫЙ ҺӘМ ХАЛЫКАРА МӨНӘСӘБӘТЛӘР, МӘДӘНИЯТ

КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ ТУРЫНДА

ӘНВӘР ӘКСАНОВ,
тарих фәннәре кандидаты, Төмән дәүләт университетының Гуманитар фәннәр институты өлкән укытучысы

Казан ханлыгы Олуг Мөхәммәд тарафыннан нигезләнгән дигән беренче фикерне А.И.Лызов, ә аннары П.И.Рычков, Н.М.Карамзин һәм Б.М.Соловьёв кебек галимнәр әйткән [1, б.68-69; 2, б.81; 3, б.273; 4, б.392]. Бу фикер «Казан тарихы»на нигезләнеп әйтелгән. В.В.Вельяминов-Зернов Воскресенск һәм Никон елъязмаларына күбрәк ышанган һәм галим ханлыкка 1445 елда Казанны яулап алган Олуг Мөхәммәднең улы Мәхмүд нигез салган, дигән фикерне әйтә [5, б.6-10]. М.Г.Худяков, тиешле чыганакларны күрсәтмичә генә, ханлыкка 1437-1438 елларда Олуг Мөхәммәд тарафыннан нигез салына, дип яза [6, б.22-25]. А.А.Зимин да шундый ук рәвештә фикер йөртә. Ул үз фикеренең дөреслеген В.В.Вельяминов-Зернов гипотезасы нигезен тәшкил иткән Воскресенск, Никон елъязмаларындагы һәм «Государева родословие»дәге мәгълүматлар соңрак язылганнар һәм баш-

1. Лызлов А.И. Скифская история. Ч. I. – СПб.: Типография Н.Новикова, 1776. – 166 с.
2. Рычков П.И. Опыт казанской истории древних и средних времён. СПб.: Императорская Академия наук, 1767. – 196 с.
3. Карамзин Н.М. История государства российского. Т.V. – СПб.: Типография Н.Греча, 1819. – 284 с.

ка тарихи чыганакларга каршы килә дип исбатлый [7, б.105]. Әмма А.А.Зимин һәм аңа ияреп язучылар XVI гасыр рәсми елъязмаларының нинди «башка чыганаклар» белән каршылыкка керүен төгәл күрсәтмиләр [8, б.34; 9, б.52-53].

Бу уңайдан Б.Л.Хәмидуллинның фикерләре аеруча игътибарга лаек. Ул «Казан тарихын»нан кала башка, XV-XVI гасырларга караган бер генә тарихи чыганакта да Олуг Мөхәммәд беренче Казан ханы итеп күрсәтелми, дип яза. Белгечнең фикеренчә, ышанычлырак чыганаклар булып Казанның беренче ханын — Олуг Мөхәммәднең улы, 1445 елда Казанны буйсындырган Мәхмүд икәнлеген хәбәр иткән шәҗәрә китаплары, Воскресенск һәм Никон елъязмалары тора [10, б.128-130; 11, б.56]. Д.А.Котлояров һәм А.Г.Бахтинның да фикер сөрешләре шул фикер белән тәңгәл килә [12, б.102; 13, б.140, 231].

Мәсьәләгә ачыклык кертер өчен, чыганаклардагы хәбәрләрне һәм аларның килеп чыгышын исәпкә алып, җентекләбрәк карыйк.

Иң беренче мәгълүматлар XV гасыр азагына караган «Мәскәү елъязмасы җыентыгы»нда, 1497 елгы «Елъязмалар җыентыгы»нда һәм Никонор, Ермолин, Симеон, Топограф, Тверь елъязмаларында саклаган.

Мәскәү елъязмачысы хәбәр итүенчә, 1437 елның көзендә тәхеттән куылган Урда ханы Олуг Мөхәммәд, эзәрлекләүдән качып, Белёв шәһәренә килә. Шул хәбәрне ишетеп, Василий II Белёв каласына «күпсандагы полклар» җибәрә, аларны күреп, Олуг Мөхәммәд «куркып кала... һәм рус кенәзләре сүзләренә буйсынырга итә». Ләкин воеводалар «патшаның сүзләренә колак салмыйлар», кирмән янында «көчле бәрелеш була һәм татарларны шәһәргә куып кертәләр». Икенче көнне Олуг Мөхәммәд алар белән янәдән килешергә тели, тәхеткә утыргач, «Рус җирләрен сакларга» һәм алардан салым җыймаска вәгъдә итә, вәгъдәсен раслап, үзенең улы Мәхмүдне һәм башка улларын воеводаларга әманәт итеп бирергә теләвен белдерә. Руслар бу тәкъдимнәргә күнмиләр, сугыш башлана, аларның полклары «беркем тарафыннан да куылмаган хәлдә», тетрәнә һәм кача башлый. Нәтиҗәдә, рус елъязмачысы сугыш хәлләрен: «Алласызларның аз гаскәре тарафыннан иксезчиксез күп булган христиан гаскәре кыйналды һәм кырылды. Аларның берсенә безнең гаскәрнең ун һәм аннан да артык кешесен җиңәргә туры килде», — дип тасвирлый. Елъязмачы тиңе булмаган җиңелүнең сәбәбен православ гаскәриләренең үзләренең дин кардәшләренә карата Белёвка барганда кылган күптөрле гөнаһларында күрә [14, б.260].

Шул елъязма мәгълүматлары буенча, 1439 елның июль аенда көтмәгәндә генә Олуг Мөхәммәд Мәскәүгә һөҗүм итә. Ул шәһәрне ала алмый, әмма «рус җирләренә зур зыян сала». 1444-1445 елның кышында Олуг Мөхәммәд иске Түбән Новгородка килә һәм аннан Муром каласына китә. Бөек кенәз

4. Соловьёв Б.М. Сочинения: В 18 кн.: Кн. 2. Т.3-4: История России с древнейших времён. — М.: Мысль, 1988. — 765 с.
5. Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. Ч.1. — СПб.: Типография Императорской Академии наук, 1863. — 558 с.
6. Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. — М.: ИНСАН, 1991. — 320 с., карт.
7. Зимин А.А. Витязь на распутье: Феодальная война в России XV в. — М.: Мысль, 1991. — 286 с.
8. Алишев Б.Х. Источники и историография города Казани. — Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2001. — 75 с.
9. Рахимзянов Б.Р. Касимовское ханство (1445-1552 гг.). Очерки истории. — Казань: Татар. кн. изд-во, 2009. — 207 с.
10. Хамидуллин Б.Л. Народы Казанского ханства: этносоциологическое исследование. — Казань: Тат. кн. изд-во, 2002. — 335 с.
11. Мухамедьяров Ш.Ф., Хамидуллин Б.Л. «Казанское взятие»: взгляд из XXI века // Исторические судьбы народов Поволжья и Приуралья. Сб. статей. Вып.1. Материалы всероссийской научно-практической конференции

гаскәренең якынлашуын белеп, хан Муромнан янәдән Түбән Новгородка китә, ә Василий II, татарларны Муром һәм Гороховец шәһәрләре янында җиңеп, Мәскәүгә кайтып китә. 1445 елның язында Олуг Мөхәммәднең уллары Мәхмүд һәм Якуб Суздаль каласы янында рус гаскәрләрен җиңәләр һәм Василий IIне әсир итәләр, Владимирга кадәр барып җитәләр, тик шәһәрне ала алмыйча, Муром аша Түбән Новгородка кайталар. 1445 елның 25 августында Олуг Мөхәммәд «үзенең балалары һәм бөтен Урдасы белән Түбән Новгородтан Курмышка килә, бөек кенәзне дә үзләре белән алып килә». Татарлар шул ук елның октябрендә, калым алып һәм тәре үптереп, Василий IIне азат итәләр, үзләренең күпсанлы илчеләре озатуында Мәскәүгә җибәрәләр. [14, б.260, 262-263, 394-365].

«Мәскәү елъязмасы җыентыгы» Олуг Мөхәммәднең аннан соңгы язмышы турында бернәрсә дә хәбәр итми. Ә 1447 елда болай дип хәбәр итә: «Казан патшасы Мәхмүд үзенең кенәзләрен бик зур көчләр белән Бөек кенәз вотчинасына, Владимирга, Муромга һәм башка шәһәрләргә яуга җибәрде. Моны ишетеп, Бөек кенәз аларга каршы яу җибәрде» [14, б.269]. Биредә Мәхмүднең «Казан патшасы» дип аталуы гына түгел, ә беренче тапкыр елъязмачының Казан тәхетен Олуг Мөхәммәд нәселе белән бәйләве игътибарны җәлеп итә. Әлегә кадәр хан Урдасының урнашкан урыны Белёв, Түбән Новгород, Муром һәм башка торак-пунктлар яннарында була, ә Казан белән бәйләп искә алынмый иде.

Моңа охшаш мәгълүматлар Ермолин, Никанор һәм Симеон елъязмаларында [15, б.149-152; 16, б.106-107, 109-110, 114; 17, б.188-190, 193-195, 203], 1947 елгы «Елъязмалар җыентыгы»нда [18, б.101-102] һәм кыскартылган рәвештә Тверь һәм Типограф елъязмаларында сакланып калган [19, стб.491; 20, б.183]. Шундый ук рухта диярлек бу вакыйгалар турында XVI гасыр елъязмалары да сөйли [21, стб. 69-70, 102, 104-106; 22, б.107, 111-114; 23, б.24-25; 30, б.63-66; 24, б.240-241, 256-259; 25, б.460, 463-464, 471; 26, б.192-193, 196-199, 207; 27, б.43-44; 28, б.180-181]. Алардан күренгәнчә, Олуг Мөхәммәднең замандашлары һәм якын дәвамчылары аны Казан ханы дип санамыйлар, ягъни рус елъязмачылары аңында ханның русларга каршы походлары казанлылар кылган гамәл дип чагылыш тапмый. Булган мәгълүматларга нигезләнеп, фәкать хан 1437 елда Сарай тәхетеннән төшерелә, аннан соңгы елларда, үзенең «йорты» булмаган хәлдә, рус шәһәрләрен яулап ала һәм аларда кышлый дигән фикергә килергә мөмкин.

Никон елъязмасы Олуг Мөхәммәд Олы Урдадан, Кече Мөхәммәд ханнан качып, Белёв шәһәренә килә һәм, руслар гаскәрен тар-мар иткәч, Түбән Новгородта төпләнә, шунда яши дип төгәлләштерә [22, б.64]. Ягъни, елъязмачы фикеренчә, Олуг Мөхәммәд 1437 елдан 1445 елга кадәр Түбән Новгородта

«Исторические судьбы народов Поволжья и Приуралья в XVI-XIX вв.», посвященной 80-летнему юбилею доктора исторических наук Б.Х.Алишева (г.Казань, 24 марта 2009 г.). — Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2010. — С.56-63.
12. Котляров Д.А. Московская Русь и народы Поволжья в XV-XVI вв.: У истоков национальной политики России. — Ижевск: Издательский дом «Удмуртский университет», 2005. — 314 с.
13. Бахтин А.Г. Образование Казанского и Касимовского ханств. —Йошкар-Ола: Марийский государственный университет, 2008. — 252 с.
14. Полное собрание русских летописей (далее — ПСРЛ) Т. 25. Московский летописный свод конца XV в. — М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1949. — 464 с.
15. ПСРЛ. Т. 23. Ермолинская летопись. — М.: Языки славянской культуры, 2004. — VI + V + 242 с.
16. ПСРЛ. Т.27. Никаноровская летопись. Сокращённые летописные своды конца XV в. — М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1962. — 418 с.
17. ПСРЛ. Т.18. Симеоновская летопись. — М.: Знак, 2007. — 328 с.

яши һәм шуннан башка рус җирләренә һөҗүмнәр оештыра. 1555 елга нисбәтле язмада Никон елъязмасы авторы, Урта Идел буенда православие таралу тарихына мөрәҗәгать итеп, Казан ханлыгы оешу турында да яза. Аныңча, 1445 елны Василий II не азат иткәннән соң, «патша Мәхмүд Курмыштан килеп Казанны ала һәм Казан кенәзе Азыяне үтерә, ә үзе Казан тәхетенә утыра» [23, б.251]. Тагын бер уникаль мәгълүмат Воскресенск елъязмасында сакланып калган. Аның авторы язуынча, 1445 елның көзеннән Мәхмүд, җирле кенәз Либейне [Алимбәк, Галимбәк] үтереп, Казанны яулап ала һәм «үзе патшалык итә башлый» [22, Б.114]. Шулай итеп, хәтта эчтәлеге ягыннан бер-берсенә охшаш булган елъязмалар да Мәхмүднең Казан тәхетенә утыруын төрлечә тасвирлаган.

«Казан тарихы» текстының башында автор рус елъязмаларында Казан ханлыгы нигезләнүе турында мәгълүмат тапмавы, ә менә «Казан елъязмалары»нда кайбер хәбәрләр барлыгын әйтеп үтә. Автор, информация эзләү максатыннан, «мәгълүматлы рус кешеләре»нә дә мөрәҗәгать итә, әмма алар, хакыйкатьне белмичә, төрлечә җавап бирәләр. Башкача әйткәндә, Россиядә XVI гасырның 60 нчы елларында ук Казан ханлыгы оешуы турында ачык һәм төгәл күзаллау булмаган. Мөгаен, «Казан тарихы»н язучы кеше Казан барлыкка килү турында ул вакытта иң киң таралган мәгълүматны гына китергәндер.

«Казан тарихы»нда Олуг Мөхәммәд ханның, 1437 елның декабрендә Белёв янында Василий IIнең 40 меңлек гаскәрен тар-мар итеп, руслар һөҗүмнәреннән соң бушап калган Казанга юнәлүе, анда яңа кирмән диварлары тергезүе һәм идарә итә башлавы турында мәгълүмат бар. Тора-бара шәһәргә Алтын Урдадан, Азовтан, Әстерханнан һәм Кырымнан «варварлар» агыла башлый, дип язылга.

Олуг Мөхәммәд күп генә рус шәһәрләрен һәм шул исәптән Мәскәүне дә камалышта калдыра. «Казан тарихы»ның авторы фикеренчә, аннан күргән бәлаказа, башка ханнар белән чагыштырганда, күпкә зуррак була. «Ул (Олуг Мөхәммәд) һәм аның төпчек улы Ягкуб Казанда үтерелә — икесе дә олы улы Мәхмүтәк тарафыннан пычак белән суела. Казанда 7 ел патшалык итә» [29, б.254-276].

18. ПСРЛ. Т.28. Летописный свод 1497 г., Летописный свод 1518 г. (Уваровская летопись). — М.: Наука, 1963. — 411 с.
19. ПСРЛ. Т.15. Летописный сборник, именуемый Тверской летописью. СПб.: В типографии Леонида Демиса, 1863. — 504 стб.
20. ПСРЛ. Т.24. Типографская летопись. — М.: Языки русской культуры, 2000. — XII + IV + 272 с.
21. ПСРЛ. Т.6. Софийская вторая летопись. Вып.2. — М.: Языки русской культуры, 2001. VIII + 446 стб.

1437 елгы Белёв сугышы. XVI гасыр азагына нисбәтле Сергий Радонежский кульязмасыннан

«Казан тарихы»ндагы Казан ханлыгын Олуг Мөхәммәд нигезләве һәм үзенең улы кулыннан һәлак булуы турындагы хәбәр — уникаль мәгълүмат. В.В.Вельяминов-Зернов һәм Н.П.Загоскин Мәхмүднең үз этисе Олуг Мөхәммәдне үтерүе турында язылган хикәяне дөрес дип кабул итәләр [5, б.11; 30, б.36-37], ә М.Г.Худяков моны «әкияти уйдырма» дип саный [6, б.34]. Л.Н.Гумилёв, бу мәгълүматтан чыгып, Касыйм ханның «үз этисен үтергән өчен үч алырга» ниятләгәнен яза. Аныңча, Касыйм һәм Мәхмүд арасындагы каршылыклар киләчәк вакыйгаларда да чагылыш таба: 1467 елны Касыйм Иван III ярдәме белән Мәхмүднең улы — яшь Казан ханы Ибраһимга каршы яу чыга [31, б.183]. А.Г.Бахтин: «Күп кенә татар ханнары ул вакытта «хакимият өчен барган көрәшләрдә һәлак булганнар», Олуг Мөхәммәдне көчләп сәяси аренадан чыгару кебек хәлләр Алтын Урда өчен гадәти күренеш булган», — дип фикер йөртә. Шуннан чыгып, тарихчы нәкъ менә Мәхмүд, 1445 елны этисе Олуг Мөхәммәдне үтергәннән соң, Казан ханлыгын нигезләгән дигән караштa тора [13, Б.135-140]. Ягъни галим, Никон һәм Воскресенск елъязмаларындагы мәгълүматларны «Казан тарихы» авторы хәбәр иткән вакыйгалар янәшәсенә куеп, үз карашын дәлилли.

Г.З.Кунцевич та Олуг Мөхәммәднең үтерелүе турында хәбәр соңрак Казан мулласы искә алуыннан кала, бернинди чыганаклар белән дә расламавын ассызыклый [32, б.251]. Биредә «Казан тарихы» авторының урта гасырлар әдәбиятында киң таралган читләтеп әйтү алымын еш кулланганын исәпкә алырга кирәк. Аның Сөембикә, Иван IVнең 1552 елда Казанга яу чабуы башка реминисценцияләр нигезендә Библия китапларыннан алынган һәм символик мәгънәгә ия хәбәрләрен искә төшерү дә җитә [33, б.193, 200]. Мөгаен, бу очракта да «Казан тарихы»ның авторы, вакыйгаларга аллегорик шәрехләүне бирер өчен, патша үтерү кебек популяр сюжетка мөрәҗәгать иткәндер. Бу вакыйгаларның семантикасын Иске Заветтагы сюжет төгәлләштерә. Анда гадел кешеләрне эзәрлекләүче һәм Иерусалимны яулап алырга омтылучы кырыс Ассирия патшасы Сеннахиримның үз уллары тарафыннан үтерелүе турында хикәяләнә. Урта гасырлар «Священное Писание» белгечләре тарафыннан мондый үлем гадел булмаган патшалык итү һәм иманлы кешеләрне газаплаган өчен җәза буларак бәяләнгән.

Шулар белән бергә «Казан тарихы»ның авторы, үз әсәренең уйланмасын ассызыклап, башка чыганаклардан да туры-дан-туры һәм читләтеп әйтелгән цитаталарны файдаланган. Хикәяләү барышында ук берничә тапкыр: «Кылыч һәм кан белән нигезләнгән Казан кылыч һәм кан белән юкка да чыкты», дигән фикерне кабатлый [29, б.203]. Күрәсең, автор патша үтерү вакыйгасын үз заманының иң дәрәҗәле әсәрләреннән алган, чөнки бу сюжет аның «Казан патшалыгы»ның кан эчендә

22. ПСРЛ. Т.8. Продолжение летописи по Воскресенскому списку. — М.: Языки русской культуры, 2001. — X + 302 с.
23. ПСРЛ. Т.12. Патриаршая или Никоновская летопись. — СПб.: Типография И.Н.Скороходова, 1901. — 267 с.
24. ПСРЛ. Т.20. Львовская летопись. — М.: Языки славянской культуры, 2005. — IV + 704 с.
25. ПСРЛ. Т.21. Ч.2. Книга степенная царского родословия. — СПб.: Типография М.А.Александрова, 1913. — 675 с.
26. ПСРЛ. Т.26. Вологодско-Пермская летопись. — М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1959. — 412 с.
27. ПСРЛ. Т.37. Устюжские и вологодские летописи XVI-XVII вв. — Л.: Наука, 1982. — 228 с.
28. ПСРЛ. Т.43. Новгородская летопись по списку П.П.Дубровского. — М.: Языки русской культуры, 2004. — 368 с.
29. Казанская история // Библиотека литературы Древней Руси. Т.10. — СПб.: Наука, 2001. — С.252-509.
30. Загоскин Н.П. Спутник по Казани. — Казань: Типография Императорского университета, 1895. — 691+83 с.

тууы һәм канга батып үлүе турындагы концепциясенә яхшы туры килеп тора.

Күрүебезчә, «Казан тарихы»ндагы хикәяләү башка, без алда карап үткән чыганаклардан нык аерыла. Бары тик Белёв янында бөек кенәз гаскәрләрен тар-мар итү һәм Олуг Мөхәммәднең Руська һөҗүмнәре турындагы мәгълүматлар гына охшаш. Шулай итеп, тарихчыларның 1437-1438 елларда Казан ханлыгына Олуг Мөхәммәд нигез салды дигән фикере каршылыклы чыганакларга нигезләнгән. Бу гипотеза 1437 елда Урда ханының Казанга килүе турындагы «Казан тарихы»нда әйтелгән хәбәргә нигезләнгән. Әйтергә кирәк, тарихчылар биредәге ялгыш датаны инкарь итәләр һәм вакыйгалар хронологиясен Олуг Мөхәммәднең исеме Казан белән бәйле булмаган рәсми елъязмалардан алалар.

Нәтиҗәдә, Казан ханлыгы оешу турындагы без карап үткән версияләр бер-берсенә бәйле булмаган ике чыганак тарафыннан расланмый. Шунысын да искәртик, озак еллар буе бу мәсьәлә рус китап язучыларын кызыксындырмаган. Фәкать XVI гасырның урталарында, мәгълүм вакыйгалардан соң гына, елъязмачылар Казан ханлыгының барлыкка килү шартлары турында уйлана башлаганнар. Фикерләү Мәскәүнең рәсми карашы кысаларында алып барыла, аның асылын Кырым ханы Сәхибгәрәйгә бирелгән грамота тәшкил итә. Рус дипломатлары, Иван IVнең Казан йортына хокукы барлыгын нигезләп, болай дип җавап биргәннәр: «Которой государь придёт ратью да возьмёт которого государя, да его сведёт, а землю его даст кому всхочет, не того ли земля будет, хто её взял?» Аларның сүзләре буенча, «Урда йортларын югалткан һәм Казан йортына сугыш белән барган, көч кулланып, аны яулап алган ханнар» кебек, Иван III тә Казанны алган [34, б.480]. Башкача әйткәндә, XVI гасырда Казанны Урда ханнары тарафыннан көч кулланып алу турындагы фикер Мәскәүнең сәяси таләпләренең хаклы, нигезләнгән булуын аңлату һәм русларның Көнчыгышка һөҗүмнәрен аклау өчен барлыкка килгән.

Казанның беренче ханы — Мәхмүд диюне башка чыганаклар да дәлилли [35, б.696; 36, б.26]. Әмма ханның 1445 елда Казанда күренүе турындагы хәбәр бары тик Никон һәм Воскресенск елъязмаларында гына бар. Югарыда язылганнарга нәтиҗә ясап, чыганаклар җитмәү сәбәпле, ханлык оешу шартлары турында бик сак фикерләргә кирәклеген искәртәбез.

Русчадан ***Ленар Гобәйдуллин*** *тәрҗемәсе*

31. Гумилёв Л.Н. От Руси до России: Очерки этнической истории. — М.: Айрис-пресс, 2004. — 320 с.
32. Кунцевич Г.З. История о Казанском царстве или Казанский летописец: Опыт историко-литературного исследования. — СПб.: Типография И.Н.Скороходова, 1905. — 682 с.
33. Плюханова М.Б. Сюжеты и символы Московского царства. — СПб.: Акрополь, 1995. — 336 с.
34. Российский государственный архив древних актов. Ф. 123. Сношения России с Крымом. Кн. 8.
35. Сборник русского исторического общества. Т.95. Памятники дипломатических сношений Московского государства с Крымом, нагаями и Турциею. Т.II. 1508-1521 гг. — СПб.: Товарищество «Печатня Б.П.Яковлева», 1895. — 706 с.
36. Родословная книга князей и дворян Российских и выезжих. — М.: Типография Н.Новикова, 1787. — Ч. 1. — 352 с.

КҮЧМӘННӘР ҖӘМГЫЯТЬЛӘРЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

КРАДИН Николай Николаевич — күчмәннәр җәмгыятьләре тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүче тарихчы, археолог һәм антрополог (этнолог); Россия Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты, тарих фәннәре докторы, профессор, Ерак Көнчыгыш халыклары тарихы, археологиясе һәм этнографиясе институтының Сәяси антропология үзәге мөдире, Ерак Көнчыгыш федераль университетының Гомуми тарих, археология һәм антропология кафедрасы мөдире. 300дән артык фәнни хезмәт, шул исәптән 19 коллектив хезмәт һәм 9 монография авторы.
Аның турында тулырак мәгълүматны карагыз: Николай Николаевич Крадин: библиографический указатель. / Авт.-сост. С.А.Васютин. Вступ. статья Б.В.Базаров, С.А.Васютин, С.В.Данилов, Л.В.Курас. — Владивосток: Изд-во ДВФУ, 2012.

– Хөрмәтле Николай Николаевич! Советлар Союзы таркалганнан соңгы чирек гасырда күчмәннәр цивилизациясе буенча нинди кызыклы ачышлар ясалды? Сезнең шәхсән бу өлкәне өйрәнүдә өлешегез нинди?

— Советлар Союзы таркалганнан соңгы дәвердә геополитик масштабта бик зур үзгәрешләр булды. Элемтәләр өчен юллар ачылды, глобализация дәвере килде һәм сәяси юнәлешләре төрле булган илләр арасында мөнәсәбәтләр көчәйде. Әлбәттә, болар фәнни өлкәдә дә зур үзгәрешләргә китерде. Советлар Союзы таркалуны ничек кенә бәяләмәсеннәр, фәнни күзлектән

Алтай Республикасы, Яломан V һәйкәлендә киртәләр комплексы, 1 нче номерлы объект. 2008 елны казылган. Төрки мәдәнияте ядкәре. VI гасырның II яртысы – VII гасырның I яртысы

караганда, бик мөһим уңышларга ирешелде. Беренче чиратта, бу Көнбатыш илләре белән постсовет дөньясы арасында күзгә күренми торган диварлар юкка чыгуда һәм элеккеге Советлар Союзы илләре белән Көнбатыш һәм Америка галим-археологлары арасында тыгыз элемтәләр урнашуда чагылыш тапты. Икенче яктан, Кытайга юллар ачылды һәм хәзер Кытай археологиясендә дә халыкара проектлар актив тормышка ашырыла, башка ил галимнәре белән элемтәләр үсә. Элекке Советлар Союзы республикаларына килгәндә, миңа бөтен постсовет мәйданын бәяләве кыен, шулай да иртә тимер гасыры белән шөгыльләнүче археологларның зур уңышларга ирешүләрен әйтергә кирәк. Украинадан һәм Россия Федерациясенең Идел буеннан алып Казахстан һәм Монголиягә чаклы бөтен Евразия мәйданында затлы күчмәннәр күмелгән курганнар ачылды. Шулай ук башка күптөрле ачышлар ясалды һәм алар археологиядә тикшерү ысуллары үзгәрү белән бәйле булды. Фәннилек көчәя, археология, чын мәгънәсендә, табигыять фәненә әверелде, чөнки даталарны ачыклау, төгәлләштерү өлкәсендә, археологик чыганакларны эшкәртүдә яңа төрле ысуллар кулланыла башлады, нәтиҗәдә, бу юнәлештә моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә алгарышка ирешелде. Бер генә мисал китерәм: археологлар озак вакытлар хуннулар (сөнниләр, сөннәр) [1] игенчелек белән шөгыльләнгәнме, юкмы, дип бәхәсләштеләр. Кытай язма чыганакларында аларда бернинди дә игенчелек булмаган һәм булырга да мөмкин түгел дип язылган. Ләкин күчмәннәрнең шәһәрлекләрен өйрәнү аларда игенчелек һөнәренең булуын белдереп тора иде. Нәкъ менә археология өлкәсендә кулланыла башлаган яңа ысуллар фәкать күчмә терлекчелек белән шөгыльләнергә тиеш булган күчмәннәрдә игенчелек эзләрен табарга ярдәм итте. Беренче карашка кечкенә генә үзенчәлек

1. Хуннулар — күчмә кабиләләр берләшмәсе. Безнең эрага кадәр I меңьеллыкта Үзәк Азиядә яшәгәнлекләре мәгълүм. Безнең эрага кадәр III гасыр азакларында берләшмәнең башлыгы Моде Хуннулар каханлыгын оештыра. 48 нче елда кытайлар хуннулар ыруларының көньяк өлешен үзләренә буйсындыралар. 87-93 нче елларда хуннуларның төньяк өлеше дә кытайлар тара-

сыман, ә чынлыкта ул безнең күчмәннәр җәмгыятенә карашларыбызны тамырдан үзгәртә.

Евразия турында сөйләгәнгә караганда, мөгаен, үзем эшләгән төбәктәге ачышлар белән таныштырсам, кызыклырак булыр. Соңгы 12 елда без тикшеренүләр алып барган Монголия җирләре, минем фикеремчә, Евразия дала җирлегенең үзәге дип саналырга тиеш, әмма болай дип белдерү, әлбәттә, һич кенә дә башка төбәкләрне кимсетми: аларда да үзенчәлекле гүзәл мәдәният учаклары булган, әмма Евразия мәйданында башланган барлык импульслар Монголиядән килә, барлыкка килгән күпчелек империяләрнең чишмә башы булып Монголия тора.

Алтай Республикасы, Яломан II һәйкәлендәге янәшә урнашкан 1-2 нче номерлы киртә урыны. 2003 елны казылган. Төрки мәдәнияте ядкәре. V гасырның II яртысы – VI гасырның I яртысы

Монголия археологиясенә килсәк, монда бер үк вакытта төрле өлкәләрдә зур алга китеш күзәтелә. Хәзер күп кенә археологлар бронза чоры, иртә тимер чорын өйрәнү белән шөгыльләнә. Яңа археологик культуралар табылды, плиткалы каберлекләрнең даталары, вакытлары төгәлләштерелде. Бу чорларны өйрәнүче археологлар, Кытай бердәм империягә берләшкәнче үк, күп кенә сәяси берләшмәләр Монголия далаларында булган дигән шактый нигезле нәтиҗәгә килделәр.

Соңгы дистә елларда күчмәннәр империяләрендә, Кытай территориясендә күтәрелүләр-таркалуларда цикллар һәм синхронлык күргән америка антропологы Томас Барфилд карашлары танылды. Мин дә күпмедер дәрәҗәдә рус телле төбәкләрдә бу карашларны танытуга өлеш керттем. Хәзер вакыйгаларның бөтенләй үк алай булмаганлыгы ачыкланды. Әгәр дә хуннулар археологиясе турында сөйләсәк, хәзерге вакытта бу тема белән Монголиядә кызыксыну күзәтелә. Ел саен бик күп археологик экспедицияләр оештырыла. Нигездә, археологлар курганнардагы каберлекләрне өйрәнү белән шөгыльләнә. Беренче чиратта, затлы күчмәннәр күмелгән курган комплексларын тикшерүгә игътибар бирелә. Россия Фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты Наталья Викторовна Полосьмак җитәкчелегендәге Россия-Монголия экспедициясенең уңышлары турында әйтәсем килә. Алар Ноин-Уладагы 20 нче курганны казыйлар. Бу — мәшһүр Россия сәяхәтчесе П.И.Козлов җитәкчелегендәге экспедиция тикшергән Ноин-Ула. Аның материаллары 1962 елда Сергей Иванович Руденко тарафыннан бастырылды. Россия-Монголия экспедициясе тагын бер затлы күчмән күмелгән курганны казыды һәм тиңе булмаган чыганаклар тапты. Әлеге табышлар турында узган

фынан җиңелүгә дучар ителә һәм көнбатышка таба чигенергә мәҗбүр була. Андагы җирле төркиләр белән кушылганнан соң, Һуннар аталы кабиләләр берләшмәсе барлыкка килә (Татар энциклопедия сүзлеге. — Казан, 2002. — Б.738).

елның азагында китап дөнья күрде. Хәзер экспедиция тагын бер курганны казу белән шөгыльләнә, алар инде күмелгән катламга кадәр төшеп җиттеләр һәм тикшерү эшләрен башладылар. Быел казу эшләре тәмамланырга тиеш. Н.В.Полосьмак җитәкчелегендәге экспедиция табышлары, беренче чиратта, Көнбатыш һәм Көнчыгыш арасында булган кыйтгаара элемтәләр турында сөйли. Уникаль келәмнәр һәм шуңа охшаш әйберләрдән кала, антик рәсемнәр төшерелгән фалара табылуын искәртеп китәргә кирәк. Аңлашыла ки, бу әйбер Көнбатыштан, мөгаен, Бактриядән килгәндер. Күчмәннәр күмелгән курганнарны өйрәнүче башка экспедицияләр дә шундый элемтәләр булуын дәлилләли. Узган ел монгол археологы Эрдэнэбаатар Гол-Мод-2 каберлегендә, мөгаен, затлы күчмән күмелгән иң зур курганны казыгандыр. Гомумән алганда, Гол-Мод-2 безгә бик тә яхшы чыганаклар бирде, французлар инде китап бастырдылар. Миңа Эрдэнэбаатар табылган әйберләрне күрсәтте. Кыйтгаара мөнәсбәтләрнең булуын дәлилләүче табышларның берсе — Италиядә эшләнгән кечкенә пыяла чокырның (Рим пыяласы) монда килеп эләгүе киң багланышлар турында сөйли.

Хунну дәверенә караган тагын бер ачыш — Дурлиг-Нарс каберлеге. Ул Көнчыгыш Монголиядә — Россия-Монголия чигеннән ерак түгел урында. Анда сугышчы каберлеге казылды. Физик-антропологик тикшеренүләр нәтиҗәсендә, бу сугышчының европеоид, тумышы белән Италиядән булуы ачыкланып, моны генетик тикшеренүләр дә раслалдылар. Миндә шунда ук бу Монголиягә килеп эләккән һәм, Шаньюда гаскәри хезмәткә кереп, зур статуска ирешкән соңгы Красс легионерының берсе булмадымы икән, дигән уй йөгереп узды. Әлеге ачыш хунну империясендә булган этник толерантлык һәм киң географик мөнәсәбәтләр турында сөйли.

Соңгырак тарихи чорга мөрәҗәгать итсәк, төрки-уйгыр археологиясе шактый җитди уңышларга ирешә. Төрки каханнар эшчәнлеге белән бәйле затлы гыйбадәтханәләр комплексы казылды. Аеруча кыйммәтле асылташлар белән бизәлгән, бик матур алтын таҗ табылуы игътибарга лаек. Шулай ук затлы асылташлардан эшләнгән хакимият символларына бәйле предметлар да табылды. Бу материаллар китапта басылып чыкты, алар хәзер Улан-Батор музее экспозицияләрендә урын алдылар.

Ә соңгы берничә елда уйгырларга нисбәтле ике уникаль курган өйрәнелде. Курганнарның беренчесе Үзәк Монголиядә, Улан-Батор шәһәреннән якынча 250 чакрым көнбатышта, без эшли торган җирдән ерак булмаган урында. Бу курган Улан-Уде шәһәреннән тарих фәннәре докторы Сергей Владимирович Данилов һәм монгол тарихчылары белән берлектә казылды. Курган кенотаф [2] булып чыкты, табылдыклар бик күп, әмма иң әһәмиятлесе — үлгән кешегә куелган эпитафия язулы таш плитә. Анда уйгыр конфедерациясенә [3] кергән телесс [4] гаскәр башлыгы җирләнгән булырга тиеш. Ул монда Кытайның

2. Үлгән кешенең мәете булмаган символик каберлек. Күмү ритуаллары башкару урыны.
3. Өченче Уйгыр каханлыгы вакытында (VIII-XI гасырлар) уйгыр конфедерациясенә 19 кабилә кергән, алар өчен «уйгыр» этнонимы уртак булган.
4. телесслылар — төрки телле күчмәннәр.

мәнфәгатьләрен кайгырткан, Беренче Төрки каханлыгы [5] җимерелгәннән соң, Тан императорында [6] хезмәттә булган. Бу — Беренче Төрки каханлыгы җимерелгәннән соң, шушы территориягә Кытайның көчле йогынты ясавын дәлилли торган уникаль язма чыганак. Икенче курган беренчесеннән 15 чакрым ераклыкта урнашкан, барлык билгеләре буенча да ул уйгырлар чорына карый. Аны Казахстан экспедициясе казыды. Анда да уникаль чыганаклар тупланган. Дромосның [7] диварлары тан, кытай сюжетлар фрескалар белән бизәлгән: җайдаклар, аждаһалар, склеп эчендә балчыктан ясалган курчаклар, бәһаләп бетергесез гүзәл итеп эшләнгән күпсанлы алтын бизәнү әйберләре бар. Алар бик зур фәнни әһәмияткә ия. Болардан кала Кытай экспедициясе Уйгыр каханлыгына нисбәтле курганнар комплексын казыды.

Аннан соңгы чорга килгәндә, без соңгы ун ел дәвамында Монголия территориясендә Ляо империясе [8] шәһәрләрен казыйбыз. Безгә өч шәһәрлекне казып, бу территориядәге Киданнар империясе археологик материаллары коллекциясен тупларга мөмкин булды. Төрле дәрәҗәдәге табышлар бар. Күптән түгел генә Чинтолгой-балгас шәһәрлеге турында китап нәшер иттек.

Табылган материаллар тулысы белән киләчәктә күптомлыкларда биреләчәк. Иң кызыгы шунда, кидан шәһәрләре дип саналган шәһәрләргә киданнар нигез салмаган. Казый башлагач

КРАДИН НИКОЛАЙ НИКОЛАЕВИЧНЫҢ МОНОГРАФИЯЛӘРЕ ҺӘМ КИТАПЛАРЫ:

1. Крадин Н. Н. Социально-экономические отношения у кочевников в советской исторической литературе. – Владивосток, 1987. – 161 с.
2. Крадин Н. Н. Кочевые общества. Владивосток: Дальнаука, 1992. – 240 с.
3. Крадин Н. Н. Империя Хунну. Владивосток: Дальнаука, 1996. – 164 с. 2-е изд. перераб. и доп. М.: Логос, 2001/2002. – 312 с.
4. Крадин Н. Н. Политическая антропология: Учебное пособие. – М.: Ладомир, 2001. – 213 с. 2-е изд. перераб. и доп. Политическая антропология: Учебник. М.: Логос, 2004. – 270 с. 3-е изд. М.: Логос, 2010, 2011. – 270 с.
5. Крадин Н. Н. Данилов С. В., Коновалов П. Б. Социальная структура хунну Забайкалья. – Владивосток: Дальнаука, 2004. – 106 с.
6. Крадин Н.Н., Скрынникова Т.Д. Империя Чингис-хана. – М.: Восточная литература РАН, 2006. – 557 с.
7. Крадин Н.Н. Кочевники Евразии. – Алматы: Дайк-Пресс, 2007. – 416 с.
8. Очир А., Крадин Н.Н., Ивлиев А.Л. и др. Археологические исследования на городище Чинтолгой. – Улан-Батор, 2008. – 270 с. (на русс. и монг. языках).
9. Крадин Н.Н., Ивлиев А.Л., Очир А., Васютин С.А., Данилов С.В., Никитин Ю.Г., Эрдэнэболд Л. Киданьский город Чинтолгой-балгас. – М.: Восточная литература, 2011. – 173 с.

5. Җитәкчеләре Ашина ыруыннан чыккан, VI гасыр уртасында барлыкка килгән төрки кабиләләр берләшмәсе. 603 елда Көнчыгыш һәм Көнбатыш төрки каханлыкларга таркала.

6.Тан династиясе (616-907) — Ли Юань нигезләгән Кытай императорлары династиясе.

7. Курган астында урнашкан гөмбәз төрбәгә үтү юлы.

8. Ляо империясе киданнар, монгол телле аучылар һәм күчмәннәрдән торган империянең кытайча исеме. Бу дәүләткә 907 елда кабилә башлыгы Абаоцзи нигез салган, ул хәзерге Эчке Монголиянең көньяк-көнчыгыш өлешен биләп торган. 947 елда биредә яңа ел санау тәртибе кертелгән, империя Бөек Ляо исеме белән йөртелә башлаган. Буддизм таралгач, китап бастыру эше җайга салынган. Иң куәтле вакытында империя Япон диңгезеннән Көнчыгыш Төркстанга кадәр, Сары диңгездән Байкал артына кадәр җирләрне биләгән. 1125 елда, чжурч-

ук, материалларның Идел буе, Россиянең Ерак Көнчыгышы, Приморьеда очрый торган чыганакларга охшаш булуы хакында билгеле булды. Приморьеда минем хезмәттәшләрем Бохай археологик культурасын өйрәнү белән шөгыльләнәләр. Без мондый кызык хәлгә таргач, тарихи язма чыганаклардан мәгълүматлар эзләргә керештек һәм Бохай дәүләте киданнар тарафыннан юк ителгәч, бохайлыларның еш кына баш күтәрүләре һәм киданнарның ахыр чиктә кырыс депортация сәясәте үткәрә башлаулары турында мәгълүматка юлыктык. Алар җирле халыкны өлешчә Маньчжуриягә депортацияләгәннәр, әмма берникадәр өлеше Монголиягә күчерелгән. Язма чыганаклардан бу хакта да дәлилләр таптык. Нәтиҗәдә, берничә мең чакрым ераклыкта урнашкан Приморьедагы һәм Манчьжуриядәге бохайлылар эзләре [9] Монголия территориясендә табылды. Һәм, иң кызыклысы, шундый ук сәясәт монголлар чорында да тормышка ашырылган, чөнки Манчьжуриядә гомер иткән җөрҗәннәр безнең Приморье территориясендә дә яшәгән.

Шулай ук без Байкал аръягы шәһәрләрен казыйбыз һәм җөрҗән мәдәнияте эзләрен табабыз. Аларның эзләрен Идел буендагы Алтын Урда истәлекләрендә дә күзәтергә мөмкин. Гомумән, Идел буена җөрҗәннәр белән килгән әйберләр бик күп, алар трансформацияләнгәннәр һәм Алтын Урда мәдәниятенә кергәннәр. Әйтик, каннар үзгәртелеп, соңрак йортларны җылыту системасы рәвешен алганнар.

2000 елдан алман экспедициясе Монгол империясе башкаласы булган Хархоринны (Каракорым) казыды һәм бу өлкәдә бик яхшы нәтиҗәләргә иреште. Алманнарның хезмәтләре өлешчә басылып та чыкты. Ә без параллель рәвештә Байкал аръягы территориясендә монгол чоры истәлекләрен тикшерәбез. Танылган археолог, СССР Фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты Сергей Владимирович Киселёв эзләнүләрен дәвам итәбез. Өч ел дәвамында Хархорин шәһәрчегеннән ун чакрым ераклыктагы яңа Сарай комплексын, бер утарны казыдык. Тикшерү нәтиҗәләре буенча хәзер китап бастырырга әзерлибез. Шулай ук без С.В.Киселёв өйрәнгән Окошки каберлеген дә казыдык һәм ул безгә XIII-XIV гасырларда монголларның җирләү йолаларына караган бик тә кызыклы мәгълүматлар бирде.

Күчмәннәр күмелгән затлы курганнарны өйрәнү, әлбәттә, бик кызыклы юнәлеш, әмма, ни кызганыч, кыенлыклар да бар. Музейлар өчен ул табылдыклар — бик яхшы коллекция, ә шәһәр культурасын өйрәнү — күләмле, чыгымлы эш, әлеге коллекцияләрне саклар өчен зур мәйдан таләп ителә. Әлбәттә, күчмәннәр төзегән шәһәр культурасын, империяләрне өйрәнергә кирәк. Бу юнәлештә барлык көчебезне куябыз.

– Николай Николаевич, халыкара мөнәсәбәтләр кысасында игенчеләр һәм күчмәннәр арасында булган үзара бәйләнешләр турында Сезнең фикерегезне беләсе килә. Бу өлкәдә нинди динамика күзәтеләме?

жәннар баш күтәргәннән соң, дәүләт таркалган. Киданнарның бер өлеше Урта Азиягә киткән.

9.Тунгус-маньчжурларның беренче дәүләте Бохай (698-926) дип аталган, ул Маньчжурия һәм Приморье крае һәм Корея ярымутравының төньяк өлешен биләп торган. 926 елда Бохайны киданнар яулап алган.

10.Сүз Эдвард Саидның «Ориентализм. Западные концепции Востока» исемле китабы турында бара.

— Мин элек бу сорауны бары тик хуннулар дәверенә мөнәсәбәтле өйрәндем. Шул вакытта ук күчмәннәр империясенең барлык чорларда күпсанлы шәһәрләре булганлыгы ачыкланды. Бу империяләрне, бәлки, лингвистик яктан күчмәннәр империясе дип әйтергә ярамый да торгандыр, чөнки анда игенчеләр дә яшәгән, әмма биредә күчмәннәр өстенлек иткән һәм сәяси лидерлык алар кулында булган. Бу шәһәрләрнең халкы утрак тормыш алып барган дәүләтләрдән алып кайтылган әсир һәм коллардан гына тормаган. Язма чыганаклар буенча анда күп кенә ярлы, түбән баскычта торган кытайлыларның күчеп килүләре мәгълүм. Алар үзләре дә далага качуны өстен күргәннәр. Бер кытай елъязмасында бу качып китүнең шактый катлаулы булуы, чик буйларында бик җитди каравыл торуы һәм күчмәннәргә барып җитү шактый авыр икәнлеге турында языла. Әгәр дә алар анда барып җитсәләр, тормыш-көнкүреш алар өчен күпкә җиңелрәк һәм яхшырак булган. Монголиядәге киданнарның шәһәрләрен өйрәнеп, без күченгән халыклар арасындагы мөнәсәбәтләр берникадәр вакыттан соң җайлашкан дигән фикергә килдек. Бу кешеләр, төрле этник үзенчәлекләренә дә карамастан, үзләрендә империянең форпостын тойганнар, җирле күчмә кабиләләр белән тыгыз сәүдә эшләре алып барганнар. Багланышлар һәм үзара мөнәсәбәт шактый борынгыдан ук яшәп килгән. Тарих фәнендә электән үк берничә миф яши иде. Аларның берсе — күчмәннәрнең начар булулары турында. Бу миф утрак тормыш алып баручылар арасында туган. Алар күчмәннәрне варварлар дип уйлаганнар. Бу мифны җимерүгә Л.Н.Гумилёв үзеннән зур өлеш кертте. Әмма ул бары тик яхшы, уңай якларны гына күрсәтә, имештер, игенчеләр аларга мәшәкать тудырган, дип яза. Мин моны Гумилёв аң төпкеленә нигезләнми эшләгәндер дип уйлыйм. Бик

Төрки күчмәннең аты белән күмелгән каберлеге реконструкциясе. Таулы Алтайдагы Катанда-3 каберлеге. VII гасырның II яртысы – VIII гасырның I яртысы

Күчмәннәрнең бакырдан эшләнгән казаннары. Алтай крае Целинный районы Победа авылы янында очраклы табылдыклар. Б.э.к. VI-II гасырлар. Быстрян археологик культурасы таралган төбәк

еш начарны яхшыга үзгәрткәндә була торган хәл, бу очракта таякны бөгәргә тырышасың... Без хәзер халыклар арасындагы мөнәсәбәттә объектив картинаны күрсәтәбез. Дөрес, төрле дәверләр булган: сугышлар да, шулай ук тыныч мөнәсәбәтләр дә. Бу мөнәсәбәтләрдә файданы ике як та алган.

– Күчмәннәр җәмгыятен бәяләгәндә, Европоцентристик бәяләү өстенлек итә. Без Россия, Совет мәктәбе традицияләрендә тәрбияләндек. Бүгенге көндә күчмәннәрнең үз дәүләтләре булуын таныр өчен нинди факторлар комачаулый. Бәлки безгә төрле яшәү шартларына һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләргә – утрак һәм күчмә тормышка – яраклашкан дәүләтләр модельләре турында сүз алып барырга кирәктер?

— Әйе, мин Сезнең белән килешәм. 20 ел буе мин язган хезмәтләремдә күчмәннәр төзегән сәяси система моделенең Көнбатыш Европа дәүләтләренекеннән, Якын Көнчыгышныкыннан һәм Кытайныкыннан аерылуын дәлилләргә омтылдым. Охшашлыклар бар. Төрле сәяси культуралар ике якка да йогынты ясаган. Алар бер-берсеннән үзләренә нәрсә кызык, шуны кабул иткәннәр. Әгәр дә без Тан империясе дәүләтен искә алсак, төрле идея һәм принциплар күчмәннәрдән кергән. Боларны хәзерге галимнәр таныйлар.

Мин күчмәннәрнең җәмгыятьләрен дәүләт дип санамыйм. Әмма бу аларда зур сәяси берләшмәләр булмаган дигән сүз түгел. Мәгълүм ки, дәүләт бюрократия белән бәйләнгән һәм дәүләт төшенчәсенең ике билгеләмәсе бар. Беренчесе, дәүләт ул — сәяси берләшмәләр, ил һәм бу очракта «дәүләт» сүзе күчмәннәр җәмгыятенә туры килер иде. Әмма без дәүләтне чиновниклар бюрократиясеннән торган дәүләт хакимияте дип саныйбыз. Мондый система күчмәннәрдә күзәтелми. Ул күчмәннәрдә генә түгел, ә Европадагы иртә феодаль дәүләтләрдә дә булмаган. Бу

һич кенә дә күчмәннәрне кимсетү түгел. Иң әүвәле терминның асылын белергә кирәк һәм аннары гына хөкем чыгарырга ярый. Мин үземнең монгол коллегаларыма: «Әгәр дә Чыңгыз ханның дәүләте булса, ул мондый бөек яулап алуларга ирешмәгән булыр иде», — дип әйтәм. Чөнки бюрократлар һәм чиновниклар аның уңышларын кәгазь язу-сызу, инструкцияләр белән юкка чыгарыр иде. Анда дәүләт булмаган, ә унарлы системасы яшәгән. Ул үз функциясен искиткеч югары дәрәҗәдә башкарган. Зур дәүләт кечкенә проблемаларны хәл итә алмый: тегендә-монда сугыш чыга, чиновниклар шәхси, корпоратив мәнфәгатьләрдә тоткарланалар. Ә Чыңгыз хан империясендә мондый күренешләр юк. Бу анда бюрократик дәүләт булмавы турында сөйли.

Европоцентризмга килгәндә, соңгы елларда яхшы якка зур үзгәрешләр башланды инде. Көнбатышта 1970 еллардан башлап ориентализм төшенчәсе барлыкка килде. Әлеге термин Эдвард Саидның шундый ук исемле китабы белән бәйле [10]. Бу дөнья тарихында Көнбатышның, шулай ук дөньядагы башка төбәкләрнең урынын билгеләүне үзгәртте, тора-бара яңа идеяләр безнең фәнгә дә үтеп керделәр, төгәлрәк әйтсәк, инде күптән үтеп керделәр. Мисалга хәзерге методологик карашларны чагылдырган «Бөтендөнья тарихы»ның икенче томын китерә алам. Аны Россия Фәннәр академиясенең Бөтендөнья тарихы институты әзерләде. Алты томлыкның икенче томы урта гасырларга карый. Бу дәвер тарихы европоцентристик караштан чыгып түгел, ә шул чор цивилизацияләренең, мәдәниятләренең күптөрлелеген күрсәтеп һәм күчмәннәрнең тарихи процесска керткән зур өлешләре дәлилләнеп язылган. Тарихи процесста күчмәннәр дөньясы белән бәйле иң мөһим фактор ул — кыйтгаара мөнәсәбәтләрнең үсеше һәм төрле, шул исәптән технологик, идеологик мәгълүматларның таралышы. Менә шуларда күчмәннәрнең зур рольләре күренә инде.

10.Сүз Эдвард Саидның «Ориентализм. Западные концепции Востока» исемле китабы турында бара.

– Сез, мөгаен, хәбәрдарсыздыр: хәзер унсигез томлы Россия тарихы язылачак. Аның ничә томы борынгы һәм урта гасырлар тарихына караячак?

— Бу хакта хәбәрдар түгелмен. Мин әле ике ай ярым вакытымны экспедициядә үткәрдем, башта Байкал аръягында, аннары Монголиядә археологик казу эшләре алып бардык. Төгәл мәгълүматым юк. Әмма методологик позицияләрдән чыгып язылыр дип өметләник, анда Россиядә яшәүче барлык халыкларның да тарихы яктыртылырга тиеш.

– Барыннан да бигрәк урта гасырлар тарихы лаеклы яктыртылырга тиеш, чөнки Россия территориясе – анда яшәүче барлык милләтләр территориясе.

— Әлбәттә, Россия — асылы белән Евразия державасы. Ул борынгы гасырларда ук нигез салынган тарихи традицияләрне дәвам итә, күпмилләтлелек безнең илебезнең төп сәяси һәм

мәдәни традицияләре нигезен тәшкил итә. Монда шунысы да бик мөһим: бу китап «хор» булсын иде. Чөнки һәрбер тавыш, һәрбер мәдәният бу томда чагылыш табарга тиеш. Шулай булганда гына чын оркестр барлыкка килә.

– Төрки каханлыкның күтәрелүе һәм җимерелүе нинди сәбәпләр аркасында булды?

— Нәкъ менә шушы темага караган китап язу белән шөгыльләнәм. Мин аның ни турында булачагын әлегә әйтмим, сер булып калуын телим, әмма шуны гына әйтә алам: барлыкка килү, оешу теориясе — һәрвакытта да күпфакторлы процесс, аңа күптөрле сәбәпләр йогынты ясый. Монда табигать-экологиянең үзгәрүе дә, күрше дәүләтләр белән мөнәсәбәт тә һәм, табигый ки, шәхес факторы да зур роль уйнаган. Совет чорында шәхес факторы тиешле дәрәҗәдә бәяләнеп җитмәгән, ә ул күчмәннәр империяләре өчен фундаменталь мәгънәгә ия иде. Таркалуга килгәндә, монда да шундый ук вазгыять күзәтелә. Бик тә мөһим бер сәбәп турында искәртәсем килә. Ул — элитаның нык артып китүе. Мин моны XIV-XV гасырларда яшәгән гарәп фәлсәфәчесе Ибне Халдун кануны дип атыйм. Күчмәннәр империясенә карата бу канун 100% эшләгән. Аларның элитасында һәрвакыт полигамия күзәтелә: күчмәннәр, кагыйдә буенча, күпхатынлы һәм күпбалалы булганнар. Минем хисаплауларым буенча, 4 нче буында һәр күчмәннең күп оныгы булган, алар арасында шактый еш каршылыклар, сугышлар килеп чыккан, җир-суны, мал-мөлкәтне бүлешә алмаганнар, һәм, нәтиҗәдә, империяләр таркалган. Күз алдыгызга китерәсездер: Чыңгыз ханның йөзләп хатыны, җариясе булган, күпме онытгы... Бу сәбәпне бик сирәк тарихчылар искә алган, әмма бик тә мөһим фактор. Мин менә шушы юнәлештә эшлим.

Төркиләрнең 1970 нче еллар азагында Таулы Алтайдан кайтартылган таш сыннары. Табылу урыннары билгеле түгел. Күрәсең, күмү комплекслары яннарында куелган булганнар

– Соңгы вакытта күчмәннәрнең шәһәрләре булуы турында күп сөйли башладылар. Анда кемнәр яшәгән? Алар күчмәннәр берләшмәсендә нинди роль уйнаганнар?

— Чыннан да, бу — күчмәннәр империясе тормышының бик мөһим ягы. Монголия территориясен алсак, гомумән, ныгытылган яки ныгытылмаган яшәү урыннары булмаган, тегe яки бу дәрәҗәдә утрак тормыш алып бармаган бер генә күчмәннәр империясен дә белмим. Болар барысы да шәһәрләрнең күчмәннәр тормышында мөһим урын тотканлыгын күрсәтеп тора. Биредә игенчеләр яшәгән һәм алар ихтыяҗ булган продук-

Алтай Республикасы, Яломан IV һәйкәлендә 7 нче номерлы киртәлек. 2008 елны казылган. Төрки мәдәнияте ядкәре. VI гасырның II яртысы – VII гасырның I яртысы

цияне җитештергәннәр, чөнки ит белән генә туклану мөмкин түгел. Торак пунктларда яшәүчеләр һөнәрчелек белән дә шөгыльләнгәннәр, алар җитештергән әйберләргә ихтыяҗ зур булган. Сүз, бер яктан, хәрби кораллар җитештерү, икенче яктан, элита өчен кыйммәтле көнкүреш әйберләр ясау турында бара. Шуңа күрә күчмән империяләрне өйрәнүдә шәһәрләр казуны бик мөһим дип саныйм. Күп тапкырлар, хәтта археологларның съездларында да бу өлкәдә көчләрне берләштерү мәсьәләсен күтәрдек, зур кызыксыну белән Татарстандагы хезмәттәшләребезнең ничек итеп Идел буе шәһәрләре мәдәниятен өйрәнүләрен күзәтеп барырга тырышам. Аларга безнең Приморьеда җөрҗәннәрнең көчле шәһәр цивилизациясе яшәве, шушы төбәктәге өч йөзләп шәһәр һәм шәһәрлекләр кызыклы булыр. Без киданнарны, монголларны өйрәнәбез. Бу юнәлеш киләчәктә үзәктә булыр дип уйлыйм.

– Безнең Татарстанда Казан алынгач һәм аннан соң христиан динен кабул иткән керәшен татарлары бар. Урта гасырларда күчмәннәр арасында, гомумән, төрки дөньяда христиан дине таралу турында ни әйтә аласыз?

— Археология һәм язма чыганаклар күчмәннәр арасында күпмедер дәрәҗәдә христиан дине таралу турында сөйли һәм Монголиядә несторианлык яшәгән, әмма христиан дине киң җәелмәгән. Бу — мәгълүм факт. Күчмәннәр, Макс Вебер әйткәнчә, «гаскәриләр һәм сәүдәгәрләр дине» булган ислам динен кабул иткәннәр. Монголиядә буддизм таралган. Дин таралу ул — катлаулы күренеш. Күчмәннәр империяләрендә төрле диннәр, мәсәлән, Уйгыр каханлыгында манихейлык булган, ул һинд йогынтысы белән бәйләп аңлатыла. Бу катлаулы өлкәдәге һәрбер мәсьәләне махсус өйрәнергә кирәк.

– Хәзерге вакытта күчмәннәр берләшмәләрен өйрәнүче археологлар алдында нинди бурычлар тора? Халыкара конгресслардан тыш тагын нинди хезмәттәшлек формаларын оештырырга мөмкин?

— Миңа калса, барыбызны да борчый торган берничә проблема бар. Беренчесе — «кара археология» һәм бу күренеш белән көрәшү. Әмма мин «археолог» сүзен болай мәсхәрәләргә теләмим, шуңа күрә «кара казучылар» терминын кулланам. Бу зур һәм җитди проблема. Кызганыч ки, дәүләт безгә кирәкле кадәр булышмый. Тиз арада тиешле законнарны кабул итәргә һәм әлеге проблеманы югары дәрәҗәдә хәл итәргә кирәк. Хәтта безнең күршебез булган кечкенә генә Монголиядә бу мәсьәлә күпкә яхшырак хәл ителгән, анда катгый законнар бар. Археологлар аны даими рәвештә күтәрәләр, узган ел Владимир Владимирович Путин белән очрашу вакытында бу хакта сөйләшү булды. Болар барысы да бюрократия мәсьәләсенә барып тоташа: дәүләттә түрәләр күп, барысы да әкрен хәл ителә.

Минем өчен мөһим булып күренгән икенче мәсьәлә — безнең илдә күчмәннәрне өйрәнүче белгечләр өчен бер мәйданчык төзү. Кызганыч ки, бездә күчмәннәр дөньясын өйрәнү буенча җитди фәнни журналлар юк. «Российская археология» «Этнографическое обозрение», «Восток» журналлары бар. Хәзер Новосибирск каласында ике телдә «Евразия археологиясе, этнологиясе, антропологиясе» дигән бик яхшы журнал чыга башлады. Әмма бу бик аз. Мондый журналларның санын арттырырга кирәк, алар әйдәп баручы фәнни үзәкләрнең грифы астында чыгарга тиеш һәм бик мөһим шарт: дөнья җәмәгатьчелеге дә безнең галимнәрнең ачышларын белсен өчен аларны ике телдә — русча һәм инглизчә бастыру мәслихәт. Мондый берничә журнал булырга тиеш. Күчмәннәрне өйрәнү фәне, Пётр Савицкий әйткәнчә, ул — Россия фәне, Россия дисциплинасы, чөнки безнең илебезнең шактый өлеше дала дөньясын өйрәнү белән бәйләнгән.

Ниһаять, соңгысы — күчмәннәрне өйрәнүче белгечләр өчен дә очрашу мәйданчыклары кирәк. Урта гасырлар Евразия далалары археологиясенең II халыкара конференциясе* — безнең илдә яшәүче күчмәннәр буенча белгечләрне бергә җыйнау, үзләренең фәнни идеяләре белән алмашсыннар өчен, бик тә мөһим юл. Фәнни ачышларга килгәндә, әгәр дә фән үссә һәм археологлар үзләренең культура катламнарын өйрәнсә, яңа ачышлар артыр һәм тагын да нәтиҗәлерәк уңышлар булыр.

*Әңгәмәдәш — **Илдус Заһидуллин***
Алтай крае, «Стик-Тревел» туристлык комплексы
7 сентябрь, 2012 ел

*Русчадан **Ленар Гобәйдуллин** тәрҗемәсе*

*Алтай краенда оештырылган конференция турында «Тарих сәхифәләреннән» рубрикасында укый аласыз. (*Ред.*)



Ханнар төрбәсенең
хәзерге күренеше

2004-2005 елгы
казуларның
Сөембикә мана-
расыннан гомуми
күренеше

Казан ханлыгы Кремленең төзелеш реконструкциясе. XVI гасырның I яртысы (археологик материаллар нигезендә)

КАЗАН КРЕМЛЕНДӘ ХАННАР ТӨРБӘСЕ

ФАЯЗ ХУЖИН,
тарих фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы

АЙРАТ СИТДЫЙКОВ,
тарих фәннәре кандидаты, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Археологик тикшеренүләр үзәге җитәкчесе

1977 ЕЛНЫҢ ҖӘЕНДӘ ПРОФЕССОР А.Х.ХАЛИКОВ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ ЭШЛӘҮЧЕ БЕР ТӨРКЕМ АРХЕОЛОГЛАР, СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫНЫҢ КӨНБАТЫШ ЯГЫНДА КАЗУ ЭШЛӘРЕ АЛЫП БАРГАНДА, XV-XVI ГАСЫРЛАРДА ТУПЛАНГАН КАТЛАМДА АК ТАШТАН САЛЫНГАН НИНДИДЕР БЕР БИНА ХӘРАБӘЛӘРЕНӘ ТАП БУЛАЛАР. БИК НАЧАР САКЛАНГАН БУЛУГА КАРАМАСТАН, ӘЛЕГЕ КОРЫЛМАНЫҢ БОРЫНГЫ ТӨРБӘ КАЛДЫКЛАРЫ ИКӘНЕН АЧЫКЛАУ КЫЕН БУЛМЫЙ: БИРЕДӘ БЕРСЕ ЭЧЕНӘ ИКЕНЧЕСЕ КЕРТЕП КУЕЛГАН, ТЫШЫ ЯХШЫ СЫЙФАТЛЫ КҮН ҺӘМ ЕФӘК ТУКЫМАЛАР БЕЛӘН ТЫШЛАНГАН, КӨМЕШ КАДАКЛАР ҺӘМ ФИГУРАЛЫ КАЛАЙЛАР БЕЛӘН БИЗӘЛГӘН АГАЧ ТАБУТЛАРДА ИКЕ МӘЕТ СӨЯКЛӘРЕ ТАБЫЛА.

Әлбәттә инде, гади шәһәр халкын Кремль уртасында таш төрбәләргә күммәгәннәрдер, һичшиксез, ханнар төрбәсе булырга тиеш бу, дип фаразлый атаклы археолог Альфред Халиков. Кызганычка каршы, әлеге ачышлар турында фәнни даирәләрдә иркенләп сөйләргә, казу эшләренең материалларын бастырып чыгарырга мөмкинлек булмады — Алтын Урда һәм Казан ханлыгы тарихлары ул заманнарда, йомшак кына әйткәндә, актуаль түгел иде. Үзгәртеп корулар чоры башлангач кына А.Х.Халиков ханнар төрбәсе турындагы фикерләрен халыкка җиткерә алды [1]. Аның фаразлавы буенча, төрбәләрнең берсендә Олуг Мөхәммәд яисә аның улы Мәхмүд, икенчесендә Сафагәрәй күмелгән булырга тиеш. Әмма, заманасы шундый булгандыр инде, бу ачышлар галимнәр арасында артык кызыксыну тудырмады.

1994 елда Казан Кремлендә масштаблы казу эшләре башланып китте, борынгы архитектура һәйкәлләрен реставрацияләүгә, яңа музейлар ачуга бәйләнешле кызыклы проектлар барлыкка

1. История Казани. Первая книга. — Казань, 1988. — С.28; Халиков А. Что, башня, в имени твоём? // Татарстан. — 1992. — № 11-12.

килде. Галимнәр 1977 елгы ачышларга яңадан әйләнеп кайттылар.

Кемнәр күмелгән бу төрбәләрдә? Беренче карашка гади генә тоелган әлеге сорауга җавап табу бик тә четерекле, катлаулы эш булып чыкты. Моның өчен башта Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты өлкән гыйльми хезмәткәре И.Р.Газимҗанов җитәкчелегендә Казан, Мәскәү, Самара антропологларыннан торган махсус төркем оештырылды, чөнки каберләрдән чыккан сөякләр антропологик яктан әле бөтенләй өйрәнелмәгән иде. А.Х.Халиковның 1977 елгы казу эшләре турындагы отчётларын, архив материалларын, Тарих институты фондларында сакланган табылдыкларны яңадан тикшереп чыктык, Казан ханнарына кагылышлы язма чыганакларны барладык. Әлеге тикшеренүләрнең нәтиҗәсе 1997 елда басылып чыккан «Казан Кремле төрбәләре» исемле фәнни җыентыкта дөнья күрде [2].

2004-2005 елларда Казан ханнарының төрбәсен археологик яктан өйрәнүне дәвам иттек. Төрбәнең А.Х.Халиков казып өлгермәгән көньяк-көнбатыш ягындагы мәйданы яңа казылма табылдыкларга бай булды. Без, ниһаять, таш төрбәнең сакланып калган нигезләрен тулысынча ачып бетердек, өстәмә дүрт каберлек урыны билгеләнде [3]. Борынгы Казан тарихын өйрәнүдә әлеге ачышларның әһәмияте бик зур.

Археологлар казып тапкан таш төрбәдә кайсы ханнар күмелгән, дигән сорауга җавап эзләү өчен, безнең карамакта өч төрле чыганак бар. Археологик материаллар нигезендә без төрбәнең төзелү һәм анда ачылган мәетләрнең якынча гына булса да күмелү вакытын билгели алабыз. Антропологик тикшеренүләр исә күмелгән ханнарның яшьләрен, буй-сыннарын, кыяфәтләрен, яшәү рәвешләрен, үлем сәбәпләрен ачып сала. Казан ханнарының тәрҗемәи хәлләренә (биографияләренә) кагылышлы язма чыганаклар, кызганыч ки, бик аз сакланган, шулай да археология һәм антропология материалларын өйрәнеп тапкан информацияне тулыландырырга, кайбер очракларда исә төгәллекләр кертергә мөмкинлек бирә.

* * *

1445 елдан алып 1552 елга кадәр яшәп килгән Казан ханлыгының төп халкын элеккеге болгарлар, башкортлар һәм җирле фин-угыр кабиләләре тәшкил иткән. Бер гасырдан аз гына күбрәк вакыт аралыгында Казанда 13 хан хакимлек иткән. Аларның тулы исемнәрен, туган һәм үлгән елларын, хакимлек иткән вакытларын, чыганакларның җитәрлек булмавы сәбәпле, төгәл генә әйтеп булмый. Без белгән мәгълүматлар түбәндәге таблицада китерелә.

Казан Кремле төрбәсендә күмелгән ханнарның исемнәрен ачыклау өчен, башта безгә, язма чыганакларга мөрәҗәгать итеп, алар арасыннан кайсыларының чит җирләрдә үлеп калганлыгын ачыкларга кирәк.

2. Мавзолеи Казанского кремля. (Опыт историко-антропологического анализа) / Отв. редактор Р.С.Хакимов. — Казань, 1997. — 158 с.

3. Ситдиков А.Г., Хузин Ф.Ш., Сивицкий М.В. Новые исследования мавзолея казанских ханов (предварительное сообщение о раскопках 2004-2005 гг.) // Урало-Поволжье в древности и средневековье. Материалы Международ. науч. конф. V Халиковские чтения. — Казань, 2011. — С.222-223.

Олуг Мөхммәднең соңгы еллардагы тормышы һәм хәрбисәяси эшчәнлеге турында аз беләбез. Рус гаскәрләре белән берничә уңышлы сугыштан соң, Казанны алып, анда хан буларак төпләнеп калырга уйласа да (аның бу планын инкарь итеп булмый), нинди-дер сәбәпләр аркасында ул максатына ирешә алмый. Казанны кулга төшергән очракта, бу мөһим вакыйга турында рус елъязмачылары хәбәр итмичә калмас иде.

Олуг Мөхәммәднең 1445 елда үлгәнлеге билгеле. Ни сәбәпле үлгән — мәгълүм түгел. «Казан тарихы» авторы болай яза:

КАЗАН ХАННАРЫНЫҢ ЯШӘҮ ҺӘМ ХАКИМЛЕК ИТҮ ЕЛЛАРЫ

№	Казан ханнарының яшәү еллары	Хакимлек итү еллары	Төрле авторларның вариантлары
1	Мәхмүд	1445–1460 еллар	1445 – 1461; 1445 – 1462; 1445 – 1464; 1445 – 1467.
2	Хәлил ? – 1467	1460 еллар башы – 1467	1461 – 1467; 1462 – 1467; 1464 – 1467
3	Ибраһим ? – 1478	1467 – 1478	1467 – 1479
4	Илһам	1478 – 1487	1479 – 1487
5	Мөхәммәд Әмин 1468 – 1518	1)* 1487 – 1496; 2) 1502 – 1518	1487 – 1495; 1502 – 1519
6	Мамук ? – 1496	1496	1495 – 1496
7	Габделлатыйф 1475 – 1518	1497 – 1502	1496 – 1502
8	Шаһгали 1505 – 1567	1) 1519 – 1521; 2) 1546; 3) 1551 – 1552	
9	Сәхибгәрәй 1500 – 1551	1521 – 1524	
10	Сафагәрәй 1510– 1549	1) 1524 – 1531; 2) 1535 – 1546; 3) 1546 – 1549	1525 – 1530; 1524 – 1532; 1533 – 1546
11	Җангали 1516 – 1535	1532 – 1535	1531 – 1533; 1531 – 1535
12	Үтәмешгәрәй 1546 – 1566	1549 – 1551	1549 – 1552
13	Ядегәр (Ядыгар) 1522 – 1565	1552	

*Кайбер чыганакларда Мөхәммәд Әминнең 1484 һәм 1486 елларда кыска гына вакытта тәхеткә утыруы турында мәгълүматлар бар.

«Умер в Казани с юнейшим своим сыном Ягупом: оба ножем зарезаны от большого сына своего Мамотяка» [4]. «Казан тарихы» авторының әлеге версиясен күп кенә галимнәр хакыйкатькә һич тә туры килми торган уйдырма дип кенә бәялиләр. Арада Мөхәммәд Әминнең, Казан тәхетендә утырмаса да, биредә үлеп калуы һәм күмелгән булуы мөмкин, дигән фикерләр дә бар. Безнең

4. Казанская история // Памятники литературы Древней Руси. Середина XVI века. — М., 1983. — С.326-327.

2005 елгы казуларның көньяктан күренеше

фикеребезчә, ул Кормышта (хәзерге Курмыш — Түбән Новгород өлкәсендә, Иделнең уң як кушылдыгы Сура елгасы буенда урнашкан посёлок) күмелгән булырга тиеш. Соңгы мәртәбә елъязмачылар аны шунда «күздән югалталар».

Илһам (елъязмаларда исеме төрлечә язылган: Алегам, Алехам, Али-хан, Гали-хан) — Ибраһим ханның һәм Фатыйма-Солтанның өлкән улы — 1487 елның 9 июль вакыйгаларыннан соң, ягъни Мәскәү дәүләтенең бөек кенәзе Иван III сугышчылары Казанны яулап алгач, тәхеттән куыла: «царя Алегама изымаша с материю и с его царицею, и с двемя браты и с сестрою, и с его князми, и приведоша их на Москву» [5]. 1517 һәм 1526 елларда Мәскәүдә булып киткән Австрия дипломаты Сигизмунд Герберштейн мәгълүматларына караганда, «бераз вакыт башкалада (Мәскәүдә) тотканнан соң, бөек кенәз аны (Илһамны) Вологдага озата һәм ул анда үзенең соңгы көннәрен үткәрә» [6].

Себер ханы **Мамук** (Шәйбанилар династиясеннән), Мөхәммәд

5. Полное собрание русских летописей. Т.XII. Патриаршая или Никоновская летопись. — М., 1965. — С.218-219.

6. Герберштейн С. Записки о Московии. — М., 1988. — С.170.

1977 һәм 2004-2005 елгы археологик казуларның схематик планы



Әминне 1496 елның ноябрендә беренче мәртәбә тәхеттән куганнан соң, Казанда бары берничә ай гына хакимлек итеп кала. Халык арасында аның абруе булмый, ул Казан хөкүмәтенең үзенә карата оппозициядә торган күренекле әгъзаларын төрмәгә утырта, талаулар белән шөгыльләнә. Шулай бервакыт сугышчылары белән Арча каласына оештырган яудан кайтып кергәч, аны Казан капкаларын ачып шәһәргә кертүче булмый. Мамук хан азсанлы гаскәре белән Себер якларына юл тота. «…Вскоре поеде от Казани восвояси и на пути умре», — дип хәбәр итә Никон елъязмачысы [7].

Касыйм шәһәрендә 1555 елда төзелгән Шаһгали төрбәсе

Габделлатыйф (Абдул-Латиф, Абдыл-Летиф, Абделятиф) — Ибраһим ханның һәм Нур-Солтанның төпчек улы — тәхеткә 1497 елда Иван III тарафыннан утыртылган булса да, мөстәкыйль сәясәт тарафдары буларак, һәрвакытта да Мәскәү мәнфәгатьләреннән чыгып эш йөртми һәм шунлыктан рус воеводалары аны 1502 елның гыйнварында тәхеттән ваз кичәргә мәҗбүр итәләр. Габделлатыйф хан Белоозеро шәһәренә озатыла. Кырым ханы Миңлегәрәйнең катгый таләбе буенча аны 1508 елның гыйнварында тоткынлыктан азат итәләр һәм үз көнен күрер өчен аңа Суздаль тирәсендәге Юрьев-Польской шәһәрен удел рәвешендә «бүләк итәләр». 1512 елның май аенда Габделлатыйф, кырымлыларның Мәскәүгә оештырган явын яклап чыкты, дигән сылтау белән яңадан кулга алына һәм шул ук Белоозерога сөрелә. 1516 елда инде картаеп баручы Мөхәммәд Әмин, хастага калып урынга ята һәм шул сәбәпле Казан тәхетенә варислар мәсьәләсе калкып чыга. Казаннан килгән илчеләрнең түбәнчелек белән бәян ителгән үтенечен искә алып, Габделлатыйфны икенче мәртәбә тоткынлыктан азат итәләр һәм Мәскәүгә якынрак җиргә — Кашира шәһәренә күчерәләр. Көтмәгәндә, ни сәбәптәндер, ул үлеп китә (күрәсең, махсус оештырылган үлем булгандыр). Бу хәл, Никон елъязмачысы хәбәрләренә караганда, 1518 елның 19 ноябрендә була [8].

Сәхибгәрәй (Сахыб-Герай, Саип-Гирей, Сап-Кирей) — Кырым ханы Миңлегәрәйнең һәм элеккеге Казан ханбикәсе Нур-Солтанның улы — Казанда бары тик дүрт ел чамасы гына хакимлек итә. 1524 елда, тәхетне бертуганының яшүсмер улы Сафагәрәйгә тапшырып, туган якларына кайтып китә. 1532 елда Кырым ханы итеп сайлана һәм ике дистә ел чамасы хакимлек итә. 1551 елда Кавказга оештырылган яу вакытында Сафагәрәйнең өлкән улы Бүләкгәрәй тарафыннан үтерелә [9]. М.Г.Худяков китабында китерелгән мәгълүматларга караганда, аның мәетен

7. Полное собрание русских летописей. Т.XII, С.242.

8. Полное собрание русских летописей. Т.XIII. Патриаршая или Никоновская летопись. — М., 1965. — С.28.

9. Инальчик Халиль. Хан и племенная аристократия: Крымское ханство под управлением Сахиб Гирея // Панорама-Форум. — Казань, 1995. — № 3. — С.94.

Кырымга алып кайталар һәм Бакчасарай үзәнлегендә, Чуфут-Кала тавы итәгендә урнашкан Хаҗигәрәй төрбәсендә җирлиләр [10].

Шаһгали (Ших-Алей, Шигалей, Шеале, Шейхали) — Касыйм кенәзе Шәех-Әүлияр һәм нугай кенәзе Ибраһим кызы Шаһи-Солтан улы — Казан тәхетендә өч тапкыр, әмма барлыгы өч ел чамасы гына утыра. Беренчесендә, 1519 елның 1 мартында, аны тәхеткә — әле ул чакта Шаһгалигә унөч яшь кенә була — Мәскәүнең бөек кенәзе Василий III күтәрә. Ике елдан соң ул Казанны ташлап качарга мәҗбүр була, чөнки урындагы оппозиция, русларның артык көчәеп китүенә, үз мәнфәгатьләренең санга сугылмавына ризасызлык белдереп, Шаһгали урынына Кырымнан Сәхибгәрәйне чакырырга карар кыла. Икенче мәртәбәсендә, 1546 елда, Шаһгали Казан тәхетен бер ай гына кулында тотып тора ала. Казанлылар ягыннан бернинди ярдәм һәм хәерхаһлык таба алмыйча, һәрдаим Мәскәү мәнфәгатьләрен генә алга сөреп эш йөртүче һәм шуңа күрә халык алдында аз гына да абруй казана алмаган хан, артык каршылык күрсәтеп тормыйча, тәхетен Сафагәрәйгә калдырып китә. Соңгы тапкырында Шаһгалине Казан тәхетенә 1551 елның 16 августында, биш яше дә тулмаган Үтәмешгәрәй ханны һәм аның әнисе регентша Сөембикәне Мәскәү тоткынлыгына озатып, ханлык җирләренең саллы гына өлешен — Тау ягын тартып алу турындагы «килешүгә» кул куелгач утырталар. Казан ханлыгын Русиягә тыныч юл белән кушу проектын чәлпәрәмә китергән 1552 елның 9 март түнтәрелешенә кадәр хакимлек итә. Аннан соң Шаһгали, Иван IV гаскәрләренә кушылып, 1552 елда Казанны яулап алуда катнаша. Казан җиңелгәннән соң, Касыймга әйләнеп кайта һәм гомеренең соңгы унбиш елын хан дәрәҗәсендә туган йортында үткәрә. Аны, тыныч-имин тормышын бозып, вакыт-вакыт хәрби походларга гына чакырып торалар: 1558, 1562, 1564-1565 елларда ул Ливон сугышында катнаша. 1560 елның 20 апрелендә Касыйм шәһәрендә дөнья куя.

Үтәмешгәрәй (Утамиш, Утямишь-Гирей) — Сафагәрәй һәм нугай морзасы Йосыф кызы Сөембикәнең улы — хан тәхетенә 1549 елның мартында, әтисе үлгәннән соң тәгаенләнә. Әнисе Сөембикә ханбикә Үтәмешгәрәйнең регенты ролен үти — улы балигъ булганчыга кадәр аның исеменнән идарә итә. Хөкүмәттә кырым татарларының роле тагын да үсә, Мәскәү белән Казан арасындагы каршылыклар көчәя бара. 1549 һәм 1550 елларда Казанга оештырылган яуларның уңышсыз тәмамлануы рус патшасы Иван IVне ханлыкны тулысынча буйсындыруның яңа юлларын эзләргә мәҗбүр итә. Башта аны тыныч юл белән кулга төшермәкче булалар. Казанда Мәскәү дәүләте белән солых төзү тарафдарларыннан торган вакытлы хөкүмәт оеша һәм шул хөкүмәт әгъзалары, югарыда әйтелгәнчә, Үтәмешгәрәй белән Сөембикәне руслар кулына тапшырырга мәҗбүр ителәләр. 1551 елның 11 августында тоткыннарны Мәскәүгә озаталар. Мәскәүдә

10. Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. — Казань, 1990. — С.89.

Сөембикәне көчләп Шаһгалигә хатынлыкка бирәләр һәм ул тиздән Касыйм шәһәренә озатыла [11]. Кайбер мәгълүматлар буенча, ул 1557 елда 38 яшендә фани дөнья белән хушлаша [12]. 1553 елның 8 гыйнварында Үтәмешгәрәйне Чудов монастырендә чукындыралар һәм Александр исеме бирәләр. Ул 1566 елның 11 июнендә егерме яшендә вафат була [13]. Җәсәден Мәскәү Кремлендәге Архангел соборына куялар, ул хәзер дә шунда саклана.

Ядегәр (Едигер, Идигер, Ядыгар, Едигирь) — Хаҗитархан ханы Касыймның улы, 1542-1550 елларда Мәскәү кенәзләренә һәм патшасына хезмәт итеп, русларның 1550 елдагы Казанга каршы яуларында катнашкан шәхес. Тәхеткә 1552 елның язында Шаһгалине Казаннан куганнан соң чакырыла. Иң авыр мизгелләрдә дә югалып калмый торган батыр йөрәкле бу хаким Казанны саклауда үзен талантлы оештыручы буларак таныта. Замандашларының әйтүенчә, 1552 елның 2 октябрендә ул бары тик Казанны саклаучыларның катгый басымы аркасында гына исән кала: Ядегәрне алар рус патшасына тапшыралар, үзләре исә, Кремльнең Елга буе капкасыннан (Елбугины ворота) чыгып, соңгы тапкыр сугышу өчен («испить смертную чашу») Казансу буенда тупланган рус яулары өстенә ташланалар [14]. Казанның соңгы ханын Мәскәүгә озаталар. 1553 елның 26 февралендә ул, Симеон исемен алып, православие диненә күчерелә. 1565 елның 26 августында вафат була. Аның җәсәде салынган табутны Чудов монастыреның Благовещение соборына куялар [15].

* * *

Шулай итеп, без кыскача гына булса да төрле елларда Казан тәхетен биләп торган, әмма төрле сәбәпләр аркасында чит

11. Атласи Һ. Себер тарихы. Сөембикә. Казан ханлыгы. — Казан, 1993. — Б.165-179; Полное собрание русских летописей. Т. XIII, С.184.

12. Фәхретдин Р. Казан ханнары. — Казан, 1995. — 144 б.

13. Вельяминов-Зернов В.В. Исследования о Касимовских царях и царевичах. Часть 1. — СПб., 1863. — С.348; Полное собрание русских летописей. Т.XIII. — С.402.

14. Курбский А. История о великом князе Московском // Памятники литературы Древней Руси. Вторая половина XVI века. — М., 1986. — С.259.

15. Полное собрание русских летописей. Т.XIII. — С.398.

Кабер өстенә куелган таш корылманы (мастабаны) өйрәнү барышы

Казан кирмәне мавзолееның каберлегендә табылган хатын-кыз баш сөягенең пластик реконструкциясе. XV-XVI гасырлар.
А.И.Нечвалов реконструкциясе

Алтын Урда чорында күмелгән хатын-кыз кaберендә сакланып калган агач табут

җирләргә китеп дөнья куйган һәм Казан кирмәнендә күмелмәгән ханнарыбызның катлаулы, хәтта, әйтергә мөмкин, фаҗигале язмышлары белән таныштык. Хәзер безнең алда каберләрен Сөембикә манарасы янындагы төрбәдә эзләргә мөмкин булган ханнарның исемлеге: Мәхмүд, Хәлил, Ибраһим, Мөхәммәд Әмин, Җангали, Сафагәрәй. Алар арасыннан икесенең каберлеген археологлар тулысынча ачып өйрәнделәр. Кемнәрнеке ул?

Бу сорауга җавап табу өчен, башта археология һәм антропология материалларына мөрәҗәгать итик.

Башта ук шуны искәртеп куйыйк: профессор А.Х.Халиков үзенең хисабында тикшерелгән каберлекләрнең икесе дә аерым төрбәләрдә урнаштырылганнар дигәнрәк фикер үткәрә. 2004 елдагы казулар нәтиҗәсендә исә барлык каберлекләрнең дә бер зур төрбә эчендә булуы ачыкланды. Бу таш төрбә (аңлашыла ки, аның нигезе һәм кайбер участокларда стенасының аскы өлеше генә сакланып калган) 17,5 х 6,6 м үлчәмдәге турыпочмаклы бина рәвешендә булган. Әмма ул, чыннан да, ике өлештән торган булса кирәк: 3 нче номерлы кабернең төньяк-көнбатыш ягында төрбәне икегә бүлеп куйган стена эзләре бар. Стеналар башлыча төрле зурлыктагы эшкәртелмәгән ташлардан, известь-кызыл балчык кушылмасыннан торган измә кулланып өелгән. Бинаның тышкы фасадын төзегәндә, сирәк булса да махсус эшкәртелгән таш кулланылган. Идәне таш плитәләрдән җәелгән. Күрәсез, бина төзелеш формасы, конструкциясе ягыннан караганда, бик гади, күләме белән артык зур түгел, һәрхәлдә, аны югары архитектура сәнгате истәлеге дип атарга нигез юк. Без аны 1555 елда Касыйм шәһәрендә төзелгән Шаһгали төрбәсе рәвешендәрәк күз алдына китерәбез [16].

16. Халит Н. Мечети средневековой Казани. — Казань, 2011. — С.120-122, 131, рис. 3-20а, 4-8.

Археологик күзәтүләр нигезендә төрбәнең төзелү вакыты XVI йөзнең 60 нчы елларына туры килә дип уйлыйбыз: төрбә белән бәйләнгән бөтен объектлар Казан ханлыгы чорында тупланган III стратиграфик катламда яталар. Шул катламның аскы өлешендә, вак кирпеч, таш, известь һәм кызыл балчык кушылмаларыннан гыйбәрәт төзелеш горизонтында, 1460 елларда сугылган Новгород акчасы табылды. Бу Казанның беренче хакиме Мәхмүд ханның вафаты вакытына туры килә.

2004-2005 елларда үткәрелгән казу эшләре барышында әлеге төрбәдә тагын өч кабер ачылды. Без аларның әлегә берсен дә казып тикшермәдек. Кабер өстенә баскычлап күтәрелә торган кисек пирамида рәвешле артык зур булмаган таш корылмалар (мастаба) куелган. Шунда ук кабер ташлары да урнаштырылган булгандыр, аларның китекләре (эпиграфик язма эзләре белән) берничә урында табылды.

Гомумән алганда, әлеге төрбәдә ун кешенең кабере сакланган. Әмма аларның барысы да ханлык чорына карамый. Мәсәлән, төрбәнең көньяк-көнбатыш стенасы янында, тышкы якта, әле Алтын Урда чорында ук күмелгән хатын-кыз кабере ачылды. Ул шулай ук ике катлы агач табутта ята иде. Күрәсең, биредә әле ханлык чорына кадәр үк дәүләтнең югары катлау кешеләрен күмә торган урын булган һәм алар арасында мәетне ике катлы табут белән күмү йоласы таралган булган.

Төрбәнең үзендә А.Х.Халиков тарафыннан ачылган ике кабер (№№ 3, 5, аларның берсе яшь баланыкы), безнең казылмалардан чыккан бер кабер (№ 4, яшь бала күмелгән) урыс чорына нисбәтле. Хикмәт шунда ки, биредә, хәзерге Сөембикә манарасының көнбатыш ягында, XVI гасырның икенче яртысында руслар чиркәү торгызып куялар (Введение чиркәве, хәзер биредә татар дәүләтчелеге музее урнашкан). Шуның янында гына православие зираты барлыкка килә. Без биредә XVI гасырның икенче яртысында — XVIII гасырларда күмелгән йөздән артык кешенең каберләрен ачтык. XVII-XVIII гасырларда ханнар төрбәсе җимертелгән була инде. Христиан зираты зурайган саен, урын җитмәгәнлектән, үлгән кешеләрне, беренче чиратта, әле чукындырырга да өлгермәгән балаларны, элеккеге ханнар төрбәсенә дә күмә башлаганнар. Бер сабыйның кабере өчен чокырны хәтта төрбә стенасын чокып ясап куйганнар.

Шул ук вакытта 2 нче һәм 3 нче номерлы каберләр арасы буш калдырылган. Булганмы биредә каберләр — төгәл генә әйтүе кыен. Киләчәктә файдалану өчен махсус саклап тотылган җир булуы да бик мөмкин.

Төрбәнең борынгырак көньяк-көнчыгыш өлешендә дүрт (№№1 — 1977, 1-3 — 2005), соңрак салынган төньяк-көнбатыш яртысында ике кабер (№№ 2, 4 — 1977) урнаштырылган. Шулар арасыннан тулысынча казып тикшерелгән ике кабернең берсен (№ 1 — 1977) А.Х.Халиков «Олуг Мөхәммәд яисә аның улы Мәхмүд», икенчесен (№ 2 — 1977) — Сафагәрәй

каберләре белән тиңләштерде. Бу объектларны өстәмә рәвештә тагын да җентекләбрәк, бигрәк тә элеккеге чыганакларга антропологларның ифрат дәрәҗәдә кыйммәтле тикшеренү нәтиҗәләрен дә кушып өйрәнү А.Х.Халиков тарафыннан әйтелгән фикерләргә кайбер төгәллекләр кертте [17].

Олуг Мөхәммәд яки Мәхмүднеке дип саналган кабер, стратиграфия материаллары күрсәткәнчә, чыннан да, Казан ханлыгы чорында тупланган өч катламның нигезендә, икенче төрле итеп әйткәндә, Алтын Урда катламы өстендә ята. Димәк, аның вакытын XV гасыр урталары, йә булмаса, шул ук гасырның икенче яртысы белән билгеләргә була. Сафагәрәйнеке дип исәпләнгән кабер чокырыннан чыккан балчык линзасы А.Х.Халиковның 1977 елгы отчётында шул ук өченче катламда, әмма аның югары (димәк, соңгы) горизонтында дип теркәлгән. Шулай итеп, безне кызыксындырган сорауга җавап эзләү бераз җиңелләшә: төрбәдә күмелгән беренче хан XV гасырның беренче яртысында (төгәлрәге, 1460 елларда), икенчесе XVI гасыр урталарына якынрак чорда идарә иткән.

Хәзер антропологлардан кергән материалларга күз салыйк. Менә аларның төп нәтиҗәләре:

— беренче кабердә күмелгән ханга — 35-39, икенчесендәгесенә 45-50 яшьләр чамасы;

— баш сөякләренең антропологик үзенчәлекләре: Үзәк Азия тибындагы монголоидлар;

— икенче кабердә күмелгән ханның сөякләрендә күпсанлы авыруларның (остеохондроз, сөяк туберкулёзы һ.б.) эзләре сакланган;

— күп кенә антропология, шул исәптән генетика билгеләре буенча ике хан бер-берсе белән якын туганлык мөнәсәбәтендә булганнар [18].

Хәзер инде археология һәм антропология тикшеренүләре биргән нәтиҗәләрне язма чыганаклардан алынган мәгълүматлар белән чагыштырып карыйк.

Олуг Мөхәммәд ханның Казанда үлгән булуы шикле, дип әйткән идек. Һәрхәлдә, язма чыганакларда бу турыда хәбәрләр юк. Бу — беренчедән. Икенчедән, үлгәндә ул олы яшьтә була инде. 1421 елда ук Олуг Мөхәммәд Алтын Урда ханы дәрәҗәсенә күтәрелә, берничә хатыны була, алар 1424 елгы сугышларның берсендә «үтереләләр яисә әсирлеккә алыналар» [19]. Балаларының (кайбер чыганаклар буенча аның җиде баласы булуын беләбез) 1430 елларда ук кайбер сугышларда катнашканлыгы мәгълүм. Шушы фактларны искә алсак, Олуг Мөхәммәд якынча 50 яшьләрдә үлгән, дип фаразларга була. Ә безнең төрбәдәге ханга 35 яшьләр чамасы.

Мәхмүдтән соң идарә иткән **Хәлил** хан кабере дә түгел ул. Кызганычка каршы, аның турында чыганаклар аз. Хәлил хан озак идарә итә алмый: 1460 еллар башында (1462?, 1464?) аны тәхеткә утырталар, 1467 елда вафат була. Балалары булмый.

17. Хузин Ф., Газимзянов И. Историческая атрибутация захоронений из мавзолеев Казанского Кремля // Мавзолеи Казанского Кремля. — Казань, 1997. — С.7-21.

18. Газимзянов И. Краниологическая характеристика материалов из мавзолеев Казанского Кремля // Мавзолеи Казанского Кремля. — Казань, 1997; Медникова М. Итоги остеометрического обследования погребённых в мавзолеях Казанского кремля; её же. Исследование погребений из мавзолеев Казанского Кремля методом рентгенографии // Там же; Бужилова А. Анализ патологических признаков у погребённых в каменных мавзолеях Казанского кремля // там же; Бужилова А., Медникова М. Оценка биологического возраста у погребённых в каменных мавзолеях Казанского Кремля; Рыкушина Г. Одотологическая характеристика погребённых в мавзолеях Казанского Кремля // Там же; Овчинникова О., Овчинников И., Друзина Е. Молекулярно-генетический анализ человеческих

Хәлилнең мангытлар нәселеннән килгән Тимербәк кызы Нур-Солтанга өйләнгән булуы турында хәбәрләр бар [20]. Нурсолтан 1447 еллар тирәсендә туган [21]. Әгәр дә кияүгә 15-16 яшьләрендә чыккан булса (ул заманнарда гадәти күренеш), аның Хәлил белән никахлашуы 1460 еллар башына, ягъни иренең хан булып алган чорына туры килә. Хәлилне 17-18 яшьләрдә өйләндергән булсалар, аның туган елы 1440 еллар башы булырга тиеш.

Димәк, Хәлил хан бик иртә, әле 30 яше дә тулмаган килеш үлеп киткән булып чыга, ә бу әлеге төрбәдәге ханның антропологлар билгеләгән яшенә якын да килми. Сүз уңаеннан әйтеп китик: без югарыда искә алган Сигизмунд Герберштейн үзенең «Язмалар»ында Хәлилне, аның яшьлегенә ишарә итеп, «Халилёк» дип атый.

Мәхмүд ханның кече улы **Ибраһим** хан, энесе Хәлил вафатыннан соң, Казан тәхетендә 11 ел — 1478 елга кадәр утыра. Әмма төрбәнең төзелү вакыты элегрәк чорга карый. Димәк, биредә Ибраһим хан да күмелмәгән булып чыга.

Ниһаять, без А.Х.Халиков тарафыннан әйтелгән фаразга бераз төгәллек кертә алабыз: төрбәдәге иң беренче кабер — **Мәхмүд** ханныкы, Олуг Мөхәммәднеке түгел. Яңа салынган төрбәдә аның каберен уртага урнаштыралар. Соңыннанрак Мәхмүд хан кабереннең уң ягында — ике, сул ягында тагын бер кабер барлыкка килә.

Мәхмүд хан турында да без, кызганычка каршы, бик аз беләбез. 1445 елның җәендә Олуг Мөхәммәднең уллары Мәхмүд һәм Якуб рус җирләренә яу чабалар. Суздаль янындагы бер сугышта алар олуг кенәз Василий II җитәкләгән гаскәрне тармар итәләр, аның үзен кулга алалар һәм ике айдан соң гына, йолым акчасы түләнгәч, әсирлектән азат итәләр [22]. Моңа кадәр исә, 1437 елда, әле яшь-яшь килеш, Мәхмүд әтисе белән Белёв янындагы сугышта катнаша. Менә шушы мәгълүматлардан чыгып, булачак Казан ханы Мәхмүднең 1420 еллар башында туган булуын фаразларга мөмкин. Һәрхәлдә, 1445 елда Казан бәге Галимбәкне үтереп тәхеткә утырганда, ул әле яшь кеше була.

Мәхмүд ханның Казанда хакимлек итә башлавы татар тарихында олы вакыйга булып тора. Ул Казан идарәчеләренең Алтын Урда, ягъни Чыңгыз хан династиясеннән чыккан беренче вәкиле. Казан ханлыгының тәмам оешып бетүе, халыкара мәйданда урын алуы, танылуы нәкъ менә аның исеме белән бәйләнгән. Аның идарә итү еллары икътисад һәм мәдәни тормышның сизелерлек дәрәҗәдә алга китеше белән тарихка кереп калган. М.Г.Худяков язганча, «руслар һәм казанлылар арасындагы тыныч мөнәсәбәтләр Мәхмүд хан хакимлек иткән заманда бер тапкыр да бозылмаган» [23].

* * *

Хәзер инде XVI йөзнең беренче яртысында (башында?) күмелгән ханның кем булуын ачыклыйк. Профессор

останков XV-XVI вв. из каменных мавзолеев Казанского Кремля: экстракция и амплификация ДНК // Там же.

19. Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды // На стыке континентов и цивилизаций. — М., 1996. — С.447-448, 451.

20. Герберштейн С. Записки о Московии. — М., 1988. — С.170.

21. Герберштейн С. Записки о Московии… — С.239; шулай ук карагыз: Бережков М. Нур-Салтан, царица крымская (историко-биографический очерк) // Известия Таврической учёной архивной комиссии. № 27. — Симферополь, 1897.

22. Полное собрание русских летописей. Т.XIII. — С.64 и сл.

23. Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. — С.34.

А.Х.Халиков, бу төрбә, һичшиксез, Казанның соңгы ханнарыннан берсе, 1549 елда вафат булган **Сафагәрәй** ханныкы булырга тиеш, дип яза. Аның дәлилләрен тикшереп үтик. Беренчедән, ди ул, ак таштан салына башлаган төрбә яртылаш төзелгән хәлендә калган, чөнки 1549 һәм аннан соңгы еллар ханлык тарихында иң хәвефле, фаҗигале еллар һәм бу шартларда төрбәне ахыргача корып бетерү мөмкин булмаган. Әмма бу дәлил археологик фактлар белән берничек тә исбатланмый: әлеге төрбә бик начар, хәрабәләр хәлендә генә сакланган. Төзелеп беткәнме ул, юкмы — моны инде берәү дә тәгаен генә әйтә алмый. Югарыда әйтеп үтелгәнчә, һәр хан өчен аерым төрбә кормаганнар ич, димәк ул, Сафагәрәй, инде аңа кадәр күптән төзеп куелган төрбәдә күмелгән булырга тиеш.

Икенчедән, дип яза безнең мөхтәрәм галимебез, әлеге төрбә хәзинә эзләүчеләр тарафыннын яхшы гына таланган. «Чордашлары калдырган хәбәрләргә караганда, — дип дәвам итә ул, — 1552 елның 2 октябрендә, Казан Кремлендә аяусыз сугышлар барганда, рус яугирләре гади йортларга һәм Хан сараена гына түгел, бәлки, алтын-көмеш эзләп, хан төрбәләренә дә үтеп керәләр, Сафагәрәйнең каберен талыйлар» [24]. Бусы да артык ышандырмый. Таланган, дөресрәге, соңгырак чорларда төрле сәбәпләр аркасында җимертелгән каберләр берәү генә түгел. Аннан соң, мөселманнарның кабергә алтын-көмеш салып күммәгәннәрен ул заманнарда да белгәннәр бит инде.

А.Х.Халиковның соңгы дәлиле Сафагәрәйнең ничек, нинди шартларда үлүе белән бәйле. «Казан тарихы»н язган XVI йөзнең билгесез авторы сүзләренә ышансак, Сафагәрәй исерек хәлендә юыну бүлмәсенә керә һәм комганы, ялгыш төшеп китеп, башына эләгә, шуннан җан тәслим кыла, имеш («ныне же, пьян, лице своё и руце умываше и напрсно занесёся ногами своима, и главою о умывалничный теремец ударися до мозгу, и о землю весь разразися, и все составы тела его разслабишася, и не успевшим его предстоящим скоро подхватити. И от того умре того же дни...») [25]. Бу — юк-бар уйдырма гына, әлбәттә. Казанның иң атаклы, мәшһүр ханын, Мәскәүнең башимәс куркыныч дошманын, һичшиксез, үтергәннәр. Әлбәттә, бу фаҗигале үлем мәетнең баш сөягендәме, башка җирендәме (әгәр дә буып үтермәгән булсалар) нинди дә булса яра эзе калдырырга тиеш иде. Һәм ул, чыннан да, бар кебек. А.Х.Халиков аны «Казан тарихы»нда китерелгән сүзләрнең хакыйкатькә туры килүе дип бәяли. Әмма антропологлар фикеренчә, баш сөяге ханның үлеменнән соң күп вакытлар үткәч чәрдәкләнгән, димәк ки, бу «яра эзе» үлемнең сәбәбе була алмый [26].

Күрәсез, әлеге кабернең Сафагәрәйнеке булмавына дәлилләр шактый җыела. Аларның иң җитдие исә — шул кабердә күмелгән ханның яше. Ул 45-50 яшьләрдә үлгән. Антропологларның әйтүләре буенча, әлеге скелет сөягендә күзәтелгән кайбер патологик билгеләр кешеләрдә 50 яшьтән соң гына барлыкка

24. Халиков А.Х. Что, башня, в имени твоём.., С.64.

25. Казанская история.., С. 382.

26. Бужилова А. Анализ патологических признаков.., С.113.

Казан ханнары Мәхмүднең (сулда) һәм Мөхәммәд Әминнең (уңда) скульптур портретлары. Антрополог Т.Балуева реконструкциясе

киләләр икән. Сафагәрәйгә исә үлгәндә әле 40 яшь тә тулмаган була. Ул 1510 елда туган [27]. Абыйсы (әтисенең энесе) Сәхибгәрәй 13 яшендә аны Казан тәхетенә утырта. Сафагәрәй Казанда барлыгы 20 елдан артык ханлык итә, бөтен көчен Казанның мөстәкыйльлеген яклауга, Мәскәү илбасарларына каршы көрәшкә багышлый.

Шулай итеп, икенче төрбәнең «хуҗасы» XVI гасырның беренче яртысында Казан дәүләте белән идарә иткән ике ханның берсе — йә Җангали, йә Мөхәммәд Әмин генә булырга мөмкин.

Касыйм ханы Шәйх-Әүлиярның улы, инде сезгә мәгълүм Шаһгалинең бертуган энесе **Җангали** 1516 елда туган һәм 16 яше тулар-тулмас борын Казан тәхетенә утыртылган [28]. Аны 17 яшендә нугай морзасы Йосыфның кызы Сөембикәгә өйләндерәләр. Җангали хан 1535 елның 25 сентябрендә үтерелә [29]. Бу вакытта аңа әле 19 яшь кенә була.

Соравыбызга җавап табу өчен, атаклы дәүләт эшлеклесе, әсәрләре халык арасында абруй казанган (һәм безнең көннәргә кадәр килеп җиткән [30]) күренекле шагыйрь һәм язучы **Мөхәммәд Әмин** хан шәхесенә генә мөрәҗәгать итәсе кала.

Тарихи чыганакларда күрсәтелгәнчә, 1478 елда, Ибраһим хан үлеменнән соң, аның өлкән улы Илһамны тәхеткә утырткач, икенче улын, 10 яшьлек Мөхәммәд Әминне, әнисеннән аерып, мәҗбүри Мәскәүгә озаталар. Ул анда олуг кенәз Иван III хозурында тәрбияләнә. 1487 елда, Казан каласы руслар тарафыннан яулап алынганнан соң, тәхеткә нәкъ менә Мөхәммәд Әминне тәгаенлиләр. Рус илендә тәрбияләнгән ич, сүз тыңлаучан булыр, янәсе. Казанда Мәскәү протектораты урнаша, ягъни ханнарыбыз Россиядән ярым буйсынып яшәргә мәҗбүр ителәләр. Чыннан да, 1487-1496 елларны эченә алган идарә итү чорында Мөхәммәд Әмин үзен русларның чын дусты итеп күрсәтә. Әмма соңыннан, 1505 елдан башлап, ул Мәскәү контроленнән чыга, сәясәтен кискен үзгәртеп, мөстәкыйль идарә итү юлына баса.

27. Атласи Һ. Себер тарихы. Сөембикә. Казан ханлыгы.., Б.284., Б.333.; Худяков М.Г. Очерки по истории.., С.90.

28. Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства.., С.96; Казанская история… — С.356-357.

29. Полное собрание русских летописей. Т. XIII… — С.100.

30. Татар әдәбияты тарихы. Том I. Урта гасырлар дәвере. — Казан, 1984. — Б.291-292.



Олуг Мөхәммәд һәм Гәрәйләр (Кырым) династиясеннән чыккан Казан ханнарының нәсел җебе (М.Г.Сәфәргалиев һәм М.Г.Худяков буенча)

Күп еллар үткәч, Мөхәммәд Әминнең шушы «хыянәтен» искә алып, югарыда телгә алынган «Казан тарихы» авторы «кире беткән» Казан ханының каты авыруын тискәрелеге өчен Аллаһ тарафыннан җибәрелгән гадел җәза, дип бәяли («И за сие преступление порази его бог язвою неисцелною от главы и до ногу его») [31]. Мөхәммәд Әмин, чыннан да, озак һәм каты авырый. Рус елъязмачылары аның авыруы турында 1516 елда ук хәбәр итәләр. Хан өч ел буе урын өстендә ята, аяклары, тәннәре сызлый, йөрерлек хәле дә калмый. «Казан тарихы» авторы авыруның хәлен болай тасвирлый (бераз арттырыбрак һәм явыз күлеп, әлбәттә): «Люте тяжело боляше три лета, на одре лежа, весь кипя гноем и червьми. Врачеве же и волхвы не возмогаша от язвы тоя изцелити. И нихто к нему в ложницу (спальню) не вхождаше посетити его: но ни та царица, прелстившая его, ни

31. Казанская история, С.338-339.

32. Там же.

болшие рядцы (советники), смрада ради злаго, изходящего от него» [32]. Антропологларның икенче төрбәдә күмелгән ханга кагылышлы тикшерү нәтиҗәләрен искә төшерик: сөяктә остеохондроз билгеләре сакланган, мәрхүмнең организмында хроник ялкынсыну процессы барган, бизгәк һәм сөяк туберкулёзы белән дә интеккән булуы ихтимал.

Илле яшен тутырган Мөхәммәд Әмин 1518 елның декабрендә фани дөнья белән хушлаша, мәңгелеккә китеп бара. Ул төрбәнең төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан 2 нче номерлы кабердә күмелгән дип уйлыйбыз.

Баш сөякләрен антрополог М.М.Герасимов ысулы белән реконструкцияләп, аларның скульптура портретын ясагач, галимнәр бу ике портретның бер-берсенә бик охшаш булуын күреп гаҗәпләнделәр. Алар бу охшашлыкны Мәхмүд хан белән Мөхәммәд Әмин ханның бик якын генетик туганлыгы белән аңлаталар. Бу фикерне Казан ханнарының нәсел җебе бик яхшы күрсәтеп тора: Мәхмүд хан — Мөхәммәд Әминнең бабасы.

* * *

Шулай итеп, озак һәм җентекле тикшеренүләр нәтиҗәсендә, без Казан Кремлендәге ханнар төрбәсендә күмелгән Мәхмүд һәм Мөхәммәд Әмин ханнарның каберләрен ачыклый алдык. Хәлил, Ибраһим, Җангали һәм Сафагәрәй күмелгән каберләр нең дә урыны билгеле, әмма кемнең кайсы кабердә ятканлыгын тәгаен генә әйтә алмыйбыз. Әлегә ул каберләрне казып, рухларын рәнҗетмәскә булдык. Сөякләрен казып чыгарып, аларны төрле ысуллар кулланып өйрәнгән очракта да нәтиҗәләребез дөрес булыр дип гарантия бирә алмыйбыз. Бусы — киләчәк эше.

Ә хәзер мәкаләбезнең ахырында бүген хәл итәргә кирәкле бер пробеманы «Казан Кремле» музей-тыюлыгы җитәкчеләренә яңадан — инде ничәнче мәртәбә! — искә төшереп үтәсе килә. 1977 елдан бирле, ягъни менә 35 ел инде, ханнарыбызның сөякләре археология фондларында тузан җыеп ята. Әлбәттә, бу ярый торган эш түгел. Әхлаксызлыгыбызның бер билгесе бу. Безнең казылмаларыбызны күмеп куймыйча, анда ачылган төрбәне, ничек бар — шул көе, бернинди үзгәреш кертмичә, килгән туристларга-экскурсантларга карау мөмкинлеге тудырып, пыяла колпак белән ябып куйдылар. Бик әйбәт эшләделәр, рәхмәт тыюлык җитәкчеләренә бу хезмәтләре өчен! Халык ташкындай агыла бирегә, кызыксыналар, ерак бабаларыбыз рухына дога кылып китәләр. Хәзер инде менә шул төрбәгә ике ханыбызның җәсәден, музей фондларыннан күчереп, үз урыннарына күмәсе иде бит, җәмәгать! Артык шауламыйча гына, олы тантаналарсыз гына.

Иншаллаһ, бусы да булыр, сүзләребезгә колак салырлар, дип өметләнеп калабыз.

КАЗАН – ХАНЛЫК БАШКАЛАСЫ

АЙРАТ СИТДЫЙКОВ,
тарих фәннәре кандидаты,
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының
Археологик тикшеренүләр үзәге җитәкчесе

Инде күптән яшәп, ниндидер сәбәпләр аркасында юкка чыккан борынгы дәүләтләр һәм цивилизацияләр тарихы серләр һәм легенда-риваятьләр белән чорналган була. Алар рәтенә, һичшиксез, иксез-чиксез Евразия далаларында дәүләт токкан төрки халыкларның, Идел Болгары һәм Алтын Урда кебек элгәреләренең мецьеллык традицияләрен туплаган Казан ханлыгы да керә.

Нинди булган ул Казан ханлыгының башкаласы? Безнең көннәргә кадәр шул ерак тарихның шаһиты булырдай истәлекләр сакланып калганмы? Унсигезенче йөзләрдән башлап галимнәребез шул сорауларга җавап эзлиләр, Казанның борынгы төсен-кыяфәтен объектив рәвештә, ничек булган шулай күз алдына китереп карарга тырышалар. Аларның озак еллар буе бөртекләп җыйган тарихи чыганаклары, мәгълүматлары яктылыгында ханлык чоры Казанының тышкы кыяфәтен бераз чамаларга мөмкинлек туа, ә фантазиягә бай язучыларыбыз,

рәссамнарыбыз исә аны хәтта сүзләр, төсләр белән матур итеп сурәтләп-тасвирлап та бирәләр. Һәм ышандыралар да, чөнки… ышанасы килә.

Ханлык чоры Казанына археологлар күзлеге аша карап алыйк.

Әле X-XI гасырлар чигендә үк хәзерге Кремль калкулыгының төньяк өлешендә, Казансуның сулъяк ярында барлыкка килгән урта гасырлар Казаны көчле саклану ныгытмалары белән уратып алынган кирмән-шәһәр рәвешендә үсүен дәвам итә. Калага нигез салыр алдыннан ук инде, аның булачак урынын сайлаганда, борынгы болгар бабаларыбыз ашыкмыйча, төптән уйлап, тирән акыл белән эш йөрткәннәр. Шәһәрне табигать үзе саклый кебек: төньяктан һәм көнчыгыштан, текә ярлы биек калкулык итәгеннән, дулкынланып Казансу ага, көнбатыш ягында — сай сулы, төбе калын ләм белән капланган, кайбер урыннарда сазлыклы, урыны-урыны белән үтеп чыга алмаслык, ярсып килгән дошман чирүен, үзләре дә сизмәстән, кинәт кенә тоткарлый алырлык Болак елгасы. Әйе, хәрби-стратегик яктан караганда, элгәреге кирмән-крепостьның урыны тел-теш тидерерлек түгел. Әле бит ул әллә кайчан инде Бөек сәүдә юлы буларак танылган, халыклар белән халыкларны берләштерүче, илләр белән илләрне тоташтыручы Иделгә дә бик якын.

* * *

XV йөзләр уртасында Казанның административ-сәяси дәрәҗәсе күтәрелү, табигый ки, аның үсешенә нык йогынты ясый. Шәһәр биләмәләре, элеккеге кирмән чикләреннән чыгып, тагын да киңәя, Таҗик чокыры тирәсендә, Ташаяк урамында базарлар, тире һәм күн эшкәртү, чүлмәк ясау, металлургия һәм зәркәнчелек белән бәйле һөнәрчелек бистәләре, Көрәеш, Бишбалта кебек шәһәр яны посёлоклары барлыкка килә, халык саны күзгә күренеп арта. XVI йөз урталарында, безнең исәпләүләр буенча, шәһәр инде 60-70 гектар мәйданда урнашкан булган һәм биредә 15-20 мең чамасы кеше яшәгән. Заманы өчен зур гына шәһәр булган ул.

Ханлык чорында Казанның эчке планировкасында, бигрәк тә саклану корылмаларының урнашу тәртибендә, сизелерлек үзгәрешләр барлыкка килә, шул ук вакытта монголларга кадәрге һәм аннан соңгы Алтын Урда чорларында калыплашкан структура да юкка чыкмый: югары хакимият һәм мөселман дине башлыкларының административ биналары элеккечә шәһәрнең иң көчле ныгытылган төньяк өлешен — ун гектар чамасы мәйданны биләп торган кирмән алып торган, көньяк тарафында исә, кирмән ныгытмаларына терәлеп диярлек урнашкан бистәләрдә, хакимият белән турыдан-туры бәйләнмәгән бай катлау кешеләренең утарлары, гади шәһәр халкының йортлары тезелеп киткән.

1.

3.

1. XXXV казылма. Ак таш манара калдыклары. XVI гасырның I яртысы

2. XIII казылма. Корылмалар: 28 (агач түшәлгән юл өлеше), 29

3. Казан ханнары мавзолееның көньяк өлеше казылмалары

4.XLIII казылманың гомуми күренеше һәм хан сараеның планы



2. (28, 29)



4.

Фонтан нигезе. XIX гасырның II яртысы

Хан сарае. XV йөз – XVI гасырның I яртысы

Яшәү корылмасының нигезе. XIX гасыр башы

Казанның әле ныгытылмаган бистәләре (посады) беренче мәртәбә 1469 елга караган язма чыганакларда, воевода И.Д.Рун җитәкчелегендәге урыс гаскәрләренең шәһәрне басып алу вакыйгасы уңаеннан телгә алына [1]. 1500 елда, шул ук документ язуларына караганда, Габделлатыйф хан бистәләрне ныгытырга әмер бирә («повеле около града нарядити острог») [2]. Шул ук хан заманында суднолар йөреше уңайлы булсын өчен, Болак елгасы да чистартыла. 1530 елгы Казан сугышы турында сүз барганда, язма чыганаклар Сафагәрәй ханның бистә ныгытмаларын тагын да көчлерәк итәргә тырышуы хакында хәбәр итәләр («около посаду по Арскому полю, от Булака и до Казани реки, округ его рвы копайте по-за острогу») [3].

Документлардан мәгълүм булганча, 1552 елгы штурм вакытында иң көчле сугышлар Кремль калкулыгының көньяк-көнчыгыш өлешенә якынрак җирдә урнашкан Арча кырында җәелеп китә. Иван IVнең Шаһгали җитәкчелегендәге Олы полкы, алдан ук уйланылган яу планы нигезендә, шул тирәдәге мөселман зираты янына куела [4]. 1565-1568 елларда төзелгән Писцовая кенәгәдә күрсәтелгәнчә, әлеге зират хәзерге Казан (Идел буе) федераль университетының төп бинасы ишегалдында булган [5]. Шәһәр бистәсе (посад) ныгытмаларын торгызганда, табигый чик булып хәзерге Астрономия урамы буйлап сузылган чокыр хезмәт иткән. Бу ныгытмаларның калдыклары җирдән өелгән вал һәм тирән чокыр рәвешендә 1982 елда Казан университетының күпкатлы хәзерге Физика институты бинасын төзегәндә ачылды [6].

Көнбатыштан, Болак ягыннан үткән посад диварларының урнашу тәртибе турындагы мәсьәлә һаман да бәхәсле булып кала. Ныгытмаларның әлеге өлешен XVIII йөздә үк Ю. фон Каниц һәм П.Рычков тарафыннан тәкъдим ителгән реконструкциягә карап бераз күзалларга мөмкин [7]. Никон елъязмасы, Иван IVнең сугышчан полкларын Казанга штурм алдыннан ничек урнаштырылулары турында сөйләгәндә, уң як Болак буйлап тезелеп киткән күпсанлы рус гаскәрләрен телгә ала [8]. Шул мәгълүматлардан чыгып, посад диварларының көнбатыш өлеше хәзерге Бауман урамыннан аз гына югарырак, Астрономия һәм Профсоюз урамнары кисешкән урыннан башлап, тау итәгенә параллель рәвештә, Ташаяк урамына кадәр сузылган булгандыр дип уйларга нигез бар.

Посад диварларының көнчыгыш өлеше исә шул ук Астрономия һәм Профсоюз урамнары кисешкән урыннан Ленин бакчасына, шуннан Ирек мәйданын үтеп, башта Тельман, аннан соң Нагорная урамнары буйлап Кремльнең Дмитрий капкасына килеп тоташкан дип фаразлана.

Кайбер яңа археологик күзәтүләргә нигезләнеп, А.Х.Халиков һәм Л.С.Шавохин язма чыганакларда телгә алынган фактларны үзләренчә аңлата [9]. Аларга кадәрге тарихчылар фикеренчә,

1. Древняя Казань глазами современников и историков / сост. Ф.Ш.Хузин, А.Г.Ситдиков. — Казань, 1996. — С.20.

2. Шунда ук. — Б.23.

3. Шунда ук. — Б.25, 76-78.

4. Шунда ук. — Б.37, 44.

5. Калинин Н.Ф. История Казани с древнейших времён до XVI в. Рукопись док. дисс. // Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кулъязмалар бүлеге архивы. — Ф. 8, оп. 1, ед. хр. 202; Писцовые книги города Казани 1565-1568 гг. и 1646 г. // Материалы по истории народов СССР. Вып. 2. Материалы по истории Татарской АССР. (Тр. Ист.-археограф. ин-та). — М., 1932. — С.45.

6. Халиков А.Х. История археологического изучения г. Казани // Средневековые археологические памятники Татарии. — Казань, 1983. — С.111 и сл. (Бу урында киңрәк күләмле археологик казу

Иван IV үзенең гаскәрләрен Арча кыры белән «Иске шәһәрлек» («Старое городище») арасындагы стеналар буйлап урнаштырган. Ә «Иске шәһәр», имеш, ханлык чорында Фёдор калкулыгын (Фёдоровский бугор — хәзерге «Казан» Милли-мәдәни үзәге бинасын төзегәндә җимертелгән) биләп торган. Ә бит дөреслеге шик тудырмый торган кайбер чыганакларда «Иске шәһәр» дип Богородица монастыре территориясе аталган [10]. Шәһәрне камаган вакытта рус гаскәрләренең Черек күл (Поганое озеро) тирәсендә торганлыгын күрсәтеп үтү дә мөһим [11]. Шулай итеп, Черек күл посад диварлары эчендә булып чыга. Ә менә 1970-1990 елларда тупланган археология материаллары Фёдор калкулыгының XVII гасырларда гына үзләштерелә башлаганлыгын күрсәттеләр, шул ук вакытта Богородица монастыре территориясендә болгар-татар чорына караган культура катламы ачылды [12]. Пассаж бинасы янында (Дзержинский урамы ягыннан) борынгы ныгытма калдыклары табылуын да әйтеп үтү кирәктер [13]. Шулай итеп, шәһәр посадының көнчыгыш сызыгы чынлыкта Дзержинский урамының Лобачевский урамы белән кисешкән урыныннан башлап Кремльгә кадәр булган арада тәгаенләнә.

Саклану ныгытмалары турында сөйләгәндә, шәһәргә (посад территориясенә) һәм кирмәнгә (Кремльгә) алып керә торган капкаларның урнашу тәртибенә дә бераз тукталып китәргә кирәк дип уйлыбыз. Аларның төгәл санын атау кыен. «Царственная книга»да ун капканың исеме күрсәтелгән: Арча, Аталык, Алабуга («Елбугины» — Елга буе), Збойливые, Кабак (Кабацкие), Кырым, Нургали (Нур-Али, Муралеевы), Нугай, Түбән, Хан (Царевы) капкалары [14]. Билгесез авторның «Казан тарихы»нда да ун капка санала, әмма аларның исемнәре башкачарак бирелгән: өч Арча капкасы, Алабуга, Збойливые, Кәбәк (Кебекевы), Нургали, Түбән һәм Югары Нугай, Хан һәм Су (Водяные) капкалары [15]. Хаҗи Шәрәфи үзенең 1549 елгы сугыш вакыйгалары турында язылган әсәрендә казанлыларның алты капканы саклау өчен көрәшкәннәрен әйтеп уза [16]. Аларның берсен ул Хан капкасы дип атый. Андрей Курбский язмаларыннан күренгәнчә, Алабуга капкасы Казансу аша салынган күпер янында булган [17]. 1565-1568 елларга караган Писцовая кенәгә буенча без 1552 елдан соң руслар тарафыннан элеккеге татар капкалары урынында торгызылган биш капканың кай тирәдәрәк урнашканлыгын чамалый алабыз.

Кремльнең бүгенге көнгә кадәр элеккеге рәвешен саклап калганлыгын игътибарга алып һәм әле генә санап үтелгән чыганакларга таянып, без Казан капкаларының урынын түбәндәгечә күрсәтәбез: хәзерге Тайницкий (Никольский) капкасы хан заманында — Нургали (Нур-Али), Воскресение капкасы — Алабуга (дөресрәге — Елга буе, ягъни Водяные), Преображение (Сереевские) капкасы Түбән исемнәре белән аталган. Бүгенге

эшләре үткәреп, фараз рәвешендә генә әйтелгән әлеге фикерне кабат бер мәртәбә тикшерү сорала).

7. Каниц Ю. Краткое изъяснение плана древнего города Казани и описание осады и покорения оного // Сборник древностей Казанской епархии П.Любарского. Православный собеседник. — Казань, 1868. — С.117, 127-128; Рычков П. Опыт Казанской истории древних и средних времён. — СПб., 1767; Хузин Ф.Ш. Древняя Казань в документах и материалах // Эхо веков — Гасырлар авазы. — 1995. — С.34-35.

8. Древняя Казань глазами современников… — С.38.

9. История Казани. Книга 1. — Казань, 1983; Шавохин Л.С. Средневековая Казань дорусского времени в историко-археологическом отношении. Дисс… канд. ист. наук. — Казань, 1988.

10. Писцовые книги города Казани 1565-1568 гг. и 1646 г…

11. Древняя Казань глазами современников… — С.29.

Дмитрий (Дмитриевские) яисә посадның Пятницкий капкасы янында (Батурин, Зур Кызыл һәм Нагорная урамнары кисешкән җирдә) Збойливые дип аталган капка торган дип фаразларга мөмкин. Безнең фикеребезчә, Хан (Царевы) капкасы Кремль калкулыгының көньяк өлешендә, хәзерге Кремль һәм Лобачевский урамнары кисешкән чатта урнашкан булырга тиеш.

Калган капкаларның урынын, җитәрлек чыганаклар булмау сәбәпле, ачыклау кыенрак. Хан капкасыннан көнчыгыш тарафта чыганаклар еш кына Арча капкасын күрсәтәләр. Аның хәзерге Дзержинский һәм Лобачевский урамнары чатында урнашкан булуы мөмкин. Арча һәм Збойливые капкалары арасында, Дзержинский урамының көнбатыш ягында, 1552 елгы штурм вакыйгаларын сурәтләгән язмаларда Кабак һәм Кырым капкалары телгә алына [18].

Посадның көнбатыш өлешендә, Хан һәм Төмән капкалары арасында язма чыганаклар Аталык, Нугай капкаларын билгеләп үтәләр [19]. Аталык капкасы Төмән капкасыннан түбәндәрәк, Болак елгасы үзәненә якынрак җирдә торгандыр дип уйларга нигез бар. Сүз уңаеннан, русларның нәкъ шул тирәдә кирмән диварларын шартлату максатында дары кую өчен казылган җир асты юлы булганлыгын да искә төшереп үтәсе килә. Нугай капкасы исә Профсоюз (Малая Проломная) яисә Бауман (Большая Проломная) урамнарының Астрономия урамы белән кисешкән урында, Нугай юлы өстендә булган дип фаразлана.

Посад диварлары, безнең кулда булган чыганакларга карап фикер йөртсәк, тараслар, ягъни эчләренә балчык, ком-таш тутырылган агач буралар тезмәсеннән торган булырга тиеш. «Со-гражден в седмь стен, в велицех и толстых древесех: в стенах же ссыпан внутри хрящ и песок и мелкое каменье, толстина же градная от рек, от Казани и от Булака, трех спжен, и те бо места ратным непреступны...», дип яза «Казан тарихы»ның авторы әлеге ныгытмалар турында [20]. Диварларның буеннан буена киңлеге 8-10, тирәнлеге 3-4, кайбер урыннарда 10-15 метрга җитә торган чокырлар казылган булган: «...и яко крепкими стенами и водами вкруг обведет бе град, и токмо со единая града с поля Арского приступ мал, но туда стена градная была в тостоту в 7 сажен и перекопана около ея стремина (яма) велия, глубока» [21]. А.Х.Халиков Лобачевский урамындагы 3 нче номерлы йортның ишегалдында, Черек күлгә якын гына җирдә казыганда, биеклеге 8 метрга җитә торган вал һәм аның алдында тирән чокыр эзләре таба. Нәкъ менә шул ныгытмаларны «Казан елъязмачысы» да искә алып үтә: «А от той реки (Булака. — *А.С.*) около места ров копан зело глубокий аж до озерка, реченого протокою» [22].

12. Халиков А.Х. Отчёт об археологических наблюдениях в Казани в 1985 г. // Татарстан Фәннәр академиясе Ш.Мәрҗани ис. Тарих институтның Археологик тикшеренүләр үзәге архивы; Ситдиков А.Г. А.Х.Халиков — исследователь средневековой Казани // Проблемы древней и средневековой археологии Волго-Камья. — Казань, 1999. — С.35 и сл.

13. История Казани... — С.32.

14. Полное собрание русских летописей. Т.XIII. Патриаршая или Никоновская летопись. — М., 1965. — С.200-221.

15. Казанская история // Памятники литературы Древней Руси. Середина XVI века. — М., 1985. — С.310-539.

16. Шерефи Х. Зафер-наме-и вилайет-и Казан // Эхо веков — Гасырлар авазы. — 1995. — С.83-92.

17. Курбский А. История о великом князе московском //

* * *

Ханлык чорында Казан кирмәненең эчке планировкасы кайбер үзгәрешләр кичерә. Дөрес, элегрәк барлыкка килгән урамнар шул килеш кала, аларда яңа йортлар гына калкып чыга. Үзәк урам таш плитәләр, калганнары агач такталар (кыртышлар) белән түшәлгән була. Монголларга кадәр үк табигый саклану чарасы буларак файдаланылган чокырларны, шул исәптән Таҗик чокырының да бер өлешен күмеп куялар. Кирмәннең иң борынгы, төньяк өлешендә яңа таш биналар төзелә. 1552 елда Казанны камау вакыйгаларын сурәтләгән язмаларда Хан сарае тирәсендәге урыннарда күпсанлы таш биналар телгә алына.

Кирмәннең мәйданын киңәйтәләр, аның көньяк чиге хан заманында почмак манара сыйфатында торгызылган Түбән башнясына кадәр барып җитә (борынгы ныгытма калдыклары 1947, 2003 елларда ачылды).

Ф.Ш.Хуҗин җитәкчелегендәге Казан Кремле археологик экспедициясе тарафыннан 2001-2003 елларда үткәрелгән казу эшләре вакытында кирмәннең төньяк диварлары тикшерелде. XVI гасырның икенче яртысында төзелгән һәм инде бүгенге көннәргә кадәр сакланмаган түгәрәк башня нигезе астында археологлар, һич көтмәгәндә, тагын да борынгырак, ханлык чорында салынган квадрат (8,7 х 9,6 м) башня хәрабәләренә юлыктылар. Ул таштан салынган, 1552 елгы штурм вакытында нык җимертелгән, диварларының сакланып калган биеклеге 3-4 метр чамасы [23]. Күрәсең, бу башня Казан-Мәскәү арасындагы хәрби-сәяси мөнәсәбәтләр кискенләшеп барган чорда, 1540 елларда төзелгәндер. Башняның ике ягыннан шул ук елларда салына башлаган таш диварлар китә, әмма аларны бөтен кирмәнне уратып алырлык итеп торгызып бетерергә өлгерми калганнар.

Борынгы Казан тарихы белән шөгыльләнүче кайбер галимнәр Казанның хан резиденциясеннән кала аерым кирмәне, ягъни Кремле булмаган, ул тулаем бер өлештән генә торган дип язып чыкканнар иде [24]. Имештер, 1552 елның 2 октябрь вакыйгалары бәян ителгән язмаларда Кол Шәриф сәетнең шәкертләре белән русларга каршы каһарманнарча көрәшеннән башка кирмәнне штурмлау турында бер сүз дә юк. Без бу фикергә кушылмыйбыз, чөнки археология материаллары да, язма чыганаклар да киресен сөйли. Андрей Курбский үзе үк шәһәрнең өч өлештән торганлыгын искәртеп үтә, аның ике өлеше (кирмән һәм аның эчендәге хан сарае) — тау башында, өченчесе (посад, бистәләр) — тигез җирдә, үзәнлектә, ди [25]. Ә «Казан тарихы» авторы шәһәрнең тау башындагы өлешен «Вышгород» дип атый [26]. 1469, 1500, 1530 елларда Казанны алырга килгән рус гаскәрләре шәһәрнең посадына үтеп керәләр,

Памятники литературы Древней Руси. Вторая половина XVI века. — М., 1986. — С.229-280.

18. Древняя Казань глазами современников… — С.40.

19. Шунда ук. — Б.38, 40, 42.

20. Древняя Казань глазами современников… — С.100.

21. Шунда ук.

22. Шунда ук. — Б.122.

23. Валеев Р.Р. Исследования Северной башни и прилегающей к ней стены Казанского кремля (по раскопкам 2003 г.) // Сб. Материалов итоговых конференций молодых учёных Института истории им. Ш.Марджани Академии наук РТ за 2003-2004 годы. — Казань, 2004. — С.42 и сл.

24. Заринский П. Очерки древней Казани, преимущественно XVI века. — Казань, 1877. — С.178; Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. — Казань, 1990; Шавохин Л.С. Средневековая Казань дорусского времени… — С.123.

казанлылар исә «градка», димәк, кирмәнгә (кремльгә) кереп бикләнәләр [27].

Ханлык чорында төзелгән һәм татар телендә язылган документларның берсе бик кызыклы. Ул — XV йөзнең икенче яртысына караган Ибраһим хан ярлыгы. Бу документта ярлыкның язылу һәм бирелү урыны төп-төгәл күрсәтелгән — «арк», фарсычадан тәрҗемәсе «цитадель, крепость» була [28].

* * *

Казан кирмәне Андрей Курбский язмаларында шәһәрнең бик көчле ныгытылган, чит илләрдән килгән кешеләрне дә тирә-якка ямь биреп торган гүзәл таш биналары, манаралары күккә ашкан мәчетләре белән шаккатыра алырлык иң матур өлеше буларак күз алдына килеп баса: «Бо бе зело крепок, между палат и мечетей каменных, оплотом великим обточен». Рус патшасы Иван IV тә кирмән диварларына исе китеп карап тора: «удивися необычной красоте стен крепости града» [29].

Хан сарае кирмәннең төньягын биләп торган өлешендә урнашкан булган, бүген инде рус чорында төзелгән биналар астында калып, эзсез юкка чыккан. Аңа Таҗик чокыры буйлап сузылган көньяк дивар уртасындагы капка аша кереп-чыгып йөрергә мөмкин булган. Ишегалдында хан сарае, сарай мәчете, кунак йорты, казна саклау йорты, дәүләт архивы һәм китапханә, ат абзарлары, азык-төлек келәтләре, хезмәтчеләр яши торган гади генә йортлар булган.

2001 елда археологлар Татарстан Президентының резиденциясе урнашкан ишегалдында, ханлык чоры катламнарын ачып, нигезләре яхшы гына сакланган, 18x24 метр үлчәмдәге зур гына дүрт бүлмәле (бүлмәләр идән астында — подвалда урнашкан) таш бина калдыкларын тикшерделәр [30]. Диварларының калынлыгы 1 метрдан артыграк иде. Ике катлы булгандыр, күрәсең, — нигезе бик нык. Табылдыклар алай күп түгел (рус чорында башка максатларда файдаланганнардыр), әмма ничек кенә булмасын, безнең алда ерак бабаларыбыздан калган гүзәл архитектура корылмаларының берсе иде. Безнең фикеребезчә, бу бинаны 1565-1568 елгы Писцовая кенәгәдә теркәлгән «Большая палата в Царёвом дворе» белән тәңгәлләштерергә мөмкин.

2001 елда Казан археология экспедициясе Сөембикә манарасына якын гына җирдә, аның төньяк һәм төньяк-көнчыгыш ягында, таштан салынган тагын бер бина хәрабәләренә тап булды. Аның озынлыгы — 30, киңлеге 16 метр чамасы иде (бинаның бер почмагы Сөембикә манарасы астына кереп китә, димәк, әлеге манара соңгырак чорга карый). Озын ягы белән без тикшергән объект нәкъ Мәккәгә, кыйблага каратып салынган. Хан мәчете булганмы? Һәрхәлдә, безнең моңа шигебез юк («у царского старого двора в мечети», дип теркәлгән ул Писцо-

25. Древняя Казань глазами современников… — С.124-129.

26. Шунда ук. — Б.100.

27. Шунда ук. — Б.20, 23, 25.

28. Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV-XVI вв. — Казань, 1979.

29. Древняя Казань глазами современников… — С.99, 131.

30. Хузин Ф.Ш., Набиуллин Н.Г. Казанский кремль // ДИНА. — 2001. — № 8; Набиуллин Н.Г. Новые данные по археологии средневековой Казани // Татарская археология. — 2002-2003. — № 1-2 (10-11).

вая кенәгәдә [31]). Шунысы игътибарга лаек: татар халкының тарихи аңында Сөембикә манарасы әле һаман да Хан мәчете буларак кабул ителә, олырак буын кешеләре, бирегә килеп, ерак бабаларыбыз рухына дога кылып китәләр. Һич тә очраклы хәл түгел бу.

Шул мәчеттән ерак түгел, бераз көнбатыш тарафка китеп, ханнар төрбәсе урнашкан булган. Кирмән территориясендә казып тикшерелгән архитектура корылмалары арасында Кол Шәриф мәчете хәрабәләре дә бар. Бу мәчетнең нигезе 1995-1999 елларда Ф.Ш.Хуҗин һәм Р.Ф.Шәрифуллин казылмаларында, Благовещение соборы янында урнашкан бакчада табылды (Писцовая кенәгәдә: «против Благовещения в мечети» [32]). Чынлыкта исә биредә бер-берсенә тоташтырып диярлек салынган берничә бина булган. Бу зур комплекска таш мәчет, мәдрәсә, торак йорт һәм хуҗалык корылмалары кергән [33].

Шәһәр мәйданының күбрәк өлешен биләп торган һөнәрчелек-сәүдә бистәләрендә — посадта — тормыш кайнап торган. Бистәләр шактый тыгыз, тәртипсез рәвештә төзелгән. Гади генә йортлардан торган бормалы-тыкрыклы урамнарның киңлеге 4-5 метрдан артмаган («проехать на конех бо невозможно, теснота во граде великая во хоремах» [34]). Чокыр-чакырлы булмаган уңайлы урыннарда хәллерәк, мөлкәтлерәк кешеләр үзләренә икекатлы кирпеч яки агач йортлар да салдырган. Аларны күргән чордашлары, «түрәләрнең йортлары гаҗәпләндерерлек дәрәҗәдә матур», дип язып калдырганнар.

Урта гасырлар Казанын шәһәр тирәсендә урнашкан эрелеваклы бистәләрдән башка күз алдына китерүе кыен. Әйтик, Болак аръягында Көрәеш бистәсе үсеп чыккан. Аның уртасында Отуч мәчетеерактан ук нур чәчеп торган. Аннан арырак, Иделгә таба, Патша болыны башланып киткән («прекрасный луг Царёв, зеленея травой и цветами красуясь, простирался»), биредә җыен зур бәйрәмнәр оештырылган, ат чабышлары уздырылган. Бәйрәмнәрдә күңел ачулар еш кына Арча кырында да оештырылган.

Казансу тамагындагы балта осталары, елга кораблары төзүчеләр яшәгән бистәне Бишбалта дип йөрткәннәр. Бу исемне халык әле хәзер дә онытмый. Биредә, Идел култыгында, сәүдә һәм хәрби кораблар килеп туктый торган уңайлы урын булган.

...Гөлдәй чәчәк атып утырган татар Казаны 1552 елның фаҗигале вакыйгалары нәтиҗәсендә юкка чыга. Авыр язмышка дучар ителеп, көл-күмер арасыннан чит кавемнәр тырышлыгы белән янәдән торгызылган элеккеге башкаланың тарихында яңа чор башлана.

Русчадан ***Фаяз Хуҗин*** *тәрҗемәсе*

31. Писцовые книги города Казани... — С.2.
32. Шунда ук. — Б.3.

33. Хузин Ф.Ш., Ситдиков А.Г. О локализации в Казанской крепости исторической мечети Кул Шарифа // Эхо веков — Гасырлар авазы. — 2005. — №2. — С.10-23.

34. Древняя Казань глазами современников... — С.46.

СӘХИБГӘРӘЙ ХАННЫҢ КАЗАН ЯРЛЫГЫНА КАРАТА БЕРНИЧӘ ФИКЕР*

ИЛЬЯС МӨСТӘКЫЙМОВ,
*Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты каршындагы
Баш архив идарәсе хезмәткәре*

*2012 елның 16-17 мартында ТР ФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты үткәргән «Социально-политический строй средневековых тюрко-татарских государств» конференциясендә ясалган чыгышның кыскартылмасы.

СӘХИБГӘРӘЙ ХАННЫҢ КАЗАН ТӘХЕТЕН БИЛӘГӘН ЧОРЫННАН БЕЗНЕҢ КӨННӘРГӘ КИЛЕП ҖИТКӘН БЕРДӘНБЕР ЯРЛЫК ИНДЕ ЙӨЗ ЕЛГА ЯКЫН ФӘННИ ӘЙЛӘНЕШКӘ КЕРҮЕНӘ КАРАМАСТАН [1], АНЫҢ БЕЛӘН БӘЙЛЕ КАЙБЕР МӘСЬӘЛӘЛӘР БҮГЕНГӘЧӘ ЧИШЕЛМИ КАЛА БИРӘ. СОҢГЫ ВАКЫТТА ХЕЗМӘТЛӘРЕБЕЗДӘ МОҢАРЧЫ КУЛЛАНА АЛМАГАН ЧЫГАНАКЛАР (ШУЛ ИСӘПТӘН ЯРЛЫКНЫҢ АСЫЛ НӨСХӘСЕ) БЕЛӘН ТАНЫШУЫБЫЗ БУ ЯДКАРЬНЕҢ УКЫЛЫШЫНА БЕРНИЧӘ ТӨЗӘТМӘ КЕРТЕРГӘ ҺӘМ ДОКУМЕНТ БЕЛӘН БӘЙЛЕ КАЙБЕР СЮЖЕТЛАРНЫ ЯҢАЧА ЯКТЫРТЫРГА МӨМКИНЛЕК БИРӘ ШИКЕЛЛЕ.

Әйтергә кирәк, ярлык начаррак сакланганга һәм Казан ханлыгының иҗтимагый-икътисади тарихына караган ышанычлы чыганакларның юк дәрәҗәсендә аз булганга күрә, бу хосустагы һәр фикер (шул исәптән алга таба әйтеләчәк фикерләр дә) фараз буларак кабул ителергә тиеш.

Бу мәкаләбездә документның адресаты (ягъни, хан боерыгы адресланган вазифа ияләре исемлеге [2]) турындагы күзәтүләребез белән уртаклашырбыз.

Ярлыкның адресатын түбәндәгечә укырга һәм тәрҗемә итәргә тәкъдим итәбез (биредә һәм алга таба документларның укылышы хәзерге татар теле фонетикасы кагыйдәләренә нигезләнә): *«вөлат вә хөккям вә сәлатыйне гыйзам вә козате ислам вә мәвалие зәвил-ихтирам вә әрбаб вә кәлантәран вә мокыйман вә илчийан вә йамчийан вә кәштибанан вә гөзәрбанан вә тоткавулан вә тамгачийан вә җөмһүре сәкәнә вә гомуме әһалие вилайате Газан вә мәмалике мәхрүсә»* (Вәлиләргә һәм хакимнәргә (наместникларга һәм губернаторларга), олуг солтаннарга, мөселман казыйларына, ихтирам ияләре руханиларга, авыл рәисләренә һәм шәһәр башлыкларына, урыннардагы вәкилләргә, атчабарларга, ямчыларга [3], көймә багучыларына, юл сакчыларына, тоткавылларга [4], тамгачыларга [5], Казан вилайәтләрендә һәм Ходай Тәгалә химаясендә булган мәмләкәтләрдә... барлык яшәүчеләр һәм бөтен торучыларга).

Әйтергә кирәк ки, вилайат сүзе гарәп теленнән кергән вилайәт сүзенең күплек сан формасы. Вилайате Газан «Казан вилайәтләре» дип язу ярлыкны төзегән кятипнең хатасы булган булуы ихтимал. Бу очракта телгә алынган сүтезмә вилайәте Газан, ягъни «Казан вилайәте» дип укылырга тиеш ки, бу Казан ханлыгының рәсми атамасы булса кирәк.

Сәхибгәрәй хан ярлыгы адресаты Ючылыларның [6] безгә мәгълүм башка ярлыкларыннан шактый аерылып торуы игътибарны җәлеп итә. Беренчедән, Сәхибгәрәй ярлыгында фарсы теленең шактый көчле йогынтысы сизелә: җанлы объектларның күплек санын белдерүче -ан/-йан кушымчасы (тоткавулан — «тоткавыллар», тамгачийан — «тамгачылар»), гарәп-фарсы лексикасының Ючылыларның ярлыклары өчен хас булмаган күплеге моның ачык мисаллары булып тора. Икенчедән, Сәхибгәрәй хан ярлыгының адресатында безнең көннәргә килеп җиткән Алтын Урда һәм Кырым хөкемдарларының ярлыкларын-

да кулланылмый торган терминнар һәм гыйбарәләр очрый. Хәлбуки, ул элементлар Иран илханнарының һәм Урта Азия Шыбанлыларының ярлыкларында һәм Чыңгыз хан нәселеннән булмаган XV-XVI йөз Урта Шәрык хөкемдарларының (Озын Хәсәннең, Исмәгыйль Сафәвинең) фәрманнарында очрый. Әйтик, илханнарның кайбер ярлыкларындагы адресатның бетем өлеше түбәндәгечә яңгырый: *«...вә гомуме әһали вә җөмһүре мөтәваттыйнане вилайате мәмалике мәхрүсә»* (Ходай Тәгалә химаясендә булган мәмләкәтләрнең вилайәтләрендә барлык яшәүчеләр һәм бөтен торучыларга). Бу гыйбарә Сәхибгәрәй ярлыгындагы адресатның бетем өлешенә гаять якын тора: *«җөмһүре сәкәнә вә гомуме әһалие вилайате Газан вә мәмалике мәхрүсә»* (Казан вилайәтләрендә һәм Ходай Тәгалә химаясендә булган мәмләкәтләрдә... барлык яшәүчеләр һәм бөтен торучыларга). Вөлат вә хөккям («валиләр һәм хакимнәр») дигән терминологик парны шаһ Исмәгыйль Сафәвинең 1509 елгы фәрманында, әрбаб вә кәлантәран («авыл рәисләре һәм шәһәр башлыклары») дигән терминологик тезмәне Мавәраәннәһердә хөкем сөргән, Ючы улы Шыбан нәселеннән Гобәйдулла ханның 1513 һәм 1538 елгы ярлыкларында, Иранда Сафәви династиясенә нигез салучы шаһ Исмәгыйль Сафәвинең 1513 елгы фәрманында күрәбез. Алтын Урда һәм Кырым ханнарының безгә мәгълүм ярлыкларында булмаган, әмма Тимерлеләр, Госманлылар, Урта Азия Шыбанлыларының кәнсәләрләрендә язылган документларында кулланылган терминнар, сүзтезмәләр Казан ярлыгының башка урыннарында да очрый.

Сәхибгәрәй хан ярлыгын өйрәнүчеләр, гадәттә, бу документның Ючылыларның башка актлары белән тәңгәл килүен билгеләп үтәләр иде. Мәсәлән, М.Г.Госманов бу ярлык адресатының «тышкы-стилистик үзенчәлекләренә карамастан, Ючылы гамәли дипломатикасының төп таләпләренә туры килә», дигән нәтиҗә ясый. Бу нәтиҗә белән принципта килешкән хәлдә, телгә алынган ярлыкта кулланылып, Ючылыларның безгә килеп җиткән башка документларында очрамаган элементларын Ючылылар хөкем сөрмәгән дәүләтләрдә чыгарылган фәрман-грамоталарга мөрәҗәгать итмичә, Алтын Урда кәнсәләр традицияләреннән чыгып яки монголлар килгәнче гамәлдә булган «җирле» традиция калдыгы дип кенә аңлатырга тырышу проблеманы беркадәр гадиләштерү булыр иде кебек. Иң элек шуның өчен ки, шактый галимнәрнең (мәсәлән, А.П.Григорьевның) хезмәтләрендә инде күрсәтелгәнчә, Чыңгызыйларның кәнсәләрләрендә һәм Чыңгызый эш кәгазьләрен төзү традициясен дәвам иттергән кәнсәләрләрдә (әйтик, Тимерлеләрнекендә) язылган документлар типологик, кайбер очракларда хәтта текстуаль охшашлыкка ия. Шуңа күрә, Сәхибгәрәй хан ярлыгының төзүчесенә (ихтимал, бу очракта «Казан ханлыгы эш кәгазьләре культурасына» дип әйтү дөресрәк булырдыр) тәэсир иткән чыганакларны барлаганда, Ючылыларның кәнсәләрләрендә төзелгән документлар белән генә чикләнмәскә кирәк дип уйлыйбыз.

Ярлыгыбыз текстыннан күренгәнчә, аны язган кеше йә фарсы телендәге эш кәгазьләренең нык тәэсирен алган төрки мөселман диван (кәнсәләр) традициясенең йогынтысын, йә фарсы телен кулланган берәр кәнсәләр традициясенең турыдан-туры йогын-

тысын күргән. Беренче очракта төрки телле, әмма Иран мәдәниятенең нык тәэсирен кичергән Сыр дәрьясы буендагы Сыгнак, Җәнд, Барчынлыгкәнд һәм тагын берничә шәһәр урнашкан төбәкнең язма культурасы нигезендә җитешкән традиция йогынты ясаган булуы мөмкин. Заманында ул җирләр Ючы Олысының сул кулы (Күк Урда) составына кергән. В.П.Юдин бу шәһәрләрне хаклы рәвештә Шәркый Дәште Кыпчактагы мөселман мәдәнияте терәкләре дип исәпли. Ючы Олысының дәүләт диваны (кәнсәләре) культурасының формалашу тарихын өйрәнгәндә, Иран мәдәниятенең борынгы учагы булып, монгол яулап алулары нәтиҗәсендә Ючы Олысына кергән һәм XIV йөздә төрки-мөселман мәдәниятенең эре мәркәзләреннән берсенә әйләнгән Харәземне дә исәптән төшерәсе түгелдер. Ихтимал ки, Урта Азия Шыбанлыларының (Мавәраэннәһердә Мөхәммәд Шәйбани хан варисларының, Харәземдә Гарәбшаһ хан нәселләренең) эш кәгазьләре теле һәм стиленең чыганагын нәкъ шушы төбәкләрдә җитешкән язма культурада эзләргә кирәктер.

Инде Казан ярлыгы төзүчесенә турыдан-туры фарсы телле диван традициясе тәэсир иткән булса, аның Мавәраэннәһер-Хөрәсән, нигездә Тимерлеләр диваннарының йогынтысы дип билгеләү хакыйкатьтән ерак түгел шикелле. Тимерлеләрнең кәнсәләрләре, үз чиратында, Чыңгызыйларның (Чыгтайлыларның һәм, ихтимал, илханлыларның) дәүләт диваннары традицияләрен дәвам иттерәләр. Сәхибгәрәй хан ярлыгын язучы Тимерле кәнсәләрләренең һәм турыдан-туры йогынтысын, һәм Урта Азия Шыбанлыларының дәүләт диваннары аша тәэсирен кичергән булуы мөмкин. XV йөз ахыры — XVI йөз башында Тимерлеләрнең Мавәраэннәһер һәм Хөрәсәндәге биләмәләре «күчмә үзбәкләр» ханы Мөхәммәд Шәйбани хан тарафыннан яулап алынгач, аның варислары заманында үзбәк кәнсәләрләренә билгеле дәрәҗәдә Тимерле дәүләтләренең диван (кәнсәләр) традицияләре тәэсир итәргә тиеш булган кебек.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алганда, өч сорау барлыкка килә: 1) Сәхибгәрәй ханның Казан ярлыгының лексик һәм стилистик үзенчәлекләре «чит» йогынтыларны сеңдереп җитешкән бер кятипнең «иҗат җимеше»ме, әллә ул үзенчәлекләр Казан ханлыгының диван традициясе белән бәйлеме? 2) Казан ярлыгының стиле соңгы дәвер Алтын Урда һәм Кырым ханлыгы традициясеннән үзгә булган берәр җирле традициягә туры килгән икән, ул традиция кайчан формалашкан? 3) Ярлыкта телгә алынган вазифалар, салымнар һәм йөкләмәләр Казан ханлыгында чынлап та булганнармы?

Кызганычка каршы, Казан ханлыгының үзендә төзелгән документлар безнең көннәргәчә килеп җитмәде диярлек яисә алар әлегә табылмаган (бүгенге көндә Сәхибгәрәй ханның ярлыгы Казан ханлыгы дәвереннән асыл нөсхә буларак килеп җиткән бердәнбер кульязма чыганак булып кала). Шуңа күрә югарыда куелган сорауларга өздереп җавап бирү әлегә мөмкин түгел. Алай да ул мәсьәләләргә караган кайбер фикерләребезне тәкъдим итәргә җөрьәт итәбез.

1) Документта кулланылган гарәп-фарсы сүзләрендә һәм гыйбарәләрендә шактый хәреф хаталары булуы ул элементларның ярлыкны төзегән кятип тарафыннан язылмавына ишарәли. Әгәр гарәп-фарсы телләренең элементлары текстка ярлык төзүченең үзе тарафыннан

кертелгән булса, безнең фикеребезчә, ул очракта алардагы хаталар азрак булырга тиеш иде. Хаталарның кайбер үзенчәлекләре ярлыкның телдән әйтеп яздырылганга ишарә итәләр кебек (мәсәлән, тәгаррыз сүзен тәкарыз, хәреҗ-хәраҗат терминын хәреҗ-караҗат, фәрдән минәл-әфрад вә вәҗһән минәл-вөҗүһ гыйбарәсен фәред минәл-афат вә вәҗеһ минәлвөҗүһ дип язу һ.б.ш. тупас хаталар). Кятипнең үрнәк итеп хаталар белән төзелгән икенче бер документны алуы да ихтимал.

2) Әгәр ярлыкның стиль үзенчәлекләре билгеле бер традициягә иярү белән бәйле булса, без ул традициянең формалашкан вакытын азмы-күпме төгәллек белән билгеле алабыз. Безнеңчә, Казан диван традициясенең тәмам формалашуы Мөхәммәд Әмин хан хакимлек иткән дәвергә (1487-1495, 1502-1518 еллар) туры килә. Моны раслаучы туры дәлилләр булмаса да, кайбер фактлар бу фараз файдасына сөйли. Беренчедән, ул вакытта Урта Идел буе белән Урта Азия арасында шактый тыгыз элемтәләр булуы мәгълүм. Моның сәбәпләреннән берсе — Казан ханы Мөхәммәд Әмин хан белән үзбәк ханы Мөхәммәд Шәйбани хан арасында булган якын, бәлки дустанә мөнәсәбәтләр. Зәки Вәлиди Мөхәммәд Әмин ханны 1505 елда, Мәскәүнең олуг кенәзе гаскәрен җиңүе белән котлап, Шәйбани ханның шигырь язуын әйтә һәм ул шигырьдән бер дүртьюллык китерә. Тимерле династиясенең мәшһүр хөкемдарларыннан Заһиреддин Мөхәммәд Бабәр үз хатирәләрендә Шәйбани ханның Мөхәммәд Әмин ханга Голям Шади исемле музыка иҗат итүчесен җибәрү турында яза. Сүз уңаеннан, В.П.Юдинның бу Голям Шадиның Мөхәммәд Шәйбани ханның эш-гамәлләренә багышланган һәм фарсы телендә язылган «Фәтехнамә» исемле шигъри тарихнамә авторы Мулла Шади белән бер кеше булу ихтималы турында фикер белдерүен дә әйтеп үтәргә кирәк. XVI йөздә Казан вилайәтендә чыгышлары белән Урта Азиядән йомышлы аксөякләрнең булуы да мәгълүм. Мәсәлән, Казан өязенең 1602-1603 елларда Иван Болтин төзегән писцовый кенәгәсендә бер «мурза юргенец» (ягъни, Өргәнечтән килгән (яки Өргәнечтән килгәннең улы булган) мирза телгә алына.

Икенчедән, галимнәр чыгтай (Тимерлеләрнең дәүләтләрендә яшәгән һәм чыгтай төрки телендә иҗат иткән) шагыйрьләре әсәрләренең XVI йөз Казан әдипләре Мөхәммәдьяр һәм Кол Шәриф иҗатларына тәэсир итүен билгеләп үтәләр.

Гомумән, Мөхәммәд Әмин ханның дәвере XVI йөздә яшәгән казанлыларга Казан дәүләтенең үзенә күрә «гасре сәгадәте» [7] булып күренгән булса кирәк (Алтын Урда дәүләтенең соңгы дәверендә һәм, ул таркалганнан соң, төрки-татар дәүләтләрендә «халыкның бәхеттә яшәгән дәвере» дип XIV йөз урталарында хакимлек иткән Җанибәк хан заманы мәгълүм). XVI йөз Казан шагыйре Мөхәммәдьярның үзен Мөхәммәдәмин хан төрбәсенең мөҗавире дип атавы очраклы түгелдер. Шунысы да игътибарга лаек: 1552 елда Казан яулап алынуга, Явыз Иван Казан арты ясак түләүчеләреннән «ясаклар»ны Мөхәммәд Әмин хан заманында җыелган күләмдә җыярга әмер бирә.

3) Сәхибгәрәй хан ярлыгында әйтеп үтелгән вазифалар, салымнар һәм йөкләмәләрнең Казан ханлыгында чынбарлыкта булу-булмаулары мәсьәләсен кую да урынлы дигән фикердәбез.

Беренчедән, вакыт үтү белән, кайбер салымнар һәм йөкләмәләр, гадәт буларак рәсми документларда телгә алынса да, гамәлдән чыга барганнар. Мәсәлән, XIV-XV йөз Алтын Урда һәм Кырым ханнарының ярлыкларында телгә алынган кайбер салымнарның XVI йөз Кырым ханнарының ярлыкларында язылмавы, М.Г.Госманов фикеренчә, ул салымнарның гамәлдән күптән төшеп калуы белән бәйле. Безнеңчә, Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән төрки-татар дәүләтләренең хөкемдарлары тарафыннан бирелгән кайбер ярлыкларда (шул исәптән Сәхибгәрәй хан ярлыгында) телгә алынган аерым вазифаларның чынбарлыкта булмаулары да ихтимал. Болай булган булса, бер дә гаҗәп түгел. Ул вазифаларның юкка чыгуын Ючы Олысында шәһәр мәдәниятенең XIV йөзнең икенче яртысында башланып, туктаусыз барган деградациясе һәм шуның белән бәйле рәвештә дәүләт институтларының эрозиясе белән аңлатып була. Алтын Урда таркалып, аның урынында берничә мөстәкыйль төрки-татар дәүләте барлыкка килгәннән соң да аларда (шул исәптән Казан ханлыгында да) шәһәр тормышы тернәкләнеп, элекке рәвешенә кайта алмаган.

Икенчедән, әгәр ярлык читтән кергән бер калып нигезендә төзелгән булса, аңарда җирле реалияләргә бик үк туры килмәгән терминнарның кулланылуы гаҗәп түгел. Мәсәлән, рус руханиларына Алтын Урда ханнары тарафыннан бирелгән тарханлык ярлыкларында башлыча «йөзем бакчалары»н белдергән «баг-багчалар» телгә алына (урта гасыр рус тәрҗемәчеләре бу парлы терминны «огороди виногради» дип тәрҗемә иткәннәр). Әлбәттә, рус кенәзлекләрендәге климатик шартлар йөзем үстерергә мөмкинлек бирмәгән һәм бу Ючы Олысы хөкүмәтенә мәгълүм булган. Димәк, рус руханиларына бирелгән ярлыкларда «баг-багчалар» терминын куллану документ төзүчеләрнең — кятипләрнең билгеле бер калыпка иярүләре белән бәйле.

Өченчедән, әгәр тарханлык ярлыгы ярлык бирелгән кешеләрне бөтен салым һәм йөкләмәләрдән азат иткән икән, әлеге документта чынбарлыкта булмаган салым һәм йөкләмәләрнең телгә алынуы аның әчтәлеген бозмаган. Ә инде ярлыкның адресатлары арасында, аңарда санап үтелгән вазифа ияләреннән башка «Казан вилайәтләренең (яки «вилайәтенең») барлык яшәүчеләр һәм бөтен торучылары»ның күрсәтелүе, текстта телгә алынган түрәләрдән гайре, ярлык төзелгән вакытта (яки, гомумән, беркайчан да), Казан ханлыгында булмаган вазифаларның документта телгә алынуы мөмкин.

Искәрмәләр

1. Бу ядкәрне өйрәнүгә һәм текстын тәнкыйди бастыруга багышланган безгә мәгълүм соңгы хезмәтне кара: Мөстәкыймов И. Сәхибгәрәй хан ярлыгы // Гасырлар авазы — Эхо веков. — 2003. — № 3/4. Шунда ук документның элекке басмаларына күзәтүне кара.
2. Сәхибгәрәй хан ярлыгы текстының 2-5 нче юллары.
3. Ямчы — ям багучы. Ям — Монгол империясендә һәм Чыңгызыйларның дәүләтләрендә: хөкүмәт йомышлары белән йөргән атчабарларга алмаш атлар асралган станция.
4. Тоткавыл — юл салымын җыючы түрә.
5. Тамгачы — тамга дигән салымны җыючы түрә.
6. Ючылылар — Чыңгыз ханның олы улы Ючы (Җүчи) нәселеннән булган династия. Алтын Урда (Ючы Олысы) дәүләтендә һәм аның таркалуыннан соң барлыкка килгән төрки-татар дәүләтләрендә хөкем сөргәннәр.
7. Гасре сәгадәт — «бәхет дәвере». Мөселман традициясе буенча, Мөхәммәд пәйгамбәр яшәгән заман.

КАЗАН ХАНЛЫГЫНДА ТӨРКИ ИСЛАМ МӘДӘНИЯТЕ

Кануни заманында* (1550 елда) Казаннан җибәрелгән бер хәбәр хаты

ЗӘКИ ВӘЛИДИ ТУГАН

*Кануни солтан Сөләйман — Госманлы империясенең унынчы солтаны, 1522-1566 елларда идарә итә. *(Ред.)*

XVI йөздәге Арча кыры ягыннан Казан күренеше, 1996 ел, кәг.кар., 54х120

ВӘЛИДИ Әхмәдзәки Әхмәдша улы (эмиграциядә (1923) — Әхмәдзәки Вәлиди Туган) (1890-1970) — башкорт халкының милли-азатлык хәрәкәте җитәкчесе, тарихчы, тюрколог, фәлсәфә фәннәре докторы (1935). 1912-1915 елларда Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсе мөгаллиме. 1925 елдан Төркиядә Истанбул университеты укытучысы һәм профессоры. Соңрак Германиянең Бонн (1935-1937) һәм Гёттинген (1938-1939) университетлары профессоры. 1953 елдан Истанбул университеты каршындагы Ислам дөньясын өйрәнү һәм тикшерену институты җитәкчесе. Әхмәдзәки Вәлиди — Манчестер университетының шәрәфле докторы (1967) (Татар энциклопедиясе сүзлеге. — Казан, 2002. — Б.138).

Ислам мәдәнияте Идел буе болгарларында X гасырдан урнаша башлаган булса да, Чыңгыз угыллары заманы килеп, Алтын Урдада Харәзем мәдәнияте көчәйгәнгә кадәр артык җәелеп китә алмаган. Һ.Йосыповның Болгар кабер ташларын өйрәнеп бастырып чыгарган хезмәтеннән аңлашылганча, ул заманнарда мөселманнар борынгы болгарларның теле булган чуваш сөйләм телен кулланып язганнар [1]. Әбү Хәмид әл-Әндәлуси Хорасанда белем туплап җитлеккән галимнәр турында сүз алып бара. Моннан тыш Сөләйман бине Даут Сакъсини (яки Сувари) исемле бер кешенең ислам мәдәнияте турында гарәп һәм

фарсы телләрендә язылган һәм безнең көннәргә кадәр килеп җиткән әсәрләре мәгълүм. Боларны исәпкә алмасак, Болгарда ислам мәдәниятенең ныклап урнашкан булуын дәлилләрлек җитди язма әдәбият юк.

Алтын Урда чорында исә, бигрәк тә 1300 елдан соң, Болгарда һәм аның төньягында урнашкан Казанда ислам мәдәнияте үзәге барлыкка килгән. Бу чорда борынгы «чуваш әдәби төрки теле» бары тик мөселман булмаган болгарларның сөйләм теле рәвешендә калган. Кабер ташларындагы язмалардан да аңлашылганча, биредә Урта Азия төрки әдәби теле җәелгән. Болгарга үзләрен пәйгамбәр нәселеннән дип таныткан «сәет»ләр килгән, алар тарафыннан идарә ителгән тәккәләр, ягъни дәрвиш гыйбадәтханәләре, имарәтләр, ягъни хәйрия оешмалары барлыкка килгән, мәктәп-мәдрәсәләр ачылган. Болгар һәм Казанда җәелеп алга киткән мәчет һәм мәдрәсә, хамам (мунча) культурасы Харәзем ислам мәдәниятенең көчле йогынтысы астында булган. Бары тик Кырымда һәм Казанда гына, бирегә Чыңгыз нәселеннән булган Ичкили Хәсән балалары килеп урнашканнан соң, Кырым аша Госманлының да тәэсире күренә башлаган. Ләкин бер сорау тынгылык бирми. Казанда борынгы Болгарда күренмәгән хәлнең — мөселманлыкның бик җанлы рәвештә таралуын ни белән аңлатырга? Биредә ислам мәдәнияте өчен эшчәнлек алып барган җәмгыятьләр, Сарай шәһәре эчке ызгыш-талашлар нәтиҗәсендә җимерелеп таралганнан соң, бирегә күчеп килеп урнашкан шәхесләрдән гыйбарәт идеме икән әллә?

Соңгы вакытларда бу мәсьәләгә беркадәр ачыклык кертергә ярдәм иткән документлар табылды. Рус галиме С.Шпилевский «Казан губернасында борынгы шәһәрләр һәм башка болгар-татар мәдәни ядкәрләре» исемле хезмәтендә, хәзерге Казан җирләренә XIII гасырда күпләп русларның килеп урнаша башлавы (70-76 б.), 1298 елда Казан исемле бер хөкемдарның үз исемен һәм, шөһрәтен мәңгеләштерү максаты белән, хәзерге Казанның бераз төньягында урнашкан Иске Казан дигән җирдә мөселман шәһәре төзүе, 104 ел үткәннән соң, һиҗри 804 нче (милади 1402) елда бу шәһәрнең хәзерге Казан урнашкан җиргә күчерелеп яңадан төзелүе турында кайбер риваятьләрне җыеп бастырган [2]. Бу мәгълүматны эченә алган «Бәяны дастаны тарих» кебек исемнәр астында безнең чорга кадәр килеп җиткән кайбер язма риваятьләр (боларның берсен чыгышы белән немец профессоры Фукс та 1817 елда бастырып чыгарган хезмәтендә искә алып үтә) белән таныш булсак та, бүгенге көнгә кадәр алар нәшер ителмәделәр. Бу язма әсәрләрдә Казанның беренче ханының исеме «Сайын» дип язылган. Бу сүз данлы Чыңгыз угылларына карата үлемнәреннән соң «газиз», ягъни «изге, хөрмәт иясе» мәгънәсендә кулланылган бер төрки сүз, исем түгел. Алтын Урдада «Сайын» дип аталган хан Бату хан булган. Соңыннан Казан исемен алган җирләр аның үз иле булган һәм бу җирләр «Сайын хан иле» дип аталып йөртелгән.

Рус галиме В.Семёнов әле 1836 елда ук, Казанның башлангыч чор тарихына караган хезмәтләрендә сүзгә-сүз болай дип яза: «Казан шәһәре рус елъязмаларында беренче тапкыр 1370 елда искә алынган. Моңа башта «Сайын иле (йорты)», (Саинов юрт) дигәннәр. Бу — Бату хан. (Ул вакытларда әле шәһәр түгел, «йорт», ягъни үзәнле җирләр булган). Казан исеме исә бу җирләрдә шәһәр төзелү белән бәйле. Аны төзүченең Әбелгази хан тарафыннан искә алынган Чагатай ханнарының берсе — Казан-хан (1334-1346) булуы мөмкин» [3].

«Казан» яки «Газан» исеме борынгы Болгар шәһәрләре арасында күренми.

«Кашан» исемле бер шәһәрме, зур авылмы булса да, ул бөтенләй башка якта, Идел борылышының көнбатышында, хәзерге Тәтеш шәһәре тирәсендә урнашкан булган.

Шәһәр «Газани» исеме белән Тимер чорына караган документларда очрый. Тимер 1395 елда Туктамышка каршы икенче тапкыр яу чабуы турында Анадулыдагы тарафдары Чәмишкәзәк бәге Ялманга язган хатында үзенең, Туктамышны эзәрлекләп, Әтил елгасына кадәр килүен, Болгар шәһәре янында сугышканнан соң, Туктамышның Рус иленә качуын, үзенең (Тимернең) исә гаскәре белән «Газни» яки «Газани» ягына килүен һәм, Рус иленә киткән дошманын эзәрлекләүдән ваз кичеп, хәзерге Украинадагы Үзи (ягъни Днепр) елгасы буйларына таба хәрәкәт итүен язган. Мәрхүм Мөкрәмин Хәлил бәйнең кулындагы «Мәҗмуга-и мүншәат» (Рәсми хатлар җыентыгы) китабында 93 б номерлы битендә язылган бу сүзләр, Ашир әфәнде китапханәсендә III бүлек, №326 «Мәҗмуга-и мүншәат» җыентыгының 94 а битендә: «Туктамышны Болгар чикләренә кадәр эзәрлекләп барып, аның боерыгы астындагы кавемнәрне буйсындырдык, аннан Газанигә китеп, Газанидән Үзи елгасы буйларына хәрәкәт иттек», рәвешендә язылган. Бурсада Хараччы угылы китапханәсендә Ибн Гарәпшаһның 1051 номеры белән саклана торган «Аҗаиб әл-макдур» (Искитәрлек көч) китабының бик камил һәм яхшы нөсхәсе бар. Моны һиҗри 841 нче (милади 1437) елда Али ибн Муса әл-Газани исемле бер кеше язган. Мондый камил язма борынгы Болгарда языла алмас. Кырым ханы Хаҗигәрәйнең һәм Казан ханы Сәхибгәрәйнең төркичә язылган фәрманнарында (Төркият мәҗмугасы, II, б.13) бу илнең әмир һәм хакимнәреннән соң «Садат-ы гыйзам», ягъни бөек сәетләр искә алынган. Әлеге ярлыкны өйрәнгән Г.Таймас Алтын Урдада язылган башка фәрманнарда сәетләрнең бәкләр белән беррәттән искә алынмаганлыклары турында хәбәр итә. Моннан тыш, Казанда Азәрбайҗан һәм Хорасанда кулланылган атамалар, шул исәптән «рабдһ» урынына «бистә» сүзе кулланылган. Идел буендагы башка шәһәрләрдә мондый «бистә» (бәстә)ләр очрамый. Бу үзенчәлек Казанда Илхани дәвере мәдәниятенең йогынтысы булган дип уйларга этәрә. Әлеге йогынты чынлап та булган. Сөләйманиядәге Хаҗи Мәхмүд әфәнде китапханәсендә саклана торган 3394 номерлы җыентыкның 62 а битендә Сәлим II дәверендә 1568 елгы «Әстерхан сәфәре»нә бәйле шундый җөмләләр теркәлгән: *«Бу яу сәфәре шул хәлдә булды ки, Чыңгыздан соң Солтан Мәхмүд Газан гасырында ислам белән дәрәҗәсе арткан татар кавеменнән бер җәмәгать ул җирләрне яулап, ватан тотып, казан татары диелеп мәшһүр булдылар. Дәүләте Газания (Казан дәүләте) инкыйразыннан соң, Мәскәү кяферләренең тәхете каһәрендә калып, әле һаман сыеныр йортка хат-хәбәрләр килеп, ике елга (Идел белән Дон) арасын ягып яндыру әмеренә этәрделәр»*. Биредә «Мәхмүд» Казанда Олуг Мөхәммәд ханнан соң килгән улы «Мәхмүд» яки «Мәхмүтәк хан» исеме белән бутап, Илханлы хөкемдары «Солтан Мәхмүд Газан» рәвешенә кертелгән булса кирәк. Тик Хаҗи Мәхмүд әфәнде язмасында бирегә «сугышып яулап алу өчен, мөселман татар газиләренең (изге сугышта яралар алган батыр сугышчы) килеп урнашуы»на караган тәфсилле аңлатма бар. Мондый мәгълүмат Олуг Мөхәммәднең улы Мәхмүтәк хан заманы өчен туры килеп бетми. Һәрхәлдә, Газан хан ислам мәдәниятен җәелдерү юлында башкарган чаралардан берсе итеп Алтын Урда дәүләтенең төньягында, Шпилевский әйткәнчә, XIII гасырда христиан рус кавемнәре күпләп үтеп керә башлаган җирләрдә, «татар газиләре»н үз илендә бик тыры-

шып асрап яткан сәетләрне дә боларга кушып, ныгытмалы кала барлыкка китертеп, каланың әйләнә-тирәсендә үз иле рәвешендә «бистә» төзеткән булуы мөмкин. Газан хан ислам динен кабул иткәннән соң, Урта Азиянең Ханбалыктагы (Пекин) каханлык боерыгы астындагы Кансу вилаятендә ислам мәдәниятен җәелдерү юлында бу төр чараларны үткәрә. Моны Рәшедеддин язмаларыннан укып белә алабыз [4]. Шул ук Рәшедеддиннең «Мүншәат» (Рәсми хатлар) китабыннан (б.17) Газан хан дәверендә Кавказның төньягында, хәзерге Владикавказ шәһәренә якын җирләрдә Алтын Урда ханнары боерыгы астында булган Балчәмән (Балчман) шәһәренең дә Илханлы йогынтысында калган булуы аңлашыла. Ибн Баттута да бу җирләрдә урнашкан Мажар шәһәре һәм бирегә Ирактан килгән Руфаи шәехе белән аның җитәкчелегендәге дәрвишләр турында искә алып үтә. Рәшедеддиннең ислам теологиясенә караган әсәрләренең үзе яшәгән заманда Тәбриздә язылган нөсхәләре башта Алтын Урданың Сарай шәһәрендә яки Кырымда булганнан соң, Госманлы дәүләтенең башкалаларына китерелгәннәр. Бу хакта без китапханәләребездә саклана торган нөсхәләрдән укып белә алабыз. Әлеге шәехнең язмаларында Алтын Урданың чик төбәкләренә кяферләр белән сугышыр өчен Азәрбайҗаннан газиләр җибәрелүе, Газан ханның замандашы булган Әрдәбил шәехе Сафеддин Әрдәбилинең дә хәтта берара бу газиләр белән бергә кыпчак далаларында булуы хакында мәгълүматлар теркәлгән. Шуның белән бергә Казан һәм Балчимән кебек җирләрдә Газан хан заманында көчле яклау һәм хуплау күргән сәүдә үзәкләре барлыкка килгән.

Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән язма документлардан күренгәнчә, Казан һәм Кырым кебек җирләрдә Илханлы дәүләте заманында барлыкка килгән «дәфтәрдарлык» (акча, мал-мөлкәт хисабын алып бару) белән «казна» (хәзинә) оешмалары һәм язу сәнгате, җирле халыкның үз эченнән үсеп чыккан алдынгылык булмыйча, бу өлкәләргә читтән кертелгән. Соңыннан Казан хөкемдары булган Олуг Мөхәммәд ханның 1428 елда Мурад IIгә һәм Кырым ханы Хаҗигәрәйнең 1453 елда Фатих Солтан Мәхмәткә җибәргән хат-язмалары Тәбриздә һәм Гератта иң югары дәрәҗәгә ирешкән дивани язу сәнгатенчә язылганнар. Телләре дә камил көнчыгыш төрки тел. Топкапы Сарае музеенда саклана торган бу документларны профессор Әкъдәс Нигъмәт 1940 елда бастырып чыгарды. Казанда хакимлек иткән Сәхибгәрәй ханның 1522 елда чыгарган фәрман язуы шулкадәр начар язылган һәм шулкадәр җаһиллек сизелеп тора ки, бу аның заманында (Тәбриз һәм Гераттан) үтеп кергән мәдәниятнең даими булмыйча, дулкын-дулкын килгәнлеген күрсәтә. [Төркият мәҗмугасы, II, 19].

Дәвамы киләсе саннарда.

Әдәбият

1. Юсупов Г. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. — М.-Л., 1960.
2. Шпилевский С. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. — Казань, 1877. — С.70-77.
3. Библиотека иностранных писателей о России. Т.1 (Барбаро). — Петербург, 1836. — С.153-155.
4. Җамигъ әт-тәварих. Русча яңа тәрҗемәсе. — 1960. — С.209; E.Bloche басмасы тексты (Leiden, 1911). — Б.601.

Чыганак

Мәкалә «Ислам тикшеренүләре институты» [İslam Tetkikleri Enstitüsü Dergisi] журналыннан алынды (Истанбул, 1965. – Т.III. – Б.179-182).

Төрекчәдән
***Асия Рәхимова** тәрҗемәсе*

КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ ТЫШКЫ СӘҮДӘСЕ

(кыскартып бирелә)

ШАМИЛ МӨХӘММӘДЬЯРОВ

МӨХӘММӘДЬЯРОВ Шамил Фатыйх улы (1923-2005) – тарих фәннәре кандидаты. 1950-1952 елларда СССР ФА Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1952-1955 елларда СССР ФА Көнчыгышны өйрәнү институтында, 1956-1965 елларда Казан дәүләт университетында СССР тарихы кафедрасы доценты һәм мөдире, 1965-1970 елларда СССР ФА Якутия фәнни үзәгендә өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли. Якут дәүләт университетында төрки халыклар тарихы буенча лекцияләр укый. 1970-1996 елларда СССР ФАнең (1992 елдан РФА Россия тарихы институты) Россия халыклары һәм этносара мөнәсәбәтләр үзәгендә эшли. Ш.Мөхәммәдьяров – Мәскәү югары мөселман колледжы профессоры.

Галим Казан ханлыгы, Кырым һәм Якутия тарихлары, татар халкының этногенезы, Идел буе һәм Уралдагы урта гасырлар төрки, фин-угор халыклары тарихы буенча 170кә якын хезмәт авторы. Сезгә тәкъдим ителә торган мәкалә Ш.Мөхәммәдьяровның 1951 елда Мәскәүдә якланган «Казан ханлыгының социаль-икътисади һәм дәүләт төзелеше (XV-XVI гасырның беренче яртысы)» дип исемләнгән диссертациясенең бер бүлекчәсе*.

*Бу китап турында «Яңа китаплар» сәхифәсеннән укый аласыз. *(Ред.)*

Казан ханлыгының тышкы сәүдә үзәге Казан каласында булган. Уңайлы географик шартлар — Идел сәүдә юлы буенда урнашу — җирле халыкларның күрше рус кенәзлекләре һәм Шәрык илләре белән җанлы сәүдә мөнәсәбәтләре булдыруга элек-электән мөмкинлек тудырган. […] Әмма XIV гасырның икенче яртысында Алтын Урда ханнарының тәхет өчен көрәшләре, ханнарның төрле мәҗбүри чаралары аркасында җитештерү көчләренең тулысынча җимерелүенә китергән. […]

Биредә шунысын да искәртмичә калу ярамый: нәкъ менә шушы вакытта русларның сәүдәсе Идел буенда активлаша. Алтын Урда ханы Туктамыш 1382 елда Мәскәүгә походы алдыннан үз гаскәренең беренче отрядын Болгарга җибәрә, шунда рус сәүдәгәрләрен үтерергә, аларның көймәләре белән товарларын таларга, суднода булган мал-мөлкәтләрен кулга төшерергә боера. […] Шул рәвешчә, XIV гасырның ахырында ук «Идел буе сәүдәсе һәм сәүдә көймәләре Урда сәүдәгәрләрендә түгел, ә русларның кулында була» [1].

Казан ханлыгы оешу Идел буендә уңай роль уйный, ә Казан татарлары үзләре бу сәүдә мөнәсәбәтләрендә актив катнашучылар була [2].

Казан ханлыгында барлык алыш-бирешне үз кулларында тоткан шактый күпсанлы сәүдәгәр катлавы яшәгән. XV гасыр азагы «Мәскәү елъязмалары җыентыгы»нда Казан ханлыгы территориясендә рус отрядларының 1468 елгы һөҗүмнәре вакытында зыян күрүчеләр арасында читтән килгән татар сәүдәгәрләренең зур төркеме дә искә алына [3].

Казан сәүдәгәрләре рус җирләренә еш барганнар һәм кайберләре хәтта эре рус сәүдә үзәкләрендә даими яшәгәннәр. Новгородның дүртенче елъязмасында 1446 елда Бөек Новгород шәһәрендә татар сәүдәгәр-кунаклары турында («бисерменство») мәгълүмат бар, новгородлылар ачлык вакытында икмәк хисабына үзләрен аларга коллыкка сатканнар [4]. […]

XVI гасыр башында Казаннан татар сәүдәгәрләре Дмитров шәһәрендә сәүдә иткәннәр. Моны Дмитров таможня грамотасыннан өземтә дәлилли […] [5].

[…] Борынгы Мәскәү тарихын өйрәнүче М.Н.Тихомиров фикеренчә, XV-XVI гасырларда Мәскәү каласында татарлар биредәге мөселман халыкларының «шактый зур һәм мөһим төркеме»н тәшкил иткәннәр. Замоскворечьеда татар урамнарыннан торган тулы бер район булуы турыдан-туры татарларның биредә күптән килеп урнашуларын күрсәтә [6]. Татар сәүдәгәрләренең шактый зур төркеме Казан шәһәренә якын урнашкан һәм соңрак танылган Казан халыкара ярминкәсенең дәвамчысы булган Түбән Новгородта, рус шәһәрендә, даими яшәгән. 1531 елда кенәз Табай җитәкчелегендәге Казан илчеләре чираттагы бәрелештән соң рус хөкүмәте белән

1. ПСРЛ. Т.XXV. — С.42; См. также: ПСРЛ. Т.VIII. — С.42.

2. Б.Д.Греков и А.Ю.Якубовский. Золотая Орда и её падение. М., 1950. — С.326.

3. ПСРЛ. Т.XXV. — С.280; См. также: ПСРЛ. Т.VI. — С.188; Т.VIII. — С.153; Т.XX. — С.279; Т.XVIII. — С.218.

4. ПСРЛ. Т.IV. — С.124; См.также: ПСРЛ. Т.IV. Ч.1. Вып.2. — С.440.

5. ААЭ. Т.I. — С.138. Документ №170.

6. М.Н.Тихомиров. Древняя Москва. М., 1947. — С.143.

сөйләшүләр алып бара. Биредә Түбән Новгородтагы Казан сәүдәгәрләренең киләчәк язмышына бәйле мәсьәлә махсус кузела [7]. [...]

Казан татарларының аеруча актив контрагентлары булып рус сәүдәгәрләре торган. Казан ханлыгы оешканнан башлап, руслар Казанда даими сәүдә алып барганнар. Бу турыда митрополит Иоанның Казанга вак-төяк алып бару хезмәтчеләренә ярдәм күрсәтүне сорап язылган ике грамотасы сөйли. [...]

Казанда ел саен май азагында Иоан Предтече Раштуасы бәйрәме вакытында зур халыкара ярминкә үткән: «...бу көндә Казанга бөтен Рус җирләреннән дә бай сәүдәгәрләр һәм күп кенә ерак илләрдән кешеләр киләләр, кыйммәтле маллар белән сәүдә итәләр» [8]. «Казан патшалыгы турындагы тарих»ның авторы Казан ярминкәсенең билгеле бер этапта Рус һәм Шәрык арасын бәйләүче төп үзәк булуын бик дөрес ассызыклый. Бу, әлбәттә, ярминкәнең һич кенә дә Казанның үзендә, аның Рус белән дә һәм шулай ук Көнчыгыш белән дә сәүдә мөнәсәбәтләре үсешендә тоткан әһәмиятен кечерәйтми. Ярминкә Казансу елгасы Иделгә кушылган урында, махсус утрауда үткән. Бу утрау Кунак утравы [Гостиный остров] дип аталган. С.Герберштейн үзенең «Мәскәү эшләре» турындагы язмасында Кунак утыравы исемен утрау буларак болай аңлата: «Сәүдәгәр утравы дип аталганы Казан крепостеннән ерак түгел Идел култыклары арасында урнашкан» [9]. Шулай ук дип аңлату 1558 елның 13 июлендә Бохарага барышлый Кунак утравы яныннан узган А.Дженкинсонда да очрый: «Шул ук көнне без «сәүдәгәрләр утравы дип аталган» утрау яныннан үтеп киттек, ул барлык сәүдәгәрләр дә — руслар да, казанлылар да, нугайлылар һәм кырымлылар да килгән, гадәти җыела торган һәм алыш-биреш иткән урын иде», — дип яза [10].

Кунак утравында Казан халыкара ярминкәсе 1525 елга кадәр була. Казан ханлыгы һәм Рус дәүләте арасында мөнәсәбәтләр начарлангач, ул уздырылмый башлый һәм Түбән Новгородка күчерелә. Ул заман кешеләре Казан ярминкәсе тукталу сәбәпле, Россия һәм Шәрык арасындагы сәүдә мөнәсәбәтләренә китерелгән кыенлыкларның шаһитлары булалар. Алар бу ярминкәнең Казан ханлыгы

7. ПСРЛ. Т.XIII. — С.56; См. также: ПСРЛ. Т.VIII. — С.276; Т.XX. — С.409.

8. ПСРЛ. Т.XIX. Стлб. 23, 229.

9. С.Герберштейн. Указ. соч. — С.152. (См. также С.153).

10. А.Дженкинсон. Путешествие из города Москвы в России до города Бухары в Бактрии в 1558 г., описанное им самим для купцов Московской компании. В кн.: Английские путешественники в Московском государстве в XVI веке. — М., 1938. — С.169.

Хәзинә. XIV гасырның I чиреге

халыклары өчен генә түгел, ә, гомумән, барлык Көнчыгыш Европа өчен зур икътисади әһәмиятен ачык күрсәтәләр.

С.Герберштейн Василий Иванович идарәсе чорында, 1525 елны, Казан ярминкәсенең тукталу нәтиҗәләрен җентекләп тасвирлый: «Гадәттә Казан янындагы сәүдәгәрләр утравында оештырылган ярминкәне Василий, казанлыларны үпкәләтер өчен, Түбән Новгородка күчерде. Шуның өстенә утрауга сәүдә итәргә баручы үзенең барлык кешеләренә дә авыр җәзалар билгеләде. Ул ярминкәне күчерү казанлыларга зур зыян китерер дип өметләнде һәм хәтта аларны тоз сатып алу мөмкинлегеннән мәхрүм итеп буйсындырырга мөмкин булыр дип уйлады (татарлар тозны бу ярминкәдә руслардан сатып алганнар). Әмма ярминкәне шушы рәвешле күчерүдән Мәскәү дә казанлылар кебек үк файда күрмәде. Чөнки аның нәтиҗәсе кыйммәтчелек һәм Каспий диңгезеннән, Хаҗитархан ярминкәсеннән Идел буенча, шулай ук Пермьнән һәм Әрмәнстаннан китерелгән күп кенә товарларга ихтыяҗ арту булды» [11].

А.Дженкинсон инде 30 елдан артык вакыттан соң, Кунак утравы яныннан узганда, элек булган Казан ярминкәсен искә төшерә һәм кызгану хисе белән: «Моңа охшаш җыелу урыны Казанда да, Мәскәүдән алып Каспий диңгезенә кадәр дә — беркая да юк», — дип билгеләп үтә [12].

Рус елъязмалары рус сәүдәгәрләренең Казанда һәм Казан ханлыгында даими булуларын берничә тапкыр билгеләп үтәләр. [...] София икенче елъязмасы (1467 ел): «Казан татарлары шул елның җәендә рус кунакларын таладылар», — дип хәбәр итә [13].

Рус сәүдәгәрләренең Казанда булуы турында тулырак һәм кызыклырак мәгълүмат XVI гасырның беренче яртысына караган рус елъязмаларында сакланган. Русларның Казан белән сәүдә мөнәсәбәтләре, әлбәттә, рус гаскәрләренең 1487 елда Казанга уңышлы походларыннан соң көчәйгән. [...]

Казан ханлыгында рус сәүдәсенең интенсивлыгы соңыннан оешкан Казан губернасы һәм хәзерге ТАССР территориясендә табылган күпсанлы, шактый зур рус тәңкәләре хәзинәсе белән дәлилләнә. Удель чоры дип йөртелгән заманга караган рус тәңкәләренең кыйммәтле җыелма хәзинәсе турында Казан губернасы буенча мәгълүмат А.А.Ильин тарафыннан төзелгән [14]. Ул шундый 12 хәзинәне исәпкә алган. Тәүге шундый зур хәзинә 1854 елның җәендә Казан шәһәреннән ерак түгел урында табылган. Хәзинә бөек кенәз Василий Васильевич Тёмный, Иван III һәм кайбер удель кенәзләренең шактый күп сандагы тәңкәләреннән тора. Савельев билгеләве буенча, алар 1487 һәм 1505 еллар аралыгында күмелгән. Казан шәһәре территориясендә тагын 3 хәзинә табылган: 1) 1861 елны Кафедраль собор янында Иван III һәм өлешчә Василий Васильевич Тёмный тәңкәләре; 2) 1878 елда Кремль территориясендә

11. С.Герберштейн. Указ. соч. — С.157.

12. А.Дженкинсон. Указ. соч. — С.169.

13. ПСРЛ. Т.VI. — С.188.

14. См.:А.А.Ильин. Топография кладов древних русских монет X-XI вв. и монет удельного периода. Л., 1924. — С.31-38. (Труды нумизматической комиссии Российской академии истории материальной культуры. Вып. V).

табылган Новгород, Василий Васильевич Тёмный һәм Иван III тәңкәләреннән торган хәзинә; 3) 1909 елны шулай ук Кремльдә табылган Иван III һәм Иван IV акчалары (284 тәңкә) Казан губернасының төрле өязләрендә дә очрый. Савельев тарафыннан Лаеш өязенең Красновидово авылы янында урнашкан Карташихада табылган хәзинәдә Василий Васильевич Тёмныйдан алып Иван IVкә кадәрге 154 тәңкә булуы мәгълүм.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: элекке Казан ханлыгы территориясендә табылган барлык рус тәңкәләре сугылу вакыты буенча Казан ханлыгы дәверенә карыйлар. Шундый хәзинәләр Лаеш өязе Панов волосте Кибәч авылыннан (1903 ел, 1700 данә рус тәңкәсе), Зөя өязе Урта Куланга авылыннан (1900 ел, XV-XVI гасырларга караган 2869 данә рус тәңкәсе), Зөя өязе Иванов волосте Әзбаба авылыннан (1899 ел, каен тузыннан ясалган акча чүлмәге, балавыз белән ямалган, эчендә алты фунтка якын XV һәм XVI гасыр башы көмеш рус тәңкәләре) табылдылар.

Рус тәңкәләренең Казан ханлыгы территориясендә киң таралуларын шул вакытта русларның татарлар белән алып барган тыгыз сәүдә мөнәсәбәтләренә бәйләү генә дөрес булмас, рус тәңкәсе Казан ханлыгының тәңкәләре җитәрлек булмау сәбәпле әйләнештә булган.

Рус сәүдәсенең Казанда шулай мөһим урын алып торуы Казанның икътисади яктан Рус дәүләте, ә төгәлрәге Рус дәүләтенең чиктәш өлкәләре белән икътисади бәйлелегенең турыдан-туры нәтиҗәсе булып тора. Бу — кире кагылмаслык факт. Монда Казан феодалларыннан бер вәкилнең фикере игътибарга лаек: «Безгә Мәскәүдән башка эшләү мөмкин түгел» [15]. Бу факт XVI гасыр сәяхәтчесе Сигизмунд Герберштейн тарафыннан да искәртелә. Ул Казан татарлары турында болай дип яза: «Мәскәү патшасы Василий аларны шул хәлгә җиткерде ки, алар аңа буйсындылар һәм патшаларын аның карары буенча кабул итә башладылар. Бу гамәл Московиядән Иделгә койган елга юлларына да, үзара сәүдә мөнәсәбәтләренә дә бәйле. Руслар белән татарлар сәүдәдән башка тора алмыйлар» [16].

Казан ханлыгына төньяктан Рус дәүләте составына кергән Вятка җирләре чиктәш була. Вятка урманнары җәнлек-җанварга бай булган. Кыйммәтле тиреләрне Нократ һәм Чулман елгалары буенча Казан базарына бик ансат китергәннәр [17].

Урта гасырларда Төньяк рус җирләреннән казан татарлары тормыш өчен бик тә кирәкле һәм мөһим булган товар — тоз алганнар [18]. Бу хакта С.Герберштейн искәртә.

Русларда һәрвакыт Идел балыгына ихтыяҗ булган һәм С.Герберштейн, Казан ярминкәсе эшләүдән туктаганнан соң, русларда «яхшы балыклар җитми» дип очраклы гына язмый. Руслар Казан сәүдәгәрләреннән балык сатып алып

15. Пр. ДРВ. Ч.8. — С.209; Ногайские дела, кн.3.

16. С.Герберштейн. Указ. соч. — С.145.

17. А.В.Эммауский. Вятская земля в период образования Русского государства. Киров, 1949. — С.25.

18. С.Герберштейн. Указ. соч. — С.157.

кына канәгатьләнмәгәннәр, ә хан хакимияте белән килешү нигезендә, даими рәвештә Идел елгасында балык тотканнар. «Казан елъязмачысы», 1521 елны Сәхибгәрәй тәхеткә утырганда, Шаһгалинең Казаннан качуын тасвирлаган текстны анализлаганда, шундый нәтиҗә соралып тора. «Казан елъязмачысы» Шаһгалинең Русь җирләренә килүен түбәндәгечә тасвирлый: «...һәм ул үзе белән Идел елгасында Кыз тавы һәм Еланташка, Увекка кадәр җирләрдә, Казаннан 1 мең чакрым ераклыкта, балык тотучы 10 меңгә якын рус балыкчысын алып китте. Алар анда барып, җәй буе кыргый сулыкларда балык тотып яшәгәннәр һәм көз көне баеп, Русь җирләренә әйләнеп кайтканнар [19]. [...]

Тарихчылар, Алтын Урда аркылы сәүдә юллары инде җимерелгән, ә Төркия белән сәүдә мөнәсәбәтләре әле яңа гына урнашып килгән дәвердә, Русьның Көнчыгыш белән сәүдәсе өчен Казанның зур әһәмияткә ия булуын гадел рәвештә билгеләп үтәләр. Руслар Казан аша тукымалар һәм төрле көнкүреш әйберләре кебек товарлар алганнар. Казанның көнчыгыш тукымаларына бай булуын, рус гаскәрләре яулап алгач, чиркәү йолаларын башкарганда файдаланылган күптөрле материяләр дәлилли [20].

XVI гасырда Көнчыгыш илләре белән алыш-биреш Рус дәүләтенең тышкы сәүдә товар әйләнешендә беренчел әһәмияткә ия була. Россия Шәрык илләреннән зиннәтле әйберләр генә түгел, ә төрле киң кулланылышта булган товарлар һәм сәнәгать продуктлары да ала. Бу хәтта рус теленең лексикасында да чагылыш тапкан. Казанлыларның әлеге процесста рольләре зур булган. [...]

Казанда махсус «Таҗик сарае» булган, анда көнчыгыш товарлары белән сәүдә иткәннәр һәм Шәрык илләреннән килгән сәүдәгәрләр яшәгән. Бу сарай шәһәрнең үзәк өлешендә, Спас мәйданында урнашкан [21]. Рус чыганакларында «тезикләр» (таҗиклар) дип аталучы Урта Азия сәүдәгәрләре Казанда даими яшәгәннәр. Казанны алганда, елъязмачы: «...палаталардан һәм базлардан очсыз-кырыйсыз байлык алынды, күп күләмдә әсирләр, кенәзләр, морзалар, тезик хатыннары һәм балалары, гади кешеләр алынды», — дип яза [22].

Тарихчы Н.Высоцкийның тикшеренүләре Казан шәһәрендә хәзерге Сукно бистәсендәге әрмән урамнары тирәсендә Әрмән бистәсе булуын күрсәтә. 1889 елда Н.Высоцкий тарафыннан Әрмән урамының Өченче тауга тоташкан урынында, «Немец ныгытмасы» дип аталган җирдә берничә борынгы каберлек һәм каберташлары табыла. Профессор Патканов әйтүенчә, ташбилгеләрнең берсендә сакланып калган язу әрмән язуы булып чыга. Н.Высоцкий үзенең материалларының анализына нигезләнеп: «Немец ныгытмасы» борынгы әрмән зираты булган», — дигән фикергә килә [23].

19. ПСРЛ. Т.XIX. Стлб. 32-33. — С.244.

20. См: Список с писцовой и межевой книги по г. Казани с уездом. Казань, 1877. — С.10-11.

21. См.: П.Заринский. Очерки древней Казани. Казань, 1877. — С.158-159.

22. ПСРЛ. Т.XIX. Стлб. 466-467 [...]. Встречающееся иногда в литературе отождествление среднеазиатских купцов — тезиков с иранскими купцами-кизилбашами следует признать ошибочными [...].

23. Н.Высоцкий. «Немецкая куртина» — древнеармянское кладбище в Казани. (ИОАИЭ. Т.VII. — Казань, 1889. — С.4.) [...].

24. ПСРЛ. Т.XIII. Ч.1. Никоновская, или Патриаршая летопись. — С.130.

Казанны Иван Грозный яулап алганда, шәһәрдә булган чит ил сәүдәгәрләре дә зыян күрә. Елъязмада 1551 елны «Идел һәм Чулман буенча күп җирләрдә казанлылар һәм кырымлылар, Казанда булган нугайлылар һәм бохаралылар кыйналдылар», — дип языла [24].

1552 елны рус гаскәрләре Казанны камап алган вакытта, шәһәрдә бик күп чит ил сәүдәгәрләре булган. «Казанлылар... үзләре белән биш мең чит ил сәүдәгәрен, бохаралыларны һәм шамахларны, төрекләрне, әрмән һәм башкаларны ябып куйдылар...» — дип яза вакыйгаларның шаһиты булган «Казан патшалыгы тарихы» авторы [25].

Казан көньякта якын күршеләре — нугайлар белән дә җанлы сәүдә элемтәләр тоткан. Казан сәүдәсендә нугайлыларның төп шөгыле — ат сату булган. «Үзебез, ат белән күченүчеләр, бу елда Казанга кадәр күчендек һәм ат белән сәүдә иттек», — дип яза Мәскәү бөек кенәзенә нугай морзаларының берсе [26]. Казанда нугай атларын сату Тезиц сарае янында урнашкан махсус ат сату мәйданында башкарылган [27]. Шулай ук, нугайлар сату өчен Казанга көтүләре белән бәрәннәр дә куып алып килгәннәр. Әйтик, мәсәлән, бервакытны Казанда нугайлылар тарафыннан 2 меңгә чаклы бәрән сатылган [28].

Казан базарлары җирле халык тарафыннан сату өчен җитештерелгән әйберләргә бай булган, чөнки аның янындагы төбәкләрдә шактый зур күләмдә тире, балавыз, бал, мех җитештерелгән, кыйммәтле тиреләр эшкәртелгән һәм балык тотылган. Венецияле И.Барбаро әле XV гасырда ук Казанның, кыйммәтле тиреләр сату үзәге буларак, гаҗәеп зур әһәмияткә ия булуын ассызыклаган: «Шәһәр (ягъни Казанда) Россияне, Польшаны, Персияне һәм Фландрияне кыйммәтле җәнлек тиреләре белән сату итеп, тәэмин итеп тора...» [29].

Шулай итеп, Казаннан чыгарылган барлык әйберләр дә ике төркемгә бүленә: 1) җирле халык җитештергән әйберләр (һөнәрчелек, кәсепчелек һәм авыл хуҗалыгы әйберләре); 2) реэкспорт товарлар (Руська һәм Көнчыгышка чыгарылучы көнчыгыш һәм рус әйберләре). Бездә чыгарылган теге яки бу товарларның күләме турында мәгълүматларга ия булмасак та, шулай да реэкспорт товарларның чагыштырмача зур күләмдә булуын, ягъни Казан сәүдәсенең транзит характерга ия булуын танырга кирәк.

Русчадан ***Ленар Гобәйдуллин*** *тәрҗемәсе*

25.ПСРЛ. Т.XIX. — Стлб.130.

26. Пр. ДРВ. Т.VII. — С.350.

27. См.: Материалы по истории Татарской АССР. Писцовые книги по городу Казани 1565-1568 гг. и 1646 г. Л., 1932. — С.70.

28. Пр. ДРВ. Т.IX. — С.258, 269.

29. Барбаро И. Путешествие в Тану. В кн.: Библиотека иностранных писателей о России. Отд. первое. Т. I. СПб., 1936. — С.60 (русский текст); 96-97 (итальянский текст).

Чыганак: Мухамедьяров Ш.Ф. Социально-экономический и государственный строй Казанского ханства (XV — первая половина XVI вв.). — Казань: Изд-во «Ихлас», Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2012. — С.182-197.

КАЗАН АЛЫНУ

КАЗАН ХАНЛЫГЫ ТАРИХЫ КҮП КЕНӘ РОССИЯ ҺӘМ ЧИТ ИЛ ГАЛИМНӘРЕНЕҢ ИГЪТИБАРЫН ҖӘЛЕП ИТТЕ ҺӘМ ХӘЗЕР ДӘ ҖӘЛЕП ИТӘ. КЫЗГАНЫЧ КИ, ХӘЗЕРГЕ КӨНГӘ КАДӘР ЧИТ ИЛ АВТОРЛАРЫНЫҢ ТАРИХИ ХЕЗМӘТЛӘРЕ РОССИЯ ТАРИХЧЫЛАРЫНА АЗ ДӘРӘҖӘДӘ ГЕНӘ БИЛГЕЛЕ БУЛДЫ.

Явыз Иван гаскәрләре Казан янында. Нияз Хаҗиәхмәтов

АЛМАН ТАРИХЧЫЛАРЫ КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ ЯУЛАП АЛЫНУ СӘБӘПЛӘРЕ ҺӘМ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА

МАРАТ ГАТИН,
тарих фәннәре кандидаты,
Казан (Идел буе) федераль университеты доценты

Моны түбәндәге сәбәпләр белән аңлатырга мөмкин. Беренче сәбәп — күп еллар дәвамында чит ил тәҗрибәсенә тиешле дәрәҗәдә игътибар булмаган һәм тискәре мөнәсәбәт яшәп килгән. Озак вакытлар чит ил историографиясе идеологик кысалардан чыгып кына өйрәнелде. Мондый караш галимнәрнең хезмәтләре белән төрле яктан җентекләп танышырга һәм аларны бәяләргә мөмкинлек бирмәде. Икенче сәбәп безнең ил тарихчыларының чит телләрне начар белүләре белән бәйле иде.

Шул сәбәпләр нәтиҗәсендә чит ил галимнәре хезмәтләрен инкарь итү, күрмәмешкә салышу яшәп килде. Әмма шунысы бәхәссез: чит ил тарихчылары үзләренең хезмәтләрендә иске проблемаларга карашны яңарта яки галимнәр алдына яңа мәсьәләләр куя. Төрки-татар ханлыкларын өйрәнүче чит ил галимнәренең фикерләре бездә кабул ителгән карашлар, тенденцияләрдән берникадәр аерылып тора.

Казан ханлыгы һәм Мәскәү дәүләте арасындагы мөнәсәбәтләр күпкырлы булган. Аеруча бу илләр арасында ике як өчен дә файдалы сәүдә мөнәсәбәтләре һәм мәдәни багланышлар турында әйтергә кирәк. Әмма алман галимнәре, Россия тарихчылары кебек үк, Казан белән Мәскәү арасындагы хәрби каршылыкны беренче планга куялар. Безнең бу мәкаләбездә алман тарихчылары аеруча игътибар биргән өлкә — Казан ханлыгын яулап алуның сәбәпләре һәм аның нәтиҗәләре яктыртыла.

Мәскәү дәүләтен Урта Идел буендагы татар ханлыгын яулап алырга нинди сәбәпләр этәрә соң? Алман тарихчылары моның шактый күп сәбәпләрен атый.

Алман тарихчысы Ханс фон Эккардт 1947 елда бастырылган Явыз Иван турындагы хезмәтендә түбәндәгеләрне яза: «Бай Казан ханлыгы аны үзенә тарта; Идел буйларына хуҗа булу көчле теләккә, ә анда рус авыллары оештыру максатка әверелә». Яулап алуга Алтын Урданың дәвамчылары булган дәүләтләр арасында бердәмлек булмау тәэсир иткән. Тарихчы фикеренчә, госманлы солтан бары тик Кырым ханлыгын һәм даланың көнбатыш өлешендәге «татар кабиләләрен» генә яклый алган, ә көнчыгыш өлеш исә читтә калган һәм берниндидә ярдәм өмет итә алмаган [2, s.101-102].

Зөя шәһәрен төзү.
XVI гасыр миниатюрасыннан

Россиянең урта гасырлар тарихы буенча иң атаклы белгеч, Көнчыгыш Германия тарихчысы Эрих Доннерт фикеренчә, беренче чиратта, «Россия дәүләтенә куркыныч янаган юлбасарлар оясын» кичекмәстән туздырырга кирәк булган. Көнчыгыш Германия тарихчысы, Россия галимнәре фикерләрен тәкрарлап, Идел буенда Казан һәм Әстерхан ханлыкларын яулап алуның

сәбәбе төрки-татарлар яшәгән көньяктан куркыныч янау көчәю, рус йомышлы дворяннарының яңа җирләр турындагы таләпләрен канәгатьләндерү мөһим булу, шулай ук сәүдә ихтыяҗлары белән бәйле, дигән фикер әйтә. Көньяктан һәм көньяк-көнчыгыштан «татардан килгән куркыныч» белән көрәшү «Россияне татарлар золымыннан азат итү»нең дәвамы булган. Казан яугирләренең һөҗүмнәре нәтиҗәсендә халык хуҗалыгына килгән зыян «даими үскән». Болардан кала Казан меңләгән рус колларын җыйган урын буларак күзалланган. Э.Доннерт язуынча, рус җәмгыятенең барлык катлаулары өчен дә ул әсирләрне азат итү зур әһәмияткә ия булган. Россиянең Казанга каршы сугышы гади халык тарафыннан гадел сугыш буларак кабул ителгән. Рус йомышлы дворяннары яңа җирләр алырга өметләнгән һәм монастырьлар да шуны көткән. Рус чиркәве Россиянең татарларга каршы сугышын «алласызлар»га каршы изге сугыш буларак күзаллаган. Татарларга каршы актив барган тышкы сәясәт рус сәүдәгәрләре һәм һөнәрчеләре өчен дә файдага булган [3, s.303-305, 307-309].

Күптомлы «Рус тарихыннан очерклар» дип аталган хезмәттә Мәскәү патшалыгы һәм Явыз Иван турындагы бүлекнең авторлары — Казан тарихын өйрәнгән Көнбатыш Германия тарихчысы Франк Кемпфер һәм Россиянең урта гасырлар тарихы буенча зур белгеч Гюнтер Штёкль Казан ханлыгы рус крестьяннары һәм йомышлы дворяннары өчен уңдырышлы җирләрне арттыру мөмкинлеге, «озак еллар гамәлгә ашмаган теләк» булган дип саныйлар. Шулай ук Казан каласы, тулысынча татарлардан яулап алынгач, Идел буенча Көньякта һәм Урал таулары аша Шәрыкта сәүдә һәм сәяси эшләр алып бару үзәге ролен үти башлый [4, s.879].

Кёльн университеты профессоры Лотар Рюль фикеренчә, «сугыш (Казанны яулап алу) аның (Явыз Иван) өчен, соңрак террор кебек үк, югары катлау вәкилләрен, шәһәрләрне һәм көчле монастырьлары белән чиркәүләрне буйсындырыр өчен кирәк була. Сугыш киләчәктә үзәкләштерелгән бөек кенәз хакимиятен ныгыту, салым һәм штрафларны арттыру, буйсынган төбәкләрне унификацияләү чарасы була». Галим, фикерен дәвам итеп, болай дип белдерә: «Иван IVнең Идел буе татарларының иң эре ханлыгы Казанга яуны «имансызлар һәм Гайсәнең дошманнары»на каршы һөҗүм итеп күрсәтүе мантыйкка ярашлы була һәм ул чиркәүгә «изге сугыш» игълан итәргә куша». Иванга беренче зур татар дәүләтен яулап алу христиан динендәге әсирләрне азат итү, христиан Россиясен ислам куркынычыннан саклау һәм православие динен тарату өчен кирәк булу белән аңлатыла. Патша «исламның көнчыгыш авангардын» юк итәргә теләгән. Мәскәү, Казан белән читтән торып идарә итү өчен, барлык чараларны да күрә, әмма алар нәтиҗәсез була. Идел буе татар ханлыгының буталчык эчке сәясәтенә берничә дистә еллар

1. Kusber, J. Um das Erbe der Goldenen Horde: das Khanat von Kazan' zwischen Moskauer Staat und Krim¬tataren // Zwischen Christianisierung und Europäisierung: Beiträge zur Geschichte Osteuropas in Mittealter und früher Neuzeit. Festschrift für Peter Nitsche zum 65. Geburtstag. – Stuttgart: Steiner, 1998. – S.293-312.

2. Eckardt, H. von. Iwan der Schreckliche. – Frankfurt am Main: Vittorio Klostermann, 1947. – 396 s.

3. Donnert, E. Russland an der Schwelle der Neuzeit. Der Moskover Staat im 16. Jahrhundert. – B.: Akademie-Verlag, 1972. – 502 s.

4. Kämpfer, F.; Stökl, G. Russland an der Schwelle zur Neuzeit. Das Moskauer Zartum unter Ivan IV. Grosnyi // Handbuch der Geschichte Russlands. Hrsg. von M.Hellmann. – Bd.1. – Hbd.2. Bis 1613. Von der Kiever Reichsbildung bis zum Moskauer Zartum. – Stuttgart: Anton Hiersemann, 1989. – S.854-961.

5. Rűhl, L. Aufstieg und Niedergang

буе тыкшыну Казанга кырым татарларының үтеп керүе куркынычын тудыра. Татарларның кырымлылар хакимияте астына берләшүе, Кырым ханлыгының терәге Госманлы империясе һәм күрше Нугай Урдасы булуын исәпкә алсаң, үсеп килгән рус дәүләте өчен моның ни белән бетәчәге билгесез вакыйга булыр иде. Иван IV һәм аның киңәшчеләре киләчәккә карап эш йөрткән. Әмма бер очракта да, Л.Рюль раславынча, Мәскәү өчен бу сугыш саклану сугышы булмый. Аның фикеренчә, Иван IVнең Казанга һөҗүме чын мәгънәсендә халык сугышы була. Җиргә ихтыяҗ сугышның төп сәбәбен тәшкил итә. Рус мәнфәгатьләре Азиягә ышанычлы сәүдә юлларын һәм Казанда рус сәүдәгәрләренең куркынычсызлыгын таләп итә [5, s.104-105, 111-113].

Алман тарихчылары Казанны яулап алуның нинди нәтиҗәләрен күрәләр соң? Монда шунысын да әйтергә кирәк: алар, Россия белгечләре кебек үк, Казан ханлыгын 1552 елда яулап алу халыкны буйсындыруга китергән дип саныйлар. 1552-1557 еллардагы «Казан сугышы»н исәпкә алмыйлар, аны еш кына «баш күтәрү» дип атыйлар.

Берлин университеты профессоры, рейхсканцлерлар Х.К.Гогенлоэ һәм Б.Бюлов киңәшчесе Т.Шиманн «XVII гасырга кадәрге Россия, Польша һәм Ливония тарихы» исемле хезмәттә ханлыкны яулап алуның нәтиҗәләре турында түбәндәгеләрне яза: «Казан походы шуның белән зур файдага ия, ул илбасарлар оясын тулысынча туздыра, әмма шул ук вакытта илнең эчке үсешендә тискәре нәтиҗәләргә дә китерә». Тарихчы фикеренчә, Казан ханлыгын яулап алуның нәтиҗәсе булып Россиядә Явыз Иван тираниясе һәм деспотиясе үсүе тора. Т.Шиманн: «Азиягә татар дәүләтләре ябып торган юл тулысы белән ачыла. Нугайлар һәм әстерханлылар арасындагы эчке каршылыкларны оста файдалану беренчеләре белән уртак тел табуга юл ача, ә Әстерхан ханлыгы 1557 елны буйсынырга мәҗбүр була. Европадагы татар хакимиятен тулысынча юкка чыгару инде якын киләчәк эше булып күренә башлый. Хәзер русларның йогынтысы Кавказга һәм Себергә кадәр киңәя. Кырым ханлыгы Мәскәүгә каршы торырлык көч туплый алмый, Мәскәү исә аңа каршы көрәшкә Днепрда мөһим союздашын — казакларны таба» [6, s.257-259].

Берлин университеты профессоры А.Брюкнер Казан ханлыгын яулап алуда христиан диненең исламны җиңү тантанасын күрә. Казанның яулап алынуы, Берлин университеты профессоры уенча — Европаның Азияне җиңүе ул. «Хурлыклы коллыктан һәм кызганыч җиңелүләрдән соң, гасырлар үткәч, ниһаять, зур уңышка ирешелде. Кылган куркыныч

Казанны камап алу.
XVI гасыр рәсеме

һәм кансыз ерткычлыкларына карамастан, алдагы йөзьеллыкта Иван IV — Россияне Азия хакимлегеннән азат итүче, дип хозурландылар... Уңышның нәтиҗәләре бәһаләп бетергесез булды. Россиянең үзәк өлкәләрен һәм Себерне Идел аша Ока һәм Чулман елгалары ярдәме белән тоташтырган, уңай урынга урнашкан Казан ханлыгы җирләре хәзер рус йогынтысын көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгышка тарату базасы булып хезмәт итә ала... Каспий диңгезенә кадәр Идел елгасы тулаем рус елгасына әйләнсен өчен вакыт кына кирәк иде». Әгәр дә Европа Куликово кырында һөҗүмнән сакланган булса, хәзер ул үзенең чикләрен Азия хисабына бермә-бер киңәйтә [7, s.466-467].

Ханс фон Эккард раславынча, «коточкыч ханлык» тулысы белән һәм бик зур көч сарыф итмичә яулана. Алман тарихчысы фикеренчә, «Иван башка диннәргә карата түзем булган һәм бернинди хорафатларга да ышанмаган». Төп мәгънә шуннан гыйбарәт: Явыз Иван «татарлардан килүче куркыныч»ны бетерә, кардәшләрен коллыктан азат итә, Шәрык белән бәйләп торган мөһим сәүдә юлларын кулга төшерә [2, s.104, 244].

Күренекле ориенталист Б.Шпулер: «Идел буендагы мөстәкыйль дәүләтләрнең юкка чыгуы татар халкы өчен нинди нәтиҗәләр бирде?» — дигән сорауга җавап эзли. «Мөстәкыйльлек аларга үзләренең мәдәниятләрен, диннәрен сакларга мөмкинлек, һәм шулай ук XIII гасырдан бирле гомер иткән җирләрендә баш булып яшәү хокукын бирә иде, — дип яза ул. — Үз ханлыкларының юкка чыгуы (Кырымнан кала) хәлләрнең тамырдан үзгәрүенә китерә. Бөтен Идел буе рус сәясәте йогынтысы астында кала һәм ул ислам цивилизациясе өчен бернинди дә сәяси роль уйнамый башлый. Ханлыкның алынуы татарларның киләчәк язмышын хәл итә... Руслар киләчәктә татарларның халык буларак яшәп калуын теләмиләр, шунда ук урта гасыр христиан дәүләтләренә хас булган, алга таба Идел буен руслаштыруны күздә тоткан миссионерлык белән шөгыльләнә башлыйлар» [8, s.62-63].

Германия Демократик Республикасы историографиясендә Казан ханлыгы тарихы проблемаларына бәйле русоцентристик шәрехләүләр өстенлек итә. Россиянең урта гасырлар чоры тарихы буенча белгеч, көнчыгыш Германия тарихчысы Э.Доннерт үзенең хезмәтләрендә совет историографиясенең төп нигезләмәләрен кабатлый: Идел буе халыкларына төрекләрдән янаган куркыныч һәм төрки-татар дәүләтләренең варварларча агрессив мөнәсәбәтләре турында белдерә [3, s.305] . Идел буендагы ханлыкның фаҗигасе турында Э.Доннерт «Рус патшалыгы. Дөнья империясенең күтәрелүе һәм бетүе» исемле хезмәтендә Казан һәм Әстерханны рус дәүләтенә кушу күпмилләтле дәүләткә илткән тагын бер адым иде, дип яза. «Россия үзенең йогынтысын Кавказ алдына кадәр киңәйтә алды», — дип ассызыклый. Э.Доннерт: «Казан һәм Әстерхан татарларын җиңү Көнчыгышта һәм Көньякта Иван IV экспансиясенең башлануы булды. Мили-

des Russischen Reiches: Der Weg eines tausendjährigen Staates. – Stuttgart: Deutsche Verlag Anstalt, 1992. – 664 S.

6. Schiemann, T. Geschichte Russlands, Polens und Livlands bis zum 17 Jahrhundert. – Bd.2. – B.: Historische Verlag Baumgärtel, 1887. – 410 s.

7. Brückner, A. Geschichte Ruβlands bis zum Ende des 18. Jahrhunderts. – Bd.1. Überblick der Entwickelung bis zum Tode Peters des Groβen. – Gotha: F.A.Perthes, 1896. – 638 s.

8. Spuler, B. Geschichte der islamischen Länder, ein Überblick. Die Mongolenzeit. – B.: Wissenschaftl. Edionsges, 1948. – 76 s.

9. Donnert, E. Das russische Zarenreich. Aufstieg und Untergang einer Weltmacht. – München; Lpz.: List Verlag, 1992. – 477 s.

10. Donnert, E. Iwan Grosny «der Schreckliche». – B.: Union Verlag, 1980. – 285 S.

11. Kappeler, A. Russland als Vielvölkerreich.

таристик Мәскәү дәүләте дала Урдасы дәүләтләрен бер-берсенә оста итеп каршы куя һәм котырта алды. 1552 елдан соң патшага Кавказ алдына үтеп керергә һәм кабардин, чиркәс кенәзләрен хәрби хезмәткә алырга мөмкинлек туды» [9, s.73]. «Шулай итеп, Ливон сугышы алдыннан Мәскәү көнчыгыш һәм көньяк чикләрендә Кара диңгез ярларына, Каспийга кадәр өстенлеккә иреште», — дип яза. «Гомумән, XVI гасырның 50 нче елларындагы татарга каршы уңышлы сәясәт, — алман тарихчысы фикеренә караганда, — рус дәүләтендә мөһим тышкы сәяси мәсьәләне — Балтыйк диңгезенә чыгар өчен көрәшүне башларга мөмкинлек бирә». Шул ук вакытта тарихчы Мәскәү дәүләтенең бу вакыйгаларга кадәр үк Балтыйк диңгезенә чыккан булуын оныта [3, s.311].

Явыз Иванга багышланган тикшеренүләрендә Э.Доннерт түбәндәге нәтиҗәләргә килә: «Казан йортын юкка чыгару һәм аны рус дәүләте белән кушу дөньякүләм тарихи вакыйга булды. Бу Россиянең бөек держава булуын аңлата. Иван IV гаскәрләре тарафыннан Казанны алу татарларның дөнья белән хакимлек итү дәверенә нокта куйды» [10, s.305].

Күптомлы «Рус тарихыннан очерклар»ында Мәскәү патшалыгы һәм Явыз Иван турындагы бүлекнең авторлары Франк Кемпфер һәм Гюнтер Штёкль 1552 елгы вакыйгалар һәм аның нәтиҗәләре турында: «Казанны яулап алу Мәскәү аграр дәүләте һәм үзләрен Алтын Урданың дәвамчылары дип санаган, көньяк рус далаларының хакыйкый хуҗалары булган күчмәннәр арасындагы көрәшнең башы булды», — дип билгеләп үтәләр [3, s.894]. «Рус патшалыгы, — белгечләр билгеләвенчә, — бер дистә елга якын вакыт эчендә үз кул асларына борынгы рус өлкәләреннән көнчыгыштагы җирләрне, Урал төбәген дә кертеп кулга төшерә һәм, чынлыкта, бу төбәкләрдә үзен «Батый олысы»ның дәвамчысы буларак таныта» [3, s.897].

Россия милли сәясәте тарихы белгече, Вена университеты профессоры Андреас Каппелер үзенең «Россия — күпмилләтле дәүләт. Барлыкка килүе. Тарихы. Таркалуы» (1992) исемле хезмәтендә 1552 елгы вакыйгаларны һәм аларның әһәмиятен түбәндәгечә бәяли: «Казанга каршы яу исламга каршы тәре походлары рәвешендә иде». Мәскәүнең сәясәте шушы агрессив максатларны тормышка ашыруны күздә тота. Патша киңәшчесе протопоп Сильвестерның ханлыктагы мөселманнарны һәм мәҗүсиләрне христиан диненә кертергә чакыруы, кирәк булган очракта бу гамәлдә көчләргә, мәҗбүриләргә өндәве тормышка ашырыла. Казан шәһәрендәге ир затлары үтерелә, мәчетләр җимерелә, алар урыннарына православие чиркәүләре төзелә, затлы нәсел вәкилләре Мәскәү дәүләтенең өлкәләренә мәҗбүри озатыла, аларны анда чукындыралар, әгәр дә каршы килсәләр суга батыралар [11, s.31]. А.Каппелернең үзенең С.Червоная белән бергә язган мәкаләсендә сүз Идел буе мөселманнарына карата алып барылган геноцид турында бара. Вена университеты профессорының сүзләренә караганда, «Мәскәү дәүләте, Идел буенда Казан һәм Әстерхан ханлыкларын яулап алып, үзе өчен шундый уңай стратегик халәт тудыра ки, ул аңа Далада үзенең йогынтысын арттырырга һәм Алтын Урда мирасына бәйле каршылыклы бәхәсләрдә актив роль уйнарга мөмкинлек бирә». «Мәскәү әкренләп Алтын Урда мирасчысы буларак үз урынын ныгытканнан-ныгыта бара» [11, s.42].

Ханлыкны яулап алуның нәтиҗәләрен Л.Рюль аеруча җентекләп тасвирлый: «Бу — Идел буе татарларын тулысынча буйсындыру хисабына һәм Европа үлчәме буенча зур мәйданнарны яулап алу нәтиҗәсендә, Россиянең һәм Мәскәү дәүләтенең күтәрелүе иде». «Яулап алулардан соң, Мәскәү патшасы, чын мәгънәсендә, «падишаһ» булды. Бу хакта ул руслар өчен һәрвакыт «патша» бул-

ган югары хаким — ханны тәхеттән төшергәнче, ягъни элеккеге вассаль мөнәсәбәтләр бетерелгәнче биш ел элек игълан итте». Алман тарихчысы: «Рус халкының үзаңында Казанны яулап алу ике гасыр ярым дәвам иткән читләр хакимиятеннән һәм ясак түләү мәҗбүриятеннән коткара... 1552-1556/1557 елларда Казан һәм Әстерханны яулап алу Россияне көнчыгыш юнәлештә — Урал таулары аша — Себерне, ә Җаек елгасы аша Урта Азия далаларын экспансияләүгә этәрде. Мәскәү патшасы яулап алган җирләр бик зур иде... Моңа кадәр бер генә рус хакиме дә мондый зур яулап алуларга ирешә алмады», — дип яза [5, s.105, 111, 113-115].

Берлинның Тюркология институты хезмәткәре Себастьян Цвиклински фикеренчә, ханлыкны яулап алу мәчетләрнең җимерелүенә, мөселманнарның шәһәрдән куылуына һәм, үз чиратында, рус хакимиятенә каршы восстаниеләргә сәбәпче була [13, s.7-8].

Алман тарихчылары хезмәтләрендә Мәскәү дәүләте һәм Казан ханлыгы мөнәсәбәтләре проблемасын тикшереп, түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкин.

Алман тарихчылары ханлыкны яулап алуның бик күп сәбәпләрен күрсәтәләр. Бу мәсьәләгә карата бердәм караш күзәтелми. Күп кенә Кайзер Германиясе һәм ГДР тарихчылары русларның һәм совет тарихчыларының фикерләрен кабатлыйлар. Алар язуынча, дәүләт буларак Казан ханлыгы рус җирләрен талау, мал-мөлкәтләрен урлау чыганагы булган. Шул сәбәпле, алар фикеренчә, ханлыкны яулап алуның төп сәбәбе — һөҗүм итү оясын юкка чыгару, рус әсирләрен азат итү һәм бу төбәкләргә Госманлы империясенең үтеп керүен туктату.

Германия Федератив Республикасы тарихчылары исә рус йомышлы дворяннарына яңа җирләр кирәклеге турында таләпләрен, Казанның сәүдә үзәге буларак тоткан мөһим урынын, «алласызларга каршы» «тәре походы» оештыруда Рус православие чиркәвенең эшчәнлеген алгы планга куялар.

Казан ханлыгын яулап алу мәсьәләсендә алман историографиясе үзгәреш кичерә. XIX гасырга караган хезмәтләрдә татар дәүләтен яулап алу, гомумән алганда, уңай бәяләнә. Казан ханлыгы җимерелү «юлбасарлар оясын» туздыру, рус җирләрен Азия хакимиятеннән азат итү буларак карала. XX гасырда исә күпчелек алман тарихчылары 1552 елгы вакыйгаларда Россиянең империя буларак оешу процессын һәм шуның нәтиҗәсендә Көнчыгыш Европада татар хакимиятенең юкка чыгуын гына күрәләр. Берлин тарихчылары да Казанны яулап алу нәтиҗәләренең Мәскәү өчен булган тәэсире турында гына язалар. Бары тик Б.Шпулер, А.Каппелер һәм С.Цвиклински кебек галимнәр генә Казан алынуының татарларга йогынтысына игътибар итәләр, бәйсезлекне югалтуның татар халкы тарихында тискәре күренеш булуын ассызыклыйлар.

Русчадан ***Ленар Гобәйдуллин*** *тәрҗемәсе*

Entstehung. Geschichte. Zerfall. – München: Verlag C.H.Beck, 1992. – 395 s.

12. Каппелер А.; Червонная С. Мусульманские народы России: историческое введение // Ислам в Евразии: современные этические и эстетические концепции суннитского Ислама, их трансформация в массовом сознании и выражение в искусстве мусульманских народов России. – М.: Традиция – Прогресс-Традиция, 2001. – С.98-118.

13. Cwiklinski, S. Die Wolga an der Spree. Tataren und Baschkiren in Berlin. – B., 2000. – 68 s.

МӘСКӘҮ ҺӘМ КАЗАН: ДАЛА ДИПЛОМАТИЯСЕ МОДЕЛЕ ТУРЫНДА КАЙБЕР ГОМУМИ ФИКЕРЛӘР*

ЭДВАРД КИНАН,
Гарвард университеты профессоры (АКШ)

«Модель» сүзе термин буларак тарихи әдәбиятта еш кулланылмый, тарихчыларда ул хәзерге яңа фәннәр белән ассоциацияләшә. Мин бу сүзгә, тасвирланачак сюжетларны өйрәнгәндә, ниндидер төптән уйланган методология кирәк булганын ассызыклар өчен мөрәҗәгать итәм. [...]

Мәскәү-Казан мөнәсәбәтләре тарихына карата билгеле бер системага яки күренешләр «моделенә» корылган, шул рәвешчә тәртипкә салынган чагыштыру ысулын тәкъдим итү максатыннан шушы терминны кулландым. Шулай иткәндә бу системаның мантыйгы турыдан-туры сакланып калмаган вакыйгалар турында да мәгълүмат бирә ала. Лингвистлар бу методны югалган тел формаларын ачыклар өчен кулланалар, кайберәүләр кроссвордлар чишкәндә файдалана.

Московиянең татар дала дәүләтләре белән мөнәсәбәтләрен өйрәнүче кеше шундый ук бурычны хәл итү — аз микъдарда сакланган һәм билгеле булган мәгълүматларны мөмкин кадәр файдалырак һәм тулырак итеп куллану юлларын табу алдында кала. Бер үк вакытта ул модельнең төгәл контурларын билгеләргә, тулган кәрәзләрдә сакланган мәгълүматлардагы мантыйк һәм функциональ элементләргә нигезләнеп, буш калган кәрәзләрне ачыкларга, аларны җентекләп мәгълүмат белән тутырырга тиеш. Мин биредә шундый модельләрне тасвирлауның берничә юлы һәм төрле дәрәҗәдә үзем тутыра алган кәрәзләр турында сөйләмәкче булам. [...]

Алар (тарихчылар — *ред.*) тарафыннан еш кына барлык вакыйгалар да «кайнар» мөнәсәбәтләргә күчә торган дини һәм милли «салкын сугыш» рәвешендә аңлатылды. Мәскәү дәүләте, мондый сугышка тартылып, гасырлар дәвамында башта «Алтын Урда калдыклары» белән, соңрак Госманлы солтаны тарафыннан җитәкләнгән панисламистик коалициягә каршы көрәшкән, дип язылды. Бу нәүбәттән, 1480 ел Алтын Урданың формаль суверенитетын юкка чыгарган, ике

*Кинан Эдвард. Московия и Казань: некоторые вводные замечания к модели степной дипломатии // Панорама-форум. — 1995. — №1. — С.66-81. Мәкалә кыскартып бирелә.

чорны аерып торучы көчеш сызыгы буларак бәян ителде. Казан белән мөнәсәбәтләрне тасвирлау исә Идел буе дәүләтен яулап алу өчен ясалган һәм күпсанлы уңышсызлыклардан соң көтмәгәндә 1552 елда җиңү белән тәмамланган яуларга кайтарып калдырылды. [...]

Чынбарлыкта исә Алтын Урда калдыклары үзара сугыша, ниһаять, 1480 еллар тирәсендә бер төркем җиңүгә ирешә. Мәскәү дә, Казан һәм Кырым белән бергә, җиңеп чыккан коалициянең әгъзасы була. Дәүләтләр арасында мөнәсәбәтләр прагматик һәм күпчелек очракта дустанә булып, аларның дипломатиясендә дини һәм милли каршылыклар нинди дә булса роль уйнамый. Шуңа күрә 1480 елның «татар игосы»на бернинди катнашы да юк. Госманлы дәүләтенең бу чордагы Мәскәү-татар мөнәсәбәтләренә зур йогынтысы турында бернинди мәгълүматлар да билгеле түгел; панисламизм идеясе — буш сүз. Казанны алу (моны шулай ук Хаҗитарханга карата кабатларга була) башкалар белән берләшүдән, үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, Мәскәү ягына чыккан татар-мөселманнарның ярдәменнән башка һичкайчан тормышка ашмас иде.

Сүзне шушындый рухта тагын дәвам итәргә мөмкин, ләкин бу урында, төп ялгышларны тикшерүдән туктап, мин, үземнең фикерләрне раслау өчен, «модельләр» турындагы дискуссиягә әйләнеп кайтырга телим.

Мәскәү-татар мөнәсәбәтләрен өйрәнүче тарихчының беренче бурычы — кулланыла торган чыганакларны төркемләү һәм аларның формаль моделен булдыру. Чыганакларның типлары табигый иерархия тәртибендә урнаштырылырга тиеш, алар арасында беренче урынны дипломатик чыганаклар алып тора. Фәкать алар гына документаль характерда, әлеге чыганаклар, адресатка аталган мәгълүматны җиткерүдән тыш, башка вазифалар үтәмәгәннәр. Кызганычка каршы, мондый чыганаклар тулы түгел һәм алар бу очракта Мәскәү елъязмалары мәгълүматларын туплаган күрше кәрәзләр ярдәмендә реконструкцияләнергә тиеш.

Елъязмалар — дипломатия тарихы буенча шактый четерекле чыганаклар. Аларның төп вазифасы — пропаганда, һәм алар дипломатлар тарафыннан түгел, бәлки Мәскәү мәдәниятенең «чит» вәкилләре — дин әһелләре тарафыннан язылган. Бу ике мәдәният бер-берсеннән шундый нык аерыла, еш кына ике төрле һәм капма-каршы мәгълүматлар агымы хасил итә. Без Мәскәү мәдәнияте турында ниндидер гомуми караш булдырганчы, бу тема үстерелергә тиеш.

Без һәрбер төрдәге чыганакның формаль контурларын ачыкларга тиеш булабыз. Дипломатия документлары төшенү өчен авыр һәм чиста славян теле кысаларында аларны аңлау мөмкин түгел диярлек (аларның елъязмачылар тарафыннан да бик еш кына аңланмый калганын әйтеп үтәргә кирәк). Мәскәү дипломатлары килгән хәбәрләрне үзләре дә аңламыйча укыганнар, язып барганнар һәм җавап биргәннәр дигән фикерне исә салкын акыл кире кага.

Дипломатлар жаргоны сыман төгәл, килештерелгән һәм консерватив жаргон башка юк. Нәкъ менә шушы килешенгәнлек, традиция безгә бу текстларны аңларга ярдәм иткән модельне тәшкил итә дә инде. Чөнки алар Каһирәдән алып Пекинга кадәр һәм Вильнодан алып Дәһлигә кадәр дипломатия теле булган Үзәк Азия төрки теленнән шактый консерватив, калькалаштырылган һәм сүзгә-сүз башкарылган тәрҗемәләр булып тора. Ул шул дөнья өчен латин теле ролен башкарган. [...] Бу стиль Бөек Пётр чорына кадәр кулланылган, дипломатлар аны Һиндстандагы Могол идарәчеләре белән язышканда файдаланганнар [1]. [...] Бу документларны төрки тел үрнәкләре

Нугайларның күченү күренеше. Россия картасыннан фрагмент. 1572 ел

белән чагыштырып укысаң, табигый, мәгънә охшашлыгы күзгә ташлана. Алар халыкара мөнәсәбәтләр буенча гына түгел, ә татар дәүләтләренең мәдәнияте һәм хакимият институтлары характеры турында мәгълүмати яңа дөнья ачарга сәләтле. […]

Бу чыганакларның структурасы турында күп сөйләп булыр иде, ләкин, әйдәгез, хәзер аларны кулланып, татар институтлары моделенә, дала сәясәтенә һәм, гомумән, Мәскәү сәясәтенә мөрәҗәгать итик.

Әйтик, безне кызыксындырган вакыйгалар Казан ханлыгының сәяси структурасына турыдан-туры бәйләнешле һәм анда үзәк урынны биләп тора. Алтын Урда калдыкларында барлыкка килгән ханлыклардагы сыман, «хан системасында» яшәгән Казан ханлыгының сәяси төзелеше турында бик үк анык булмаган мәгълүматлар сакланып калган. Бу факт, гомуми күзаллау өчен Мәскәү чыганаклары биргән мәгълүматларга нигезләнеп, шактый ышанычлы модель төзергә һәм аны, күрше кәрәзләрдәге шуңа охшаш дәүләтләр турындагы мәгълүматны кулланып, мөһим детальләр белән тулыландырырга мөмкинлек бирә. Мондый типтагы системаларда ханнарның сузерен буларак вазифалары һәм чыганакларда «җир» дип атала торган төбәкнең социаль-икътисади элитасы арасында шактый тирән упкын яши. Теоретик яктан бер генә дәүләт тә ханнан (Чыңгыз хан нәселе дәвамчысы) башка яши алмый: ул мөстәкыйльлекне гәүдәләндерә, дипломатия, югары мәхкәмә һәм хәрби өлкәләрдә өстенлекле вазифаларга ия була. Хан урынын әлегә биләмәгән дәвамчыны «җир» традицион мөстәкыйль хакимият булган урыннарның берсенә тәхеткә утырырга чакырырга, «җир» аның кандидатурасын кабул итәргә тиеш була. Элеккеге Алтын Урда биләмәләрендә андый урыннар дүртәү: Казан, Кырым, Хаҗитархан һәм Себердә Төмән. Алар төрле характердагы йогынтылы хезмәттәшлек үзәкләре булып, бигрәк тә икътисади яктан дала белән дала булмаган өлкәләрне тоташтырган урыннарга әверелгән. Әлеге үзәкләрдәге иҗтимагый һәм икътисади тормыш көчле күчмә кланнар, сәүдә династияләре һәм игенче җәмгыятьләре тарафыннан контрольлек ителгән. Бу магнатлар чыганакларда «кенәзләр» дип атала («бәк» — төркичә, «кенәз» — русча). Шулар арасында дүртесе «карачы» титулына ия булган (бу термин монгол чорында бөтен Алтайга хас), алар дәүләт советын тәшкил иткән.

Бер генә хан да карачылар ярдәменнән башка идарә итә алмаган, чөнки соңгыларының карары нигезендә ул үзенең сараен һәм хәрби иярченнәрен тоту өчен җир алган, билгеле бер салымнарга, монополияләргә ия булган

һ.б. Бу — килешүгә нигезләнгән мөнәсәбәтләр. Ханны кабул итеп, «җир» дәүләткә әверелгән, ә хан, үз чиратында, «карачы»ларны дәүләт советы итеп раслаган. Ләкин болар бер үк вакытта хәрәкәтчән мөнәсәбәтләр булган, әгәр дә гадәти шартларда «җир» ханнан котылырга теләсә, аерым индивидуум яки династия үзенең хакимиятен нығыта алса, ул инде Кырымда еш күзәтелә торган тулы автократия рәвешен алган. Чыганаклар безгә Кырым баш «карачы»сының Василий IIгә Миңлегәрәйнең үлеме һәм тәхеткә аның улы Мөхәммәтгәрәй утыру турында язган хатында сурәтләнгән зәгыйфь тотрыклылыкның төгәл чикләрен күрсәтәләр: «Бог сделал меня князем и Менгли-Гирей сделал меня князем, и если кто-либо мог бы придираться ко мне или спорить со мной, это был этот Менгли-Гирей, кто мог сказать: «Я сделал тебя князем…», но этого хана (ягъни Мөхәммәдгәрәйне — *ред.*) бог сделал ханом, так же, как и четверо из нас «карачи», под моим руководством сделали его ханом».



Татар (нугай). Немец гравюрасы. XVII гасыр

«Алла» дип биредә, әлбәттә, нәселдән килгән хокук аталган. Кенәзләр, Чыңгызыйлар кебек, үзләренең дәрәҗәләренә билгеле бер олылык системасы хисабына ирешкәннәр. Шул вакытта аларның статусы хан тарафыннан гадәти символик никах аша расланган. Бу бик нәзакәтле һәм катлаулы мөнәсәбәтләр була, һәм без алда күрербез: Мәскәү дипломатлары моны аңлап һәм хәйлә белән бик оста эш йөрткән. Әйе, алар бу системаның асылына төшенгән, ә менә тарихчылар тиешле дәрәҗәдә игътибарга алмаган. Ә бит шуннан башка Мәскәү-Казан мөнәсәбәтләрен аңлау мөмкин түгел.

Хәзер дала сәясәтенең башка контурларына да игътибар итү кирәк. Гамәли яктан кыпчак далалары үзенә күрә җир диңгезе буларак күзаллана: без атаган шәһәрләр — аларның портлары, кәрваннар — аларның сәүдәгәр конвойлары, төрки һәм славян казаклары — пиратлары. Урта диңгездәге кебек үк, алар сәяси киртә дә, икътисади арадашчы яки ялгаучы бәжра ролен дә үтәгән. Ләкин бу чагыштыру тулы түгел, чөнки далада күчмәннәр яшәгән һәм алар күчмән терлекчеләр тарафыннан контрольдә тотылган. Әлбәттә, алар диңгезчеләр һәм балык тотучылар ролен дә уйный алганнар, ләкин бу очракта соңгыларының мөһим үзенчәлекләрен исәпкә алырга кирәк. Бу вакытта иң көчле күчмәннәр саналучы нугайлар үзләренең билгеле бер көчәнү циклы барышында әлеге

«порт»ларга даими кереп йөргәннәр, тик бу биләмәләрендә шәһәрләр булмаган һәм алар шәһәрләр булдырырга омтылмаганнар да. Чыңгыз хан вакытындагы монголлар кебек, нугайлар даланы яшәү өчен яраклаштырылган урын дип кенә түгел, ә сәяси һәм хәрби хакимият тупланган урын дип тә күргәннәр. Чыңгыз, әйтик, кем даланы үз кулында тота, шул шәһәрләрне дә буйсындыра дип санаган. Башка күчмәннәр кебек үк, нугайлар да, шиксез, шәһәрләрсез яши алмаган: базарларга үзләренең терлек көтүләрен һәм ат табуннарын куып килгән, биредә, үз чиратында, көнкүреш өчен мөһим булган тоз, тимер һәм башка шуларга охшашлы кирәк-ярак алган. Күчмә һәм утрак тормыш алып баручы җәмгыятьләр арасындагы идеаль мөнәсәбәтләр үзара тыкшынмауга нигезләнгән булырга тиеш, һәм ул бердәмлекне тәэмин итәчәк дип саналган. Нугайлар мәскәүлеләргә еш кына болай дип әйткәннәр: «Без тавыкның ботын сындырмыйбыз, сез дә колынның ботын сындырмагыз» [2]. Мәскәүлеләрнең бернинди колыннарга, бигрәк тә аларны сатып алгач, тияргә теләмәүләре бу чорда гадәти күренеш булган: алар ел саен нугайлардан төньяк-көнбатышта сугышлар алып бару өчен кирәкле 30-40 мең ат алып кайтканнар. Көнчыгыштан мәскәүлеләр атлар гына кайтармаган: XVI гасырның уртасына кадәр традицион Идел һәм дала юллары Мәскәү өчен иң мөһим тышкы сәүдә артерияләре булып торган [3].

Концептуаль структураның тагын бер мөһим элементын атау сорала. Ул — славян-татар мөнәсәбәтләре нигезенең рухы. Документаль чыганаклар, дипломатлар язышуы елъязмаларга капма-каршы килә, бу мөнәсәбәтләрнең прагматик кына түгел, тышкы яктан, чыннан да, дустанә, милли һәм дини ызгышсыз булганын раслый. Мин моны дипломатик язмаларда елъязмалардагы мәсхәрәләү теле кулланылмаудан күрәм. Дипломатлар мәдәни һәм дини аерымлыкларны исәпкә алмаган гына түгел, аларны ачыктан-ачык таныганнар һәм шулар нигезендә карар кабул иткәннәр. Һәрьяк икенче якның дини мәдәниятен шул дәрәҗәдә ихтирам иткән ки, моны бүгенге тарихчылар мөмкин хәл дип кабул итмиләр. Килешүләр, гадәттә, дини ант белән беркетелгән, антны һәрьяк үз дине тәртибендә биргән («һәрберсе үз дине буенча» дип хәтта елъязмаларда да әйтелә): мәскәүлеләр — тәре белән, мөселманнар — Коръән белән, шушы максатлар өчен бер данә Коръән Кремльдә саклаган. [...]

Без даланы бербөтен сәяси һәм икътисади система буларак карыйбыз, һәм ул 1390 елларда Аксак Тимер тарафыннан икътисади нигезе җимерелгәннән (Азак, Хаҗитархан, Үргәнеч) алып Идел буе үзәкләрен Мәскәү басып алуларына кадәрге чорда коточкыч зәгыйфьләнү кичерә. Бу көчсезләнү, әлбәттә, Госманлы дәүләтенең яулап алулары һәм Европадагы бөек географик ачышлар йогынтысында барлыкка килгән халыкара сәүдә өлкәсендәге революцион үзгәрешләрнең бер өлеше була. Аның нәтиҗәсендә Үзәк Азиядәге кәрван юллары үзләренең элеккеге әһәмиятләрен югалталар.

Бу торгынлыкны сәяси яктан өч өлешкә бүлеп карарга мөмкин. Беренче фаза 1470 елларга кадәр дәвам иткән һәм бер-берсен тулыландырган ике процесс белән билгеләнгән: сәяси хакимиятнең үзәктән читтәге күптән утрак тормыш мәдәнияте булган дәүләтләргә күчүе һәм аларның һәрберсендә якын киләчәктә яңа династияләргә нигез салачак сәяси һәм икътисади берләшү өчен көрәш. Бу — империя таралганнан соң була торган гадәти күренеш. Ләкин биредә шунысын да исәпкә алырга кирәк: Сарайда көчле сәяси хакимиятнең юкка чыгуы Сарай империясенең элеккеге өлкәләре

Җиз комган. XVI гасырның II чиреге. Казан

арасында элемтәләрне өзми. Өч мөһим үзәктә (Мәскәүдә — Василий IІнең нәселе, Бакчасарайда — Хаҗигәрәйнең нәселе, Казанда — Олуг Мөхәммәднең нәселе) барлыкка килгән династияләр тотрыклы булмаган килешүләр һәм үзгәреп торган язмышлар чорында еш кына төркемнәргә берләшә. Бер оешкач, алар ныклы союз төзегәннәр, ул союз даланың тотрыклылыгын гына тәэмин итеп калмый, ә ярты гасыр дәвамында шактый дәрәҗәдә Көнчыгыш Европа тарихы барышын да билгели.

Союзның төп максаты һәм икенче этапның төп билгесе булып, шиксез, далада тотрыклылыкны саклау исәпләнә. Үзәктән читтәге дәүләтләр моңарчы Алтын Урда тәэмин итеп торган көнчыгыш базарлар белән турыдан-туры элемтәләр урнаштыруга елдан-ел ныграк мохтаҗлык кичерә, аларга шулай ук терлек һәм терлекчелек азыклары кирәк булган. Тотрыклылыкның мөһим шарты булып күчмәннәр өстеннән, бигрәк тә Сарайга якын урнашкан һәм «Олы Урда» дип аталган кабиләләр берләшмәсе өстеннән контроль урнаштыру торган. Башка кабиләләр утрак тормыш алып барган дәүләтләрнең башкалаларында үзләренең йогынтыларын көчәйтүче династияләр тирәсендә берләшкәндә, Олы Урда Чыңгызыйлар белән бергә баш шәһәрсез кала.

Ул чорда күпчелек конфликтларның килеп чыгуында үзенә «утырырга» урын эзләүче Олы Урда гаепле була. Мәскәү, Кырым һәм Казан союзы шушы омтылышларны тыярга, далада тынычлык урнаштырырга һәм Олы Урда тирәсендә боҗраны кысарга мәҗбүр ителә. Эш уңышлы хәл кылына (бу яктан 1502 елны кырымлылар тарафыннан Хаҗитарханны алу мөһим роль уйный). Әлеге җиңү шулкадәр хәлиткеч була ки, далада барлыкка килгән вакуум нәтиҗәсендә элеккеге фикердәшләр үзләре каршылыкка тартылалар. Килеп чыккан яңа конфликт өченче этапны ачып җибәрә һәм якынча 1520 елдан башлап русларның Идел буен яулап алуларына кадәр дәвам итә.

Мәскәүнең Казан белән мөнәсәбәтләрен шушы сәяси барышның, шушы процессларның бер өлеше итеп карау мәҗбүри.

Бу мөнәсәбәтләр Олуг Мөхәммәд тарафыннан ханлык оештырудан, 1445 елда Василий IІне әсир итеп алудан һәм аны азат итүдән башланып китә. Историография традициясе бу вакыйганы алласызларга каршы алып барылган бетмәс-төкәнмәс көрәш барышында милләт дәрәҗәсендәге бәла дип бәяли, ләкин Василий IІнең шундук диярлек азат ителү сәбәпләрен аңлатмый. Кайбер елъязмалар зур суммадагы ясакка ишарә ясый, ә марксист тарихчылар биредә хезмәт ияләренә каршы заговор күрә. Без ышанычлырак аңлатма бирә алабыз. Василий IІне азат итү

Җәя һәм ук садаклары комплекты. Татар ханлыклары. XVI гасыр

Кырым ханы Габделгәрәйнең улы Шаһингәрәй шлемы. 1666-1671 еллар

ике арадагы союзны рәсмиләштерә һәм Шемякага каршы гражданнар сугышын җиңү белән тәмамларга мөмкинлек бирә. Бу вакыйга — Василий һәм аның дусты Олуг Мөхәммәд өчен озакка сузылган мөнәсәбәтләрне көйләүнең кульминациясе. Алар инде элегрәк тә берләшкән булалар. 1432-1433 елларда Василий кышны Олуг Мөхәммәднең Кырымдагы ставкасында үткәрә. Елъязмалар бу вакыйганы шартлы һәм искергән сүз — «ярлык алу» белән аңлаталар, вакыйлар исә аларның сәяси мәсьәләләрне киң масштабта, шул исәптән Московиядә, Литвада, Кырымда берләшү процессларын тикшергәннәрен раслый.

Фикер алышу озак һәм кискен бара: Олуг Мөхәммәдкә Кырымны алырга ярдәм иткән кайбер кабиләләр Василийны яклаганнар, кайберләре Юрий Дмитриевич һәм аның союзнигы Свидригайло белән союз төзергә өндәгәннәр [4].

Көчләр мөнәсәбәте һәрхәлдә нугайлар килгәч үзгәрә: Олуг Мөхәммәд мәсьәләне Мәскәүне яклаучы кланнар файдасына хәл итәргә мәҗбүр була. Шулай итеп, Василий аның союзнигына әверелә. Биш ел узгач, үзен яклаган кланнар Кече Мөхәммәт ягына авыша, ә соңгысы Олуг Мөхәммәдне Кырымнан кугач, ул нәкъ менә Василийга мөрәҗәгать итә. Олуг Мөхәммәд, Мәскәү кенәзлегенең чик буенда урнашкан Белёв шәһәренә килеп, үзенең союзнигыннан яшәп торырга урын сорый. Елъязмалар аның тыныч мөнәсәбәтләр яклы булуын күрсәтә [5].

Юрий Дмитриевичның ике улы (Шемяка һәм Дмитрий Красный) Василий белән сугышмасалар да, аларның арасында яхшы мөнәсәбәтләр урнашуын теләмиләр һәм Олуг Мөхәммәдкә һөҗүм итәләр. Мәскәүлеләр җиңелүгә дучар була, ләкин Олуг Мөхәммәд көнчыгышка борыла һәм ахыр чиктә Казанга килеп төпләнә. Шуңа күрә Василийның 1445 елда Олуг Мөхәммәд тарафыннан иреккә чыгарылуы һәм хөрмәт белән татарларның ике отряды озатуында җибәрелүе шаккатырмый. Бу хәрби отрядлар белән Олуг Мөхәммәднең уллары Касыйм

һәм Якуб җитәкчелек итә, алар Василийның мөһим союзниклары булалар һәм уртак дошман Шемяканы җиңүгә күп ярдәм күрсәтәләр, соңрак Василийның көнбатышка походларында катнашалар.

XVI гасырның 70 нче елларына кадәр шушы модель яшәп килә. Казан белән, соңрак Кырым белән тыныч мөнәсәбәтләр мөһим булган көнчыгыш сәүдәсе тотрыклы үссен өчен гарантия бирә. Бу модель шулай ук көньякта чагыштырмача куркыныч булмаган чик буен булдырырга мөмкинлек һәм Московиянең Төньяк-Көнбатышта зур уңышларга ирешүенә юл ача. Мәскәүнең көньяк-көнчыгыштагы чиге 1520 елларга кадәр тотрыклы, ул чик әле монголлар килгәнче үк славян-төрки халыклары яшәгән чик була, утрак тормышлы халыкларны һәм күчмәннәрне бүлеп тора. Алай гына түгел, чагыштырмача тынычлык хөкем сөргән чик буе ныгытылмаган була. Биредә вакыт-вакыт күзәтелеп торган татар отрядларының аерым һөҗүмнәрен гадәттәгедән чыгарма дип билгеләргә кирәк. Аларны кайбер татар дәүләтләренең үзара килешеп оештырган дошмани сәясәте дип бәяләү һич кенә дә дөреслеккә туры килми. Табыш артыннан куып һөҗүм итү төрки-монгол күчмә системасының яшәү рәвеше булып тора. Шуңа күрә, рус елъязмалары дәлилләгәнчә, Кырым һәм Казан ханнарына буйсынган күчмәннәр күпсанлы мөстәкыйль яулар оештыра торган. Алар без аңлаган хәрби «кампанияләр» булмаган, алай гына да түгел, хакимлек итүчеләрнең теләкләренә һәм тәкрар иткән сәясәтләренә каршы килеп үткәрелгән. Мәскәү сәясәтен дә сугышчан дию дөреслеккә туры килмәс.

Бу системада бернинди каршылыклар да күзәтелми дип әйтеп булмас. Ләкин шунысы ачык: Новгородны көчсезләндерү һәм яулап алу да, Иван IIIнең башка зур уңышлары да, ике

Иван IV нең (Явыз Иванның) «Казан бүреге». XVI гасыр уртасы

фронтта көрәш алып барган очракта, нугай атларыннан һәм татар отрядлары ярдәменнән башка, шулай ук ныгытылмаган көньяк-көнчыгыш чикләреннән ерактагы Мәскәү хәрби көчләренә таянмыйча мөмкин булмас иде. Һичшиксез, дала белән тынычлык мөнәсәбәтләре 1445 елдан башлап 70 ел дәвамында Мәскәүнең тышкы сәясәтенең мөһим шарты булып торган.

Ул очракта гел кабатланып торган Казанны «алырга» омтылуларны ничек аңлатырга? Алар мин тасвирлаган тотрыклы системаның эшчәнлеген вакытлыча бозу, көчле һәм үз мәнфәгатьләрен күздә тотучы «яхшы күршеләрнең» эчке конфликтларына тыкшыну буларак кабул ителергә тиеш. Мисал өчен мин беренче һәм соңгы сугышларга гына тукталырмын.

Елъязмалар безгә 1468 елны Касыйм ханның Иван III тарафыннан Казанга каршы җибәрелүе, ләкин мәскәүлеләрнең буш кул белән кире кайтулары турында хәбәр итә. Әмма алар Касыймның олы ир туганы Мәхмүтнең үлүе һәм Казан тәхетенә варис мәсьәләсе килеп чыгу, мәрхүмнең хатынының Мәскәүгә баруы, биредә Касыймга кияүгә чыгуы һәм бу

адымның татар идарә традицияләренә хас һәм тирән мәгънәгә ия булганын, нәтиҗәдә, Касыймның ир туганы тәхетенә варис хокукын алуы турындагы «ваклыкны» әйтми калдыралар. Шириннәр — идарә итүче карачылар нәселе вәкилләре — Мәхмүт ханның хатынын Мәскәүгә җибәрүгә сәбәпче: шулай итеп алар Мәскәүдә егерме ел яшәгән Касыймның Казанга хан булып утыруын ачыктан-ачык яклаганнар. Мәгълүм ки, мондый очракларда, «җир» мәнфәгатьләренән чыгып, төбәк белән бәйләнеше нык булмаган берәр ханны чакырырга тырышканнар. Бу эшкә Иван III кысыла һәм үзенең күптәнге союзнигының өлкән туганын Казан тәхетенә утыртуны кайгырта. Әлеге кампания Казанда каршылыклар хәл ителү белән тәмамлана. Башка детальләр дә безнең шушылай аңлатуны раслый, бу модель узган гасырда күп тапкырлар кабатлана: Мәскәү «кампанияләре» әле бер, әле икенче җирле төркем чакыруы буенча чит дәүләт эшләренә еш кына кыюсыз тыкшынгалап тора, гомумән, мондый күренеш Казанның сәясәтенә хас була.

Шуңа охшаш фикерне 1552 елны Казан алыну уңаеннан да әйтергә була. Аны түбәндәгечә бәяләргә мөмкин. 1549-1552 еллардагы хәрби кампанияләрдә инде кыюсызлыкка урын калмый. Мәскәүнең көче алдагы дистә елларда шул дәрәҗәдә үсә ки, Көнбатышта тынычлык урнашу белән, Василий III һәм Иван IV регентлары Көнчыгышта ачыктан-ачык басып алу сәясәте үткәрә башлыйлар. Васильсурскка нигез салу һәм традицион Казан ярминкәсен Түбән Новгородка күчерү — шуны раслаучы билгеләр. Тотрыклылыкны югалтуга китергән икенче мөһим фактор булып Мәскәү белән Кырым арасында көрәшнең кискенләшүен атарга кирәк. Бу каршылык Казан «җиренә» бер ханны икенчесенә каршы куярга мөмкинлек бирсә дә, һичшиксез, икътисади хәл начараю шартларында Казан эчендәге төрле төркемнәр арасында көрәшнең һәм интригаларның кискенләшүенә китерә.

Хәтта шушы үзенчәлекләрне исәпкә алганда да безнең фикерләребез, гомумиләштерүләребез дөрес булып чыга. 1549 елны нугайлар Казанның иң мөһим союзниклары төсендә, ханның сәясәтеннән канәгать булмыйча, Мәскәүгә бергә хәрәкәт итәргә, Казанны Мәскәүгә кушарга һәм ханны Мәскәү вәкиле Шаһгали (инде хан булып торып караган) белән алыштырырга тәкъдим итәләр, ә нугай кенәзе Казанда баш карачы урынына риза була. Мәскәү бу тәкъдимгә күнә, ләкин хәрби чаралар уңышсыз тәмамлана. 1552 елны инде мәскәүлеләр җирле идарә катлавы вәкилләре белән килешү төзиләр. Алар җирле кенәзләргә ханны төшерергә, Мәскәү воеводасын кабул итәргә, җирле кенәзләрнең традицион табышлары һәм статуслары сакланган хәлдә, Мәскәү патшасына ханның барлык хокукларын, өстенлекләрен, табышларын бирергә тәкъдим итәләр. Бу яулап алу түгел, ә күбрәк читтән яңа хан чакыруга охшый, суверенитет дәрәҗәсендәге үзгәрешләр буларак күзаллана, ә Казан «җиренең» юкка чыгуын күздә тотмый. Әлеге шартлар кабул ителә, ләкин паника, бәлки канәгать булмаганнарның тарафыннан эшләнгән адымнар шәһәр капкаларының ябылуына китерә һәм камаудан саклануга хәзерлек башларга этәрә. Бу юлы шәһәр алына, каршы көчләр юкка чыгарыла. Иван IV шәһәргә җиңүче булып тантаналы рәвештә керә, сугышып җиңү аны үзенә кабул иткән йөкләмәләрдән азат итә. Ләкин ул элекке принципларны саклый — Казанны җирле халыктан чистарталар, тик күчмәннәр, бигрәк тә нугайлар, үзләренең көтүлек җирләрен, элеккеге өстенлекләрен һәм хәтта Казандагы табышларын саклап калалар.

1554 елда нугайлар ярдәме белән тиз һәм көч түкмичә генә Хаҗитархан яулап алына. Елъязмаларда Мәскәү агентларының хисаплары сакланган: «астазанские люди царю государю добили челом и в город... пришли и правду на том дали, что им служити царю и великому князю и ясак платити, как прежде сего царям астраханским плачивали... а царю и великому князю их жаловати и воевати не велети и ослободити кочевати по старым местам. И кочевали, и зимовали ногаи под Астраханью, и торговали во всю зиму в Астрахани довольно и полюбовно...» [6].

Московия хәрби чакыру ташламый гына даланы җиңә. Рус дипломатлары күчмәннәр өчен шәһәр хәрби яки сәяси үзәк түгел, ә күбрәк икътисади үзәк буларак әһәмиятле икәнне аңлый. Мәскәү биргән өстенлекләр аркасында, килешеп яшәү мөмкин була. Ләкин шунысы ачык: сәүдә һәм технологияләр үсеше тенденцияләре шәһәрнең әһәмияте артуга, төгәлрәк әйтсәк, утрак тормыш алып баручы җәмгыятьнең күчмәннәр өстеннән җиңүенә китергән. Бу дала җәмгыятенең соңы якынлашканны аңлаткан. Даланы кылыч түгел, ә төрән җиңә, тавык аттан өстенлек итә башлый.

Мин өч нәтиҗә ясарга тырыштым.

1. Бүгенге тарихи мәгълүмат җитешмәгән шартларда, материалны төгәл төркемләп, модельләр ясарга, күбрәк чыганакларның мәдәни контекстына һәм сәяси институтларны, традицияләрне анализлаганда, чагыштыру ысулына нигезләнергә кирәк. Соңгы очракта модельләр төрки дәүләтчелек тарихы буенча безнең белемнәребезгә һәм күчмәннәр белән утрак тормыш алып барган җәмгыятьнең симбиозына нигезләнгән булырга тиеш.

2. Аерым мөнәсәбәтләр бердәм дала тарихы рамкаларында өйрәнелергә тиеш һәм алар эчендә югарыда тасвирланган өч озын циклның аерып чыгарылуы шарт.

3. Ниһаять, мәдәни, бигрәк тә дини каршылыкларның дипломатлар эшчәнлегендә, чынбарлыкта бик тар урын биләп торганын атап үтү сорала. Бу факт гаҗәпләнерлек түгел, чөнки Московия барлыкка килгәннән бирле уртак дөньяның сәяси һәм икътисади аерылгысыз бер өлеше булган.

Мин, йомгаклап, тагын бер характерлы факт турында әйтеп үтәм. Миланнан Форциа белән латин телендә хат алышканда, Мәскәү падишаһлары үзләрен озакламый онытылачак «Albus Imperator» (Ак император) титулы белән атаганнар. Тарихчылар өчен бу термин гаять зур әһәмияткә ия. Мәскәүнең бөек кенәзе «Ак» яки «Көнбатыш» кенәзе саналган, соңрак билгеле бер мәдәни даирәдә үзен хан (русча «патша») дип атаган. Бу титулны куллану ул яшәгән дөньяны бәяли. «Ак патша» титулы Иван III өчен дә әһәмияткә ия. Ләкин «Ак патша» соңрак чорда славяннар һәм татарлар тарафыннан кеше тәне төсеннән чыгып, раса мәгънәсендә яңача уйнатылган, ул хәзерге тарихчылар белән урта гасыр кешеләре арасындагы күңелсез бер аңлашылмаучанлык рәвешендә яши.

Искәрмәләр

1. Русско-монгольские отношения в XVII веке. – М., 1958. – С.363 и др.
2. «Мы у курети не изломим, и вы у жеребяти ноги не изломите». (Кара: Касыйм морзаның Иван IV 1548 елның октябрендә язган хаты: Продолжение Древней русской вивлиофики. Т.8. – СПб., 1793. – С.94.)
3. Фехнер М.В. Торговля Русского государства со странами Востока в XV веке. – М., 1956. – С.19.
4. Полное собрание русских летописей (ПСРЛ), Т.XXV. – М.Л., 1949. – С.249.
5. ПСРЛ, Т.XXV. – С.260.
6. ПСРЛ, Т.XXIX. – С.225.

Русчадан ***Илдус Заһидуллин*** *тәрҗемәсе*

КАЗАН АЛЫНУ СӘБӘПЛӘРЕ ҺӘМ НӘТИҖӘЛӘРЕ: XXI ГАСЫР ЮГАРЫЛЫГЫННАН БӘЯЛӘҮ

460 ЕЛ ЭЛЕК КАЗАН АЛЫНУ УҢАЕННАН «ЧЫН МИРАС» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ ГАЛИМНӘРГӘ ӨЧ СОРАУ БЕЛӘН МӨРӘҖӘГАТЬ ИТТЕ.

1. Мәскәү белән мөнәсәбәтләрдә Казан һәм башка урта гасыр татар-төрки дәүләтләренең җиңелү сәбәпләре нинди дип саныйсыз?

2. Бүген XVI гасырның беренче яртысындагы Казан-Мәскәү мөнәсәбәтләре хакында чынбарлыкка туры килмәгән нинди фикерләр, мифлар яшәп килә?

3. XXI гасыр башы ераклыгыннан караганда, татарның урта гасыр милли дәүләтчелеге юкка чыгу татар халкына һәм Россия өчен нинди югалтулар, табышлар алып килде?

Вадим Винцерович ТРЕПАВЛОВ, тарих фәннәре докторы, Россия Фәннәр академиясенең Россия тарихы институты баш гыйльми хезмәткәре, Россия халыклары тарихын һәм этник мөнәсәбәтләрне өйрәнү үзәге җитәкчесе (Мәскәү)

1. Минемчә, төп факторлар булып түбәндәгеләр тора. Беренчедән, татар ханлыклары белән чагыштырганда, XIV-XV гасырларда алып барылган актив эчке сәясәт, игенчеләрнең яңа киң мәйдандагы җирләрне үзләштерүләре, җитештерелгән продукцияне оста итеп, үзәкләштерелгән идарә һәм поместьеләр системасын аралаштырып бүлү, зур сугышлар озак вакытка тукталып тору сәбәпле, уңай демографик шартлар булу Мәскәү дәүләтенең матди мөмкинлекләрен көчәйтә. Иван III тарафыннан зур һәм бай Новгород җирләре кушылганнан соң, Московиянең ресурслары күп тапкырлар арта.

Икенчедән, Мәскәү дәүләтенең хәрби яктан өстенлеге. XVI гасырда күпсанлы нугай атлары кертелү дворян ополчениесен ерак аралар-га походлар ясарлык атлы гаскәргә әйләндерергә мөмкинлек бирә. Моннан тыш XV гасырның уртасыннан рус хәрби көчләренә ат өстендә сугышучы күпсанлы йомышлы татар отрядлары кушыла. Рус һәм татарның корал комплекслары бер-берсеннән бик аз аерылса да, патша гаскәрләре XVI гасырның икенче яртысыннан башлап утлы коралның мөмкинлекләрен тор-

ган саен киңрәк куллана башлыйлар.

Өченчедән, татар ханлыклары конфликтлар һәм каршылыклар белән эчтән таркатыла, бу (күп тапкырлар тырышуларга да карамастан) Мәскәү экспансиясенә каршы озак вакытлы һәм бердәм фронт булдырырга комачаулый. Нәтиҗәдә, һәр ханлык Россиягә каршы берүзе каршы торырга мәҗбүр була.

Гомумән, минем фикеремчә, Евразиянең бу өлешендә геополитик хәл рус дәүләтчелегенең көчәюен һәм Урда дәүләтчелегенең тарихи аренадан китә баруын күрсәтте. Чөнки Алтын Урда калдыкларында оешкан барлык ханлыклар да бу дәүләтнең дәвамчылары иде. Тотрыклы икътисади системага һәм тышкы ярдәмгә таянырга мөмкинлек булганда, ханлыклар чагыштырмача тотрыклы дәүләт структураларына әверелгәннәр. Алар — халыкара сәүдә белән шөгыльләнгән һәм Госманлы дәүләте яклавы астында булган Кырым; борынгы Болгар цивилизациясе нигезенә таянган һәм Идел сәүдә юлының урта өлешен контрольдә тоткан Казан; шулай ук өлешчә элекке хан домены һәм иң көчле урбанлашкан элекке Җучи олысы өлкәләренең берсе булган Хаҗитархан.

Гомумән алганда, күчмә хуҗалык икътисадына нигезләнгән сәяси берләшмәләр (Олы һәм Нугай Урдалары, Казах ханлыгы) акрынлап сүнә, ваклана, үзәкләштерелгән идарә системасын югалта һәм, ахыр чиктә, көчлерәк күршеләренең корбаны була.

Себер йортына килгәндә, ул баштан ук Алтын Урданың зәгыйфь, азсанлы халык яшәгән, ресурсларга бай булмаган чик өлкәсе кебек оеша. Геополитик конфликтлар үзәкләреннән читтә урнашу аңа шактый озак вакыт мөстәкыйль яшәргә мөмкинлек бирә. Теләсә нинди көчле дошман белән бәрелешкән очракта ул җиңелүгә дучар ителәчәк иде.

2. Минем уемча, Россия аудиториясенә сеңдерелә торган төп миф булып казанлыларның Руська һөҗүм итүчәнлеге (агрессорлыгы) турындагы фикер тора. Һичшиксез, ике дәүләт арасында хәрби бәрелешләр күзәтелгән. Ләкин алар һәрвакытта да татар һөҗүмнәренең нәтиҗәсе булмаган. Алтын Урда таркалганнан соң, Мәскәү белән Казан, объектив зарурлыктан чыгып, тарихи үсеш мантыйгы буенча Көнчыгыш Европаның көнчыгышында беренчелек өчен көрәш башлыйлар (Көнчыгыш Европаның көнбатышында тагын да аяусыз һәм канлы көрәшне Мәскәү дәүләте Бөек Литва кенәзлеге белән алып бара). Кызганычка каршы, хәзергә урта гасыр татарлары турындагы массакүләм күзаллау тыныч тормыш алып баручы рус халкын җәфалаучы кыргый күчмә «орда» стереотибына кайтып кала. Шуңа күрә татарларның тарихи үткәнен популярлаштыру (гомумән Россиядәге славян булмаган халыкларныкы кебек үк) чиктән тыш әһәмиятле бурыч булып кала бирә.

Гамирҗан Миргаҗан улы ДӘҮЛӘТШИН, тарих фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры, Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты (Казан)

1. Патша һәм совет чоры историографиясендә Мәскәү дәүләтенең

Казан ханлыгын басып алуы ханлыкның һөҗүмнәреннән саклану чарасы, дип язылa. СССР чорында, коммунистик идеология хөкем сөргәндә, Ф.Энгельсның «Господство России играет цивилизаторскую роль для Чёрного и Каспийского морей и Центральной Азии, для башкир и татар» (К.Маркс и Ф.Энгельс. Соч. Изд. 2-е, т.27, С.241) дигән фикере өстенлек итте. Совет чоры тарихчысы, академик Милица Нечкина бу теорияне тагын да купшылатты.

2-3. Беренчедән, татар халкы үзенең милли дәүләтчелеген югалтты. Һәр халык милли дәүләте булганда гына үзенең этнокультур үзенчәлекләрен саклый, үстерә, аерым халык, милләт булып яши ала. Хәзерге чорда да татарның үз милли дәүләте булмау аның халык буларак яшәвен, телен, мәдәниятен саклап калуны зур куркыныч астына куя.

Шулай да күпчелек халыкларның милли дәүләте юк бит һәм шактыеның тарихи милли дәүләтләре булмаган да. Әмма безнең бабалар дәүләтле булган. Бу сыйфат аларның каннарына сеңгән. Әлеге дәүләтләр Евразия тарихында гаять әһәмиятле урын тоткан… Татар дәүләтләрен яулап алу татарны татар итеп саклауның иң әһәмиятле механизмын юкка чыгара.

Икенчедән, татар халкы шәһәр культурасын югалтты, тулаем диярлек авыл халкына әйләнде. Ә бит безнең бабалар дөньяда шәһәрләре белән дан тотканнар. Шәһәрләр сәяси, икътисади үзәкләр генә түгел, илнең дини, мәдәни, архитектура үзәкләре дә булганнар. Югары профессиональ культура хәзер дә һәм борынгы заманнарда да бары тик шәһәрләрдә генә яши, үсә ала. Рус яулап алуларыннан соң, милли профессиональ музыка, рәсем сәнгате, фән, үсеш җирлеге булмагач, башта торгынлык кичерә, аннан, гомумән, сүрелә.

Өченчедән, яулап алучыларга каршы көрәшне — Ватан сугышын югары катлам вәкилләре җитәкли. Шуның өчен дә яулап алучылар, иң беренче чиратта, татар дәүләтләренең югары катламын зәгыйфьләндерәләр, юкка чыгаралар. Урта гасырларда югары катлам ул — илне, халыкны оештыручы катлам, аның башы. Ил халкы башсызландырыла, «толпага» — халык өеренә әйләндерелә диярлек. Моннан тыш, ул чорларда югары катлам югары мәдәният әсәрләренә заказ бирүче, аны үзләштерүче дә. Шулай итеп, югары мәдәният, профессиональ культураның тагын бер нигез ташы зәгыйфьләндерелә.

Шулай да татарның профессиональ, язма культурасы бөтенләй юкка чыкмый бит! Әйе, моның сәбәбе, иң беренче чиратта, борынгы заманнардан килгән бу өлкәдәге көчле традициядә, шул исәптән ислам традициясендә дә. Татар мөселман руханилары мәгариф системасын саклап калалар. Бар мөселманнарны укуга тарталар. Профессиональ мәдәниятнең башка өлкәләрен саклап калуда, үстерүдә армый-талмый эшлиләр.

Хәтерсез, тарихсыз халыкның рухын сындыруы, аны коллыкка төшерүе җиңел. Шуңа күрә дә колонизаторлар, беренче чиратта, тарихи китапларны юкка чыгаралар, алып китәләр, тарихи һәйкәлләрне җимерәләр. Алар өчен җимерелгән һәйкәлләр дә, тарихны саклаган авыл, елга, чокыр исемнәре дә куркынычка әйләнә. Мәсәлән, хәзерге Болгар шәһәрлегендәге тарихи-архитектура истәлекләре исемнәре: «Четырёхугольник» (Җамигъ мәчет), «Красная, Белая палата» (җәмәгать мунчалары), «Чёрная палата» (дәрвиш, суфилар өчен ханәкә), «Греческая палата» (әрмән чиркәве). Яки шунда ук «Иерусалимский овраг», «Британское, Голландское озёра».

Татарларга сәүдә, тимерчелек, зәркән сәнгате белән шөгыльләнү, таш, кирпечтән йортлар төзү катгый тыела. Татар кешесе тимер балтаны да рус конторасына махсус барып, кәгазьгә теркәтеп сатып алырга тиеш була. Ә балта яраксыз хәлгә килгәч, татар кешесе яңасын искесен китереп тапшыргач кына сатып ала алган. Бабалары сәүдәдә, металлургиядә, архитектурада дан тоткан халык өчен бу бик хурлыклы була. Әлеге өлкәләрдә дә халык рухы имгәтелә. Искә төшерик: безнең бабаларыбыз Европада беренче чуен коючылар булганнар (XIV гасыр).

Кайберәүләр, рус яулап алуларын акларга омтылып, рус дәүләтендә татар дөньясы берләшә, диләр. Киресенчә, яулап алулары татар дөньясының тагын да ныграк таркалуына китерә. Мәскәү, Казан ханлыгын яулап алганда, беренче мәртәбә мәкерле «разделяй и властвуй» принцибын сынап карый. Төрле өлкәләрдә яшәгән татарларның үзара аралашуын кыенлаштыру өчен, татарларны олы юллардан (трактлардан), кораблар йөзәрлек елга буйларыннан күчереп утырталар. Күпгасырлык көчләп чукындыру сәясәте нәтиҗәсендә татар халкының керәшен татарлары этнографик төркеме оеша. Екатерина II (Әби патша) татарны күпгасырлык юкка чыгаруның нәтиҗәсезлеген аңлап, моның сәбәбен сакланып калган татар элитасында күреп, аны таркатырга тотына. Татар морзаларын документлы (дворяннар) һәм льготасыз морзаларга, татар сәүдәгәрләрен гильдияле һәм гильдиясез, татар муллаларын указлы һәм указсызларга аеруга ирешә. Татарлар укмашып утырган төбәкләргә рус дәүләтенең үзәгеннән рус авыллары күчереп утыртыла. Мондый сәясәт соңгы чорларга кадәр уздырыла. Татар халкын таркатуның күпләгән алымнары кулланыла. Шулай итеп, Мәскәү яулап алулары татарны берләштерде дигән фикер һич тә урынлы түгел.

Шулай да, Мәскәү яулап алуларының татар халкы өчен бер яхшы ягы да юкмыни? «Яулап алыну» дигән сүз үзе үк моңа тискәре җавап бирә. Татар халкы рус халкыннан, аның бай культурасыннан күп нәрсә үзләштерә. Ләкин бу үзебезнең милли тарихыбызны, татар телен оныттыру хисабына алып барылмасын иде.

Роман Юлианович ПОЧЕКАЕВ,
юридик фәннәр кандидаты, доцент, «Икътисад югары мәктәбе» милли тикшеренү университетының Санкт-Петербург филиалында хокук һәм дәүләт теориясе һәм тарихы кафедрасы мөдире (Санкт-Петербург)

1. Мин, беренче чиратта, ул сәбәпләргә Мәскәүнең Казаннан территориясе, матди ресурслары һәм кешеләр саны ягыннан өстенлеген кертер идем. Мәскәү бөек кенәзлеге (1547 елдан — патшалыгы) гасырлар дәвамында, әле Алтын Урда заманыннан башлап, идарә итү, финанслар, гаскәрне оештыру һ.б. өлкәләрдә татарларның күп кенә традицияләрен үзләштерә, үз көндәшенең тактикасын яхшы белә (ә Мәскәү гаскәрләрендә татарларның Казан гаскәренә караганда күбрәк булганын исәпкә алсаң, бигрәк тә!). Казан хакимияте исә Мәскәү дәүләте төзелеше һәм анда

хәрби эш торышының көчле яклары хакында күпкә начаррак хәбәрдар булган. Икенче сәбәп итеп Казан ханлыгының Кырым һәм Хаҗитархан ханлыкларыннан, шулай ук мөселман дәүләтләреннән — Бохара ханлыгы һәм Госманлы империясеннән — еракта урнашуын, аерымрак мөнәсәбәттә булуын атарга кирәк. Шул сәбәпле, ул дәүләтләр, бик теләсәләр дә, Казандагы дин һәм кан-кардәшләренә вакытында тиешле ярдәм күрсәтә алмыйлар. Өченчедән, кем һөҗүм итә — шул җиңә. Ә XVI гасырның уртасында һөҗүм итүче як Мәскәү була. Ул Көнчыгышка актив экспансия башлый. Казан исә сакланучы позициясендә чыгыш ясый, булганын сакларга тырыша, ләкин булганын да югалта бара.

2. Мифлар Казанны алганчы ук барлыкка килә башлаган, күрәсең. Чөнки Казанны яулап алуны «нигезләргә» кирәк була. Бүгенге көндә ике юнәлештәге мифларны атарга мөмкин. Беренче юнәлеш — идеологик. Ул күбрәк Рус-Казан мөнәсәбәтләре турында Россия (һәм совет) историографиясенә хас. Казан ханлыгының Россия чикләре янындагы паразит дәүләт булуы, аның максаты фәкать рус җирләренә һөҗүм итү, аларны талау, әсирләр алу икәнлеген тәкрарлау белән килешү мөмкин түгел.

Казан ханлыгы көчле, хокукый, мәдәни традицияләргә ия дәүләт булган, ул үз тарихының кайбер этапларында халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендә тигез хокуклы ил буларак чыгыш ясаган. Шуңа күрә аны яулап алуның сәбәбен фәкать рус чикләренә янаган куркынычны юк итәргә теләү белән генә аңлату дөрес түгел. Фәнни җәмәгатьчелектә мондый мифлар, я тарихи фактларны берьяклы аңлату, я кайберләрен әйтми калдыру юлы белән барлыкка килгән.

3. Татарлар өчен Казан ханлыгын Мәскәү дәүләтенә кушуның тискәре ягы, әлбәттә, рәсми мөстәкыйльлекне югалту була. Ханлык үзенең мөстәкыйль идарә органнарын, кануннарын да югалта, күпмедер дәрәҗәдә социаль күчешләр дә күзәтелә, җәмгыятьнең кайбер сыйнфый катламнарының статусы үзгәрә һ.б. Ләкин чынбарлыкта ханлыкның суверенлыгы Россиягә кушканчы ук, бигрәк тә соңгы ике дистә елда, инде шактый кимегән була. Ул 1480-1540 еллар аралыгында ук кими, ханлык үзенең монарх-сюзереннары буларак Мәскәү кенәзләрен, Кырым ханнарын (Казан тәхетендә идарә итүче Гәрәйләр йорты вәкилләре утырганда) таный. Ә 1520 елларда хәтта Госманлы империясе солтаны сюзеренитетын тану турында сөйләшүләр бара.

Шуңа күрә, татарлар өчен, Мәскәү дәүләтенә кушылу турында сөйләгәндә, ничек генә пародоксаль булмасын, социаль һәм сәяси-хокукый яктан тормышны тәртипкә салу мөһим була: тәхеткә я Мәскәү яклы, я Кырым яклы ханнар утыру җәмгыятькә зур тетрәнүләр китергән. Шуларга бәйле рәвештә ханлыкның затлы нәсел, төрле катлам вәкилләренең статусы үзгәреп торган.

Мәскәү дәүләтендә статуслары кимесә дә, алар сословиеләр баскычында үз урыннарын табалар. Билгеле булганча, күп кенә татар нәселләре вәкилләре Россия аристократиясе составына керә, дәүләт эшлеклесе, хәрби җитәкче буларак танылa яки тыныч тормыш шартларында яхшы карьера ясый. Идел буенда гасырлар дәвамында ханлык чорының (хәтта Алтын Урда вакытының да) аерым традицияләре, Чыңгызыйларның хо-

кук системасы элементлары сакланып килә: әле XVIII гасырга кадәр даругалар административ берәмлек булып тора, борынгыдан килгән тарханлык институты кала, салым урынына ясак җыела һ.б. Шулай итеп, Казан алынгач та, ханлык чорындагы хокукый һәм сәяси традицияләр шундук юкка чыккан, алар Мәскәүнең дәүләт һәм хокук институтлары тарафыннан кысрыклап чыгарылган дип сөйләү, әлбәттә, дөреслеккә туры килми.

Мәскәү өчен Казан ханлыгын кушу, һичшиксез, күптөрле проблемаларны хәл итәргә мөмкинлек бирә. Беренчедән, дошманнарының Идел буендагы татар дәүләтен рус җирләренә һөҗүм ясаганда җирлек итеп файдалану куркынычы бетә (хәрби-сәяси аспект). Икенчедән, бай һәм стратегик яктан мөһим төбәкне кушу сәүдә юллары үсешенә һәм Үзәк Россиядән Көнчыгышка таба яңа сәүдә үзәкләре үсешенә китерә (икътисади аспект). Ниһаять, өченчедән, үзенә зур территорияне генә түгел, ә тулы бер мөстәкыйль дәүләтне (бу мөстәкыйльлек шактый дәрәҗәдә номиналь булса да) буйсындыру Мәскәү монархларының дәрәҗәсен күтәрә. Россия тарихын өйрәнүче Европа галимнәренең кайберләре (мәсәлән, Э.Каррер д'Анкосс) Россия империясе турында инде 1552 елдан, Казанны кушкан вакыттан башлап сөйләргә мөмкин дип саный. Һәм аларны хаклы түгел, дип тә әйтеп булмый: чит дәүләтне кушу беренче вакытта Казан ханнары статусында булган Мәскәү падишаһларының дәрәҗәсен күтәрә. Чит дәүләт өстеннән сюзеренитет урнаштырып, Мәскәү падишаһлары de facto [факт буенча] үзләренең империалистик амбицияләре турында белдерәләр.

Шул ук вакытта, Казан ханлыгын кушу Мәскәү дәүләтен фәкать уңай нәтиҗәләргә генә китерә дию дә дөрес түгел. Беренчедән, Казан ханлыгы мөстәкыйльлеген Мәскәүгә карата дипломатик (кайбер вакытта хәрби) басым итеп файдаланган Кырым, соңрак Госманлы дәүләте белән озакка сузылган каршылык хасил була. «Казан патшалыгы»ның Мәскәү дәүләте составында XVIII гасыр башына кадәр аерым статуска ия булуы Мәскәү хакимиятенең, уңайсыз кискен сәяси хәл туган очракта, үзенә күрә бер саклану чарасы була; бу статус, Мәскәүнең халыкара авторитетын төшермичә, Казанга мөстәкыйльлеген кайтару мөмкинлеген калдыру өчен кирәк булган дигән фикер әйтергә җөрьәт итәм.

Искәндәр Аяз улы ГЫЙЛӘҖЕВ,
тарих фәннәре докторы,
Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры, Татарстан
Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы

1. Төп сәбәп бар кешегә дә ачык шикелле. Аны инде без ничә еллар кабатлыйбыз, ләкин барыбер гыйбрәт ала алмыйбыз. Ул — татарлар арасында бердәмлек булмау. Төрки-татар дәүләтләре үзара уртак тел таба алмаганнар, дәүләтләр эчендә дә даими низаглар күзәтелгән. Җитмәсә, Мәскәү хөкүмәте үз файдасына бик мәкерле сәясәт алып барган, бар чаралар белән ул татар җәмгыятен эчтән

таркатырга тырышкан. Казан ханлыгында Мәскәү файдасына тырышып эшләүчеләр аз булганмы? Ә Казанга каршы һөҗүм оештырылган вакытта Мәскәү гаскәрендә күпме татар булган? Бердәмлек булмау — татарның күптәнге авыруы. Кызганыч ки, ул бүген дә сизелә — татарда шундый ямьсез гадәт яшәве барыбызга да мәгълүм. Бездә бит һәрвакыт «мин» генә хаклы, без башкаларны тыңларга теләмибез, барыбызны да борчый торган милли мәсьәләләрне чишкәндә дә «мин-минлек» өстенлек ала. Соңгы вакытта калкып чыккан мәгариф, мәдәният, тел өлкәсендәге җитди мәсьәләләрне генә искә төшерик. Без шул очракта да берләшә алмыйбыз. Барыбер ызгыш-талашлар чыгарабыз, үзара сугышабыз, төп мәсьәлә чишелми кала, ә кемдер моны күреп шатланып кына тора…

2. Билгеле булганча, тарихны җиңүчеләр яза. Шуңа күрә бүген Россиядәге рус күзлегеннән язылган тарихта татар тарихына, шул исәптән Казан-Мәскәү мөнәсәбәтләренә карата мифлар буа буарлык. Төп миф, әлбәттә, татар-рус мөнәсәбәтләрен бәяләү өлкәсенә карый. Имеш, Мәскәү тыныч «холыклы» дәүләт булган, аның әйләнә-тирәсендәге, күршесендәге бары тик агрессив, вәхши дәүләтләр һәм халыклар бер уйфикер белән генә яшәгән — шушы матур, тыныч тормыш алып барган Рус дәүләтен яулап алырга яки, һич булмаса, таларга. Казан ханлыгы, башка татар дәүләтләре менә шундый вәхши юлбасарлар булган, имеш. Сорап карагыз сез рус кешеләреннән: алар тарихчы булмасалар да, тарихны яхшы белмәсәләр дә, күпчелек шундый карашлар белән яшәп килә. Ул чордагы дәүләтләргә бәя биргән вакытта без бүгенге сәяси терминологияне кулланырга тиеш түгелбез. Сугыш урта гасыр өчен табигый күренеш. Мәскәү-Казан мөнәсәбәтләре ул — Алтын Урда чорыннан ук формалашкан дәүләтара сәяси көндәшлек нәтиҗәсе, һәм бу шартларда Рус дәүләте көчлерәк булып чыккан, уңышка ирешкән. Мәскәү-Казан мөнәсәбәтләрен без бары тик шундый позициядән бәяләргә хаклыбыз.

3. Югалтулар күбрәк, әлбәттә. Аларның күпчелеген мин хәлиткеч, фаҗигале югалтулар, дип атар идем. Иң мөһим югалту — дәүләтчелек традициясенең өзелүе. Дәүләте булган, дәүләт тоткан халык өчен дәүләт бетерелү аның тарихында коточкыч зур фаҗига һәм тискәре якка борылыш. Моңа кадәр үз дәүләтендә төп роль уйнаган татарлар хәзер яңа сәяси вазгыять шартларында буйсындырылган хәлдә яши башлыйлар, икенче планга күчәләр. Халыкның сәяси «кәефе», үзүзен тотышы тамырдан үзгәрә.

Казан ханлыгы бетерелгәннән соң, татар халкы үзенең шәһәр структурасын югалта. Татарның сәяси, икътисади, мәдәни тормышында шәһәр нинди зур урын алып торганы аңлашыладыр. Телисеңме-теләмисеңме, шәһәр, нигездә, халыкны оештырырлык, берләштерерлек бер үзәк булып тора. Ә татар халкы, Казан ханлыгы руслар тарафыннан яулап алынганнан соң, бары тик авыл халкы гына булып кала, татарлар шәһәрләрдән, зур елга буйларыннан, зур юллардан куылалар. Авылның халыкны берләштерү өчен мөмкинлекләре чикләнгән. Кызганычка каршы, без бүгенге көнгә кадәр милли рухлы татар шәһәр структурасын торгыза алмадык. Бүгенге көнгә кадәр, шәһәр белән авыл арасында тигез, ихтирамлы, ике якка да файда китергән мөнәсәбәт юк.

Тагын бер хәлиткеч югалтуны атап узасым килә. Дәүләтчелеген югалтканнан соң, безнең халык тора-бара үзенең иң белемле, иң оешкан, матди мөмкинлекләре булган, халыкның сәяси, икътисади, мәдәни үсешен үз кулында нык тоткан җирбиләүчеләр, феодаллар катлавын югалта. Шуңа күрә халкыбыз XVI-XVIII йөзләрдә тормышның күп кенә өлкәләрендә тирән кризис кичерә. Мисал өчен шунысын да искә төшерәм: XIX гасыр — XX йөз башында татарларда яңадан югары сыйныф, кулларында финанс мөмкинлекләрен туплаган катлау пәйда булгач, татар халкы, аның мәдәнияте нинди казанышларга ирешә бит! Югары катлау формалашуы моңа этәргеч фактор булып тора. Бүген дә без милли үзаңнары булган, дөньяда үз урыннарын төгәл аңлаган бай татарларга мохтаҗлык сизәбез. Бай татарлар бар, ләкин алар чын мәгънәдә татармы? Тарих безгә бу очракта яңадан гыйбрәт була ала.

Александр Геннадьевич БАХТИН,
тарих фәннәре докторы, Мари дәүләт университетының Ватан тарихы кафедрасы профессоры (Йошкар-Ола)

1. XVI гасырның икенче яртысында Мәскәү патшалыгының Казан һәм башка төрки-татар ханлыкларын җиңүе икътисади, хәрби һәм сәяси сәбәпләр белән аңлатыла.

Хәрби каршылыкта хәрби-икътисади потенциал шактый мөһим роль уйнаган. Бу яктан Мәскәү дәүләте җитди өстенлеккә ия була. Ханлыкта 500-600 мең халык яшәгән, ул 60 меңгә кадәр сугышчы бирә алган. Россиянең халкы 5 миллионнан алып 7 миллионга кадәр булган, хәрби көчләре 200 меңгә җиткән, матди ресурслары да зур булган. Хан армиясенең исә структурасы искергән, ул азсанлы хан гвардиясенә кушылган феодал отрядларыннан һәм игенчеләр ополчениесеннән торган. Бер кеше боеруына нигезләнгән рус гаскәреннән аермалы буларак, хан турыдан-туры гаскәр белән идарә итмәгән, бу эшне хәрби җитәкчеләр аркылы башкарган, алар исә һәрвакытта да югары командованиегә буйсынмаганнар. Татар отрядлары еш кына гомуми стратегия кысаларында мөстәкыйль хәрәкәт иткәннәр. Һөҗүмнәр ясаганда, бу алым сугыш хәрәкәтләре барган мәйданда тиз һәм зыян күрмичә хәрәкәт итәргә мөмкинлек биргән, ә саклану сугышларында һәм зур бәрелешләрдә бердәм хәрәкәт итүгә кыенлыклар тудырган. Казанлыларның бик шәп атлы гаскәре, гасырлар дәвамында камилләшкән, ләкин рус дворян ополчениесе татарлардагы коралларның, сугыш киемнәренең һәм тактикаларының иң яхшы мөмкинлекләрен күптән үзләштерә. Хәтта «Бояр малаен татарлар белән сугышырга өйрәтмә» («Не учи сына боярского с татарами биться»), дигән әйтем дә бар. Русларның җәяүле гаскәре сан ягыннан һәм сыйфат ягыннан өстен булуы, рус елга флотының да көче ап-ачык күренеп торган. Әле XV гасырда татар елга флоты күпмедер дәрәҗәдә каршы торырга омтылса, соңрак татарлар су өстендә сугышлардан баш тарткаччан. «Казан елъязмачысы» 1552

елны Казан астында татар һәм мари флотлары турында болай дип язган: «не брежахуся — не умеют бо с русью на воде битися». Шул сәбәпле, казанлылар елгаларны — табигый су каршылыкларын файдалана алмаганнар, шул ук вакытта руслар уңышлы рәвештә елгалар буенча гаскәрләренә ярдәм ташыганнар, елгалар буенча ханлыкның чикләрен япканнар.

Ике якның да салкын сугыш кораллары, гомумән алганда, заманы өчен алдынгы булган, ләкин русларның утлы корал өлкәсендә күзгә бәрелеп торган өстенлекләре күзәтелә. Казанда туплар җитештерү һәм аны куллану дәрәҗәсе турындагы дискуссиягә кермичә, ышанып әйтергә мөмкин: ханлыкта утлы корал аз санда булып, аны куллану дәрәҗәсе тиешле югарылыктан ерак торган. Ханнар күп тапкырлар Кырымнан туплар җибәрүне сорап мөрәҗәгать иткәннәр, артиллерия фәкать Казанны саклаганда гына кулланылган, аны башка бәрелешләрдә файдалану очраклары билгеле түгел. Татарлар утлы коралны тиешенчә бәяләп бетермәгәннәр. Киң кулланылыштагы ук-җәя беренче вакытта камил булмаган пищальләрдән һәм туплардан күпкә өстен саналган. Утлы корал катлаулы һәм озак корылган, юеш көнне аны гомумән куллану мөмкин булмаган, ләкин ул еракка ату, туры тидерү һәм күп кешене һәлак итү көче белән аерылып торган. Әйтик, Мәскәү яклы нугай кенәзе Исмәгыйльгә ярдәмгә бары тик 50 стрелец җибәрү нугайлар арасындагы үзара сугышны аның файдасына хәл иткән дә куйган. Инженерлык өлкәсендә руслар Европа һәм үзләренең казанышларын файдаланганнар (гуляй-город (вагенбург), җир астын казып, дивар шартлату ысулы, тараслар һәм туралар).

Рус дипломатиясе татарларны җиңеп чыга, аларның союзларын тарката, дошманнары арасыннан үзенә яраннар җыйный. Казан өчен барган сугышта татарларга бары тик азсанлы нугайлар һәм Болын ягы марилары гына ярдәмгә килә. Шул ук вакытта руслар ягында меңләгән татар, мордва, чуваш һәм Тау ягы марилары сугыша. Казанлылар арасында эчке бердәмлек булмый. Чит мәмләкәтләренең мәнфәгатьләре чәкәләшү һәм эчке каршылыклар илне нык көчсезләндерә. Бердәмлек булмау, төрки-татарларның үзара килешә алмаулары көчәеп килгән Россиягә җиңелүнең төп сәбәпләре булып тора.

Татар яугирләре русларга караганда сугыш алымнарын әйбәтрәк белгән. Казанны яклап, алар кыю һәм бик чая сугышканнар. Руслар өчен Казанны буйсындыру Алтын Урда белән сугышны дәвам итү кебек кабул ителгән, бөтен халык эше һәм тынгысыз күршедән котылу дип аңлатылган. Бу рус-казан мөнәсәбәтләренә фаҗигалелек төсмере өстәгән.

2. Күптөрле фантазияләргә бай публицистик һәм фәнгә катнашы булмаган әдәбиятны исәпкә алмаган очракта, Казан ханлыгының оешу вакыты, ул оешуның дәвамлылык мәсьәләсе һәм Казанны яулап алу буенча галимнәр арасында фикерләр төрлелеге яшәп килүен әйтергә кирәк. Кайбер тарихи шәхесләр, мәсәлән, Шаһгалине сатлыкҗан дип бәяләү хакыйкатькә туры килми. Шаһгали —тугрылыклы хезмәт иткән рус патшасы белән үзенең халкы, татар дөньясы арасында бәргәләнүче трагик шәхес. Ул читләр арасында үз кеше, үз кешеләр арасында чит булган.

Инде йөз ел буе Казан ханлыгы тәхетенә соңгы варисның исеме төгәлләштерелә. М.Г.Худяковның

«җиңел кулы» белән аның исеме тарихи әдәбиятка «Али-Әкрам» — нугай кенәзе улы һәм Сөембикәнең ир туганы буларак кереп китте. Чынлыкта елъязмаларда аның исеме «Ахполбей» дип атала. Али исә, Чыңгызый булмаган һәм марилар тарафыннан үтерелгән Ахполбейга караганда берничә ел озаграк яшәгән. Күп тиражлар белән басылган әдәбияттагы хаталардан котылу бик кыен шул.

3. Идел буен кушуның беренче нәтиҗәләре җирле халыклар өчен дә, руслар өчен дә уңай булмау ачык күренеп тора. Татарлар үзләренең дәүләтчелекләрен югалталар, аларның мәдәниятләренә, икътисадына көчле һөҗүм ясала. Бик күп кеше үтерелә яки илдән читкә чыгарыла. Руслар да зур югалтуларга дучар булалар һәм Көнчыгышта яулап алган җирләрне саклап калу, үзләренә кушу өчен гаҗәеп зур күләмдә матди һәм хәрби ресурслар куллануга мәҗбүр ителәләр. XVI гасырның икенче яртысында биредә халык баш күтәрүләре, восстаниеләр гел булып тора.

Гасыр ахырында гына бу кушуның уңай яклары тоемлана башлый. Күп гасырлар дәвам иткән үзара сугышлар һәм чит дәүләтләрнең һөҗүмнәре туктый.

Тынычлык урнашу икътисад үсешенә, халык саны артуга уңай йогынты ясый. Руслар Россиядә өстенлекле халык булмаганнар, дәүләт сыйнфый-дини (православие) нигездә төзелгән, бу исә татарларга һәм башка халыкларга яңа шартларга яраклашырга, ә православие динен кабул иткән очракта, Россия җәмгыятендә хәтта шактый югары дәрәҗәгә ирешергә мөмкинлек тудыра.

Казан ханлыгын һәм аның күршеләренең башка альтернативасы булмаган. Әгәр дә Иван IV Казанны яулап алмаган булса, бу эш аның тәхет дәвамчылары тарафыннан башкарылган булыр иде. Татарлар үзара киртәләр аркасында Мәскәүгә каршы берләшә алмаганнар, ә Көнчыгыш Европада Мәскәүгә каршы торырлык башка көч булмаган.

Татарлар һәм руслар — үзара мөнәсәбәтләрен бик озак ачыклаган — талашкан һәм хезмәттәшлек иткән, сугышкан һәм туганлашкан ике күрше. Алар, ахыр чиктә, киләчәктә озак вакытлар бергә бер илдә яшәячәкләрен һәм бөтен мәсьәләләрне тыныч юл белән, яхшы күршеләрчә — туганнарча хәл итәргә кирәклеген аңлаганнар.

Илья Владимирович ЗАЙЦЕВ,
тарих фәннәре докторы, Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының әйдәп баручы гыйльми хезмәткәре (Мәскәү)

1. Төп сәбәп дип татар тарихы фәне классиклары Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Һади Атласи, Газиз Гобәйдуллин да билгеләгән факторны — Казан элитасы эчендә бердәмлек булмауны атар идем. Нәкъ менә партияләргә һәм төркемнәргә таркалу ханлыкның егылуына китерә. Шулай ук башка — Мәскәүнең объектив икътисади һәм хәрби өстенлеге кебек сәбәпләр дә булган.

2. Минем фикеремчә, төп миф — ике як арасында кискен дошмани мөнәсәбәтләр, Казан ханлыгының су-

гышка атлыгып торуы хакындагысы. Нәтиҗә буларак, төрекләр ягыннан сугыш белән янаулар һәм Мәскәү-Госманлы дәүләтләре арасындагы көндәшлек турындагы миф. Соңгы миф акрынлык белән, ләкин бары-бер историографиядән югала бара. Ике дәүләт арасындагы каршылык берсенең генә сугышка хирыслыгы белән беркайчан да аңлатыла алмаса да, беренчесе чиктән тыш яшәүчән булып чыкты.

3. Милли дәүләтчелекне югалту кебек катлаулы хәл эчендә уңай моментларны аерып чыгару бик авыр. Ләкин, әгәр хыялга бирелсәк һәм бер мизгелгә генә Казан ханлыгының бәйсезлеге XVIII гасыр ахырына (Казах ханлыгы шикелле) яки XIX гасыр уртасына кадәр (Урта Азия ханлыклары кебек) яшәгән, ә Иделнең түбән агымы бу вакытта руслар кулында булган дип уйласак, һичшиксез, бу чакта Казан тулысынча Россия империясеннән һәм ислам дөньясыннан, Европа илләреннән бүленеп, киселеп калган булыр иде. Мондый мәдәни ялгызлыкның барлык тискәре нәтиҗәләрен күз алдына китерүе дә авыр. Мәскәүнең яулап алуы Казанны катлаулы империя организмына урнаштыра, ләкин ислам Шәрыгыннан да, христиан Көнбатышыннан да аермый (соңгысына хәтта якынайта да). Татарлар өчен икенче «уңай» һәм руслар өчен «тискәре» момент — Чыңгызыйлар мирасына мөнәсәбәт. Чыңгызыйларның идарә камыты 1550 еллардан Россия проблемасына әйләнә, ә татарлар империя төзелешендә катнашучы милләт булудан котыла һәм шуның белән бәйле күпсанлы төрледән-төрле гаепләүләрдән азат була.

Рәшит Габделфәрт улы ГАЛЛӘМОВ,
тарих фәннәре кандидаты,
Татарстан Фәннәр академиясе
Ш.Мәрҗани исемендәге
Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре

1. Төрле сәяси фиркаләргә, төркемнәргә бүленеп беткән Казан бәкләре-мирзалары турыдан-туры тышкы агрессия куркынычы алдында да үзләрендә ахыргача берләшерлек көч таба алмыйлар. Бу бары тик соңгы этапта гына, 1552 елда Явыз Иванның күпсанлы явы инде Казан диварларына якынаеп, вакыйгалар трагик төсмер ала башлагач кына күзәтелә. Монда инде, дәүләт язмышының «кыл өстендә калганлыгын» аңлап, Казан җиренең бар халкы «бер йодырык булып» туплана. Моны илне, динне яклап, елъязмаларда, бәетләрдә чагылган сугышчан бергәлек, батырлык, каһарманлык үрнәкләре күрсәтә. Әмма инде соң була... Бу уңайдан «яшен яшьнәмичә, мужик чукынмас», дигән рус халык мәкале искә төшә. Безнең бүгенге вазгыятебез дә шундыйрак.

Эчке ыгы-зыгылар күпчелек очракта хан тәхете өчен көрәш белән бәйле була. Татар ханлыкларында исә тәхеткә Чыңгыз нәселеннән булган һәр кеше дәгъва кыла ала. Мондыйлар татар мәмләкәтләрендә дә, рус дәүләтендә дә күп була. Шул сәбәпле дә, Казан тәхете күрше-күлән дәүләтләргә Урта Иделдә үз йогын-

тыларын үстерү өчен уен коралына әйләнә.

Казан ханлыгын көчсезләндерүче факторларның берсе булып хәрби демократиягә корылган, Алтын Урда заманыннан калган Яса кануннарының шәригать кануннарына каршы килүен дә билгеләп үтәргә мөмкиндер. Чөнки Казан аксөякләрен боларның беренчеләрен үтәргә элеккедән килгән гореф-гадәтләр, икенчеләрен Ислам дине мәҗбүр иткән.

Тактик хаталарга Рус дәүләтенә Казанга якын гына бер урында Зөя (Свияжск) кальгасын кору мөмкинлеген бирүне кертергә кирәк дип саныйм.

2. Мәгълүм булганча, XVI гасырның беренче яртысында Казан-Мәскәү мөнәсәбәтләре үзара килешү, татулык чорларын да, киеренкелек, сугыш дәверләрен дә кичерә. Казан ханлыгын яулап алу вакыйгасы исә тарихи әдәбиятта төрлечә бәя алды. XVIII-XX йөз башы рус тарихчылары, империячел вазгыятьтән чыгып, кагыйдә буларак, аны рәсми, тантаналы рухта, «прогрессив күренеш» кебек бәяләде. Совет чорында исә бу тарихи вакыйга башта «абсолют явызлык» («абсолютное зло»), аннары «кечкенә явызлык» («меньшее зло»), ә соңыннан янә «прогрессив күренеш» итеп бәяләнә башлады. Турыдан-туры әйтелмәсә дә, әлеге тенденция Ватан тарихы буенча Россия мәгариф министрлыгы, югары уку йортлары, фәнни институтлар әзерләп чыгарган хәзерге уку-укыту әсбапларында да чагыла. Элек-электән, «Әби патша заманнарыннан» ук килгән империячел традицияләр буенча, 1552 елда Казанны, көчсезләнгән Казан ханлыгын яулап алуның Рус дәүләте өчен саклану характерында булуы турында ялган тезис алга сөрелә. Аны аклау, Казан ханлыгын агрессив, баскын, «кыргый» бер дәүләт итеп күрсәтү өчен, махсус тарихи монографияләр дә бастырыла.

Шунысы кызык, үз заманында XVI гасыр Рус дәүләте өчен иң әһәмиятле дәүләткүләм вакыйга булып, күп буын тарихчыларның, урта гасыр рус елъязмаларының игътибар үзәгендә торса да, Ватан тарихы буенча бүгенге дәреслекләрнең күбесе Казан ханлыгын, башка татар ханлыкларын яулап алуга бәйле «вак-төяк тарихка» әллә ни зур игътибар бирми. Нигездә, бу турыда искә алынып кына үтелә. Бик тәфсилләп язылуына караганда, 1558 елда Көнбатышта немец рыцарьларына каршы алып барылган, асылда нәтиҗәсез тәмамланган Ливон сугышы бик тә әһәмиятле икән?! Шул рәвешле, Ватан тарихында урта гасыр рус-татар, Мәскәү-Казан, Мәскәү белән башка татар ханлыкларының мөнәсәбәтләре, аларның тарихи әһәмияте кимсетелә, юкка чыгарыла. Моны Ватан тарихын яңабаштан реставрацияләү, аннан татар тарихын ясалма рәвештә сызып ташлау дип бәяләргә була.

Еш кына Казан ханлыгын басып алуның Идел буе халыклары өчен прогрессив күренеш булуы Рус дәүләтенең соңгылары өчен икътисад, матди, рухи культура өлкәләрендә миссионерлык, мәгърифәтчелек роле белән аңлатылырга тырышыла. Әмма ул вакытта Казан ханлыгы үзенең икътисади, сәяси-иҗтимагый үсеш дәрәҗәсе буенча Мәскәү дәүләтеннән калышмаган. Ә һәр халыкның рухи культурасы үзенә күрә бөек һәм кабатланмас.

3. Үз дәүләтчелегеңне, ирегеңне югалту — ул һәр халык өчен дә трагедия. Урта гасыр чыганагында: «Казан алынганнан соң, татарлар каралып калды», — диелә. Ягъни, мәчет-мәдрәсәләр җимерелү, матди-ру-

хи байлыклар туздырылу, юк ителү, укымышлы, затлы кешеләрнең кимүе сәбәпле, бу дәвердә халкыбыз «каралыбрак» кала — милли тарихыбызда «караңгы чор» башлана. Гасырлар дәвамында халкыбыз милли-сыйнфый, дини изүгә дучар булып яшәде. Православие диненә көчләп чукындыру сәясәте нәтиҗәсендә татарларның аерым бер төркеме — керәшен татарлары барлыкка килде.

Ләкин Казан ханлыгын яулап алып, Мәскәү дәүләте, рус халкы үзе нигә иреште соң? Тар аралыкта карагaнда, Мәскәү өчен аның отышлы яклары күз алдында кебек. Беренчедән, элеккеге Мәскәү кенәзлеге, чын мәгънәсендә, патшалыкка («царство») әйләнеп, күпмилләтле Рус дәүләте оеша башлый, аның халыкара дәрәҗәсе үсә. Җирләре дә бермә-бер артып, ул сәүдә-икътисад өчен әһәмиятле Урта, Түбән Идел буена ия була.

Әмма шуны да онытмаска кирәк: Казан ханлыгын яулап алу — ул бүгенге Россиядәге берсеннән-берсе катлаулы милли, дини җирлектәге проблемаларның юл башы да. Алар мирас булып Россия империясеннән Советлар Берлегенә, ә аннан исә хәзерге Россиягә күчте. Хәзерге вакытта бу мәсьәләләрнең ни дәрәҗәдә катлаулылыгын барыбыз да беләбез.

Сергей Павлович САНАЧИН,
шәһәр төзүче архитектор (Казан)

1. Төп сәбәпләр:

1) Мәскәү дәүләте җиңүгә һәрьяклап һәм ныклап әзерләнә, ә Казан — «һәрвакыттагыча». Зөя кирмәнен төзергә мөмкинлек бирү гаҗәеп зур хәрби гамьсезлек (ваемсызлык) була.

2) Элеккеге таркау рус кенәзлекләре бер дәүләткә берләшәләр, ә татар йортларының (Кырым, Казан, Хаҗитархан, Нугай) уйланылган бердәм мөселман йортына туплануы барып чыкмый.

3) Мәскәү бик көчле хәрби державага әверелә. Казан үзенә күрә автономия сыман кала. Моны, бер яктан, Госманлы дәүләтенә үзен аның йорты дип тануны сорап мөрәҗәгать итүе, икенче яктан, 1552-1553 елларда Казанны саклаучыларның чагыштырмача азсанлы булулары күрсәтә.

4) Бер генә татар йорты да Казанга туганнарча ярдәм кулы сузмый, Дәүләтгәрәй ханның 1552 елны Тула астындагы пируэты куркаклык була. Хаҗитарханлылар һәм нугайлар ярдәмне бөтен йортлары белән күрсәтми, ә аерым отрядлар гына җибәрә. Кырым йортында сәяси фикер йомшак була, моны Дәүләтгәрәйнең Мәскәүне соңга калып, 1571 елда гына алуы дәлилләп тора.

5) Татар йортларының көчле опекуны — Госманлы дәүләте Мәскәү-Казан сугышына катнашмый. Хәтта, Кырым йортына күп мәртәбәләр ярдәм иткән кебек, туплар, җайдаклар һәм пищальләр дә җибәрми. Моңа акыллы Мәскәү дипломатиясе һәм һөҗүм өчен Төркиянең үзе хәрби эшләре белән мәшгуль булган вакытны сайлау да йогынты ясый.

6) Казан йорты ике дошмани төркемгә — Мәскәү яклы һәм Кырым яклыларга бүленгән була. Ханнарны алыштырулар гел кабатланып тора.

7) Казанның үз хан династиясе юк. Күрәсең, ачык күренеп торган

хәрби лидер да булмаган. XVI гасырда мондый әйдәманнарны яллап чакыралар. Әйтик, Сафагәрәй 1545 елны Мәскәүне түгел, Казанны алырга омтыла, икенче талпыныштан, 1546 елны үз теләгенә ирешә дә.

8) Татарларның 1552 елгы Ватан сугышларын күпмедер дәрәҗәдә гражданнар һәм Ватан сугышы дип атарга мөмкин. Бу хакта Мәскәү гаскәрләре ягында Касыйм, Городец татарларының, ханлыкның Тау ягы кешеләренең сугышуы сөйли.

2. 1) Әгәр дә XVI йөз вакыйгаларына, гомумән, Казан-Мәскәү һәм хәтта Русь һәм Урда мөнәсәбәтләренә тирән кермәсәң, бу гасырда Казан җирләренең Мәскәү йорты булганын, аның тәхетенә Мәскәү патшалары үзләренә охшаган ханнарны утыртуларын әйтергә кирәк. Казанның суверенлыгы булмауны 1524 елны Сәхибгәрәйнең Казан җирләрен Госманлы солтаны Сөләйман йорты дип атавы һәм бу сәяси адымга җөрьәт итүе Мәскәү протекторатыннан чыгуын дәлилләп тора.

2) 1552-1553 елларда Казанны камау, саклау һәм алу реконструкциясе тарихи чынбарлыкка туры килми.

3) Куелган беренче сорауга каршы килә торган фикерләр. Гомумән, «ханлык» терминын Казан йортына карата куллану бик үк дөрес түгел. Ханнарны чакырганнар, сайлаганнар, XVI гасырда алар еш кына марионетка булган.

4) Иң төп миф — халыкларның күршеләре белән сугышуы объектив мәҗбүрият булган дип уйлау. Безнең очракта сугышлар рус һәм татар халыклары өчен түгел, ә дөньяви һәм рухани хакимиятләр, бу халыкларның элиталары өчен кирәк булган.

3. Россия өчен төп табыш булып дөнья аренасында сәяси һәм хәрби авторитеты үсү һәм Тын океанга кадәр сузылган яңа җирләргә хуҗа булу тора. Мәскәүнең Казан белән еш кабатланган һәм инде ияләнелгән сугышлары белән чагыштырсак, 1552 елгы сугышның көтелмәгән һәм һәлакәтле тәмамлануы, күпсанлы югалтулар һәм монда русларның гаепле булулары аерым кешеләрдә гаеп хисе уята.

Татарлар өчен иң зур югалту дәүләтчелекләре юкка чыгу була. Аларның табышлары турында сөйләүне әхлаксызлык дип саныйм. Һәм дөрес тә түгел, чөнки без, 1552-1553 еллар вакыйгасы булмаса, бу халыкларның үсеш юллары ничек буласы хакында белә алмыйбыз.

Бүген күпчелек руслар һәм татарлар дустанә яшиләр. Ике яктан да аерырга теләүчеләрнең тырышуларына, кайбер дөньяви һәм дини лидерларның бу хакта мактануларына карамастан, бу дуслык генетик дәрәҗәдә күзәтелә.

Ләкин русларның 460 еллык «гаепләре» һәм татарларның «яралары» әле бик озак үзен сиздереп торачак. 1550 елгы геополитик халәткә кире кайтырга руслар да, татарлар да теләмиләр дип уйлыйм. Руслар тарафыннан гафу үтенү бу гаепне һәм яраны киметергә мөмкин. Ул татарлар сайлаган урында Россия хакимияте тарафыннан 1552-1553 елларда Казанны саклап һәлак булганнар өчен һәйкәл кую инициативасы белән чыгу һәм аны төзүдә чагылыш таба алыр иде.

Илдус Заһидуллин *әзерләде.*

ОНЫТЫЛГАН ИСЕМНӘР

ГАБДЕРӘШИТ ФӘХРЕДДИНОВНЫҢ «РУСИЯ ТАРИХЫ» ДӘРЕСЛЕГЕ (1919)

Габдерәшит Фәхреддинов мәшһүр дин галиме, тарихчы Ризаэддин Фәхреддин гаиләсендә өченче бала булып 1892 елның 22 гыйнварында Уфа каласында дөньяга килә. Бу шәхеснең тормыш юлы турында без сеңлесе Әсма Шәрәф һәм аның улы Арыслан хатирәләреннән генә белә алабыз. Ул Р.Фәхреддиннең барлык балалары кебек үк дөньяви гыйлем алган, тәрбияле, гыйлемле шәхес булган. Габдерәшит башта «Хөсәения» мәдрәсәсендә, аннары Оренбург реальное училищесында һәм Пермь университетының физика-математика факультетында гыйлем ала. Төрле курсларда, рабфакта, авыл хуҗалыгы техникумында математика укыта. Озак еллар Уфа авиация техникумында эшли. Габдерәшит Фәхреддиннең төгәл һәм табигать фәннәре буенча төрле дәреслекләр язуы мәгълүм. Галим 1953 елда йөрәк өянәгеннән вафат була [1].

Әтисе Ризаэддин Фәхреддинов һәм ир туганнары кебек үк Габдерәшит Фәхреддинов та тарих фәненә битараф булмаган. Аның алтыеллык ибтидаи мәктәпләренең югары сыйныфлары өчен төзелгән «Русия тарихы» дәреслеге (1919) игътибарга лаек. Бу дәреслек Русия мөселман укытучыларының икенче гомуми съезды секциясендә кабул ителгән «Русиядәгә мөселман төрек-татар халкы өчен алты еллык ибтидаи мәктәп



Габдерәшит Фәхреддинов (1892-1953)

программасы» (1917) нигезендә язылган. Әмма Г.Фәхреддинов программаны таркау ясалган дип саный һәм, кайбер пунктлары башлангыч мәктәп өчен туры килмәгәнгә, аннан берникадәр читләшергә дә мәҗбүр була.

Мәгълүм булганча, тарих фәне татар мәктәп-мәдрәсәләрендә иң мөһим предметларның берсен тәшкил итеп, ул милли үзаң тәрбияләү коралы булган. Шәкертләр бу фәннең ислам тарихы, пәйгамбәрләр тарихы, гомуми тарих, Русия тарихы һәм төрки-татар тарихы кебек тармакларын үзләштергәннәр. Г.Фәхреддин: «Ибтидаи мәктәпләрдә тарих укытуда

максат — халыкның иң борынгы замандагы тормышыннан, кешеләрнең бер-берсенә булган мөнәсәбәтләрен хәзергегә караганда күп садә [гади], простой булган заманнан алып, шул мөнәсәбәтләрнең акрын-акрын катлауланучын күрсәтү һәм шул юл белән хәзерге мөнәсәбәтләрне аңлатудыр», — дип яза [2]. Шул сәбәпле автор китапта халыкның яшәү ысулларына, шартларына һәм иҗтимагый тормышларына зур урын бирә, тормыш катлаулануның сәбәпләрен аңлата, вакыйгаларны үсеш-үзгәрештә һәм берберсенә мөнәсәбәттә тикшерә.

Г.Фәхреддинов ибтидаи мәктәпләрдә «Русия тарихы» фәнен укыту методикасына да туктала. Аның фикеренчә, бу фәннең тарих нәрсә икәнлеге аңлатылгач, ягъни «Тарихы мөкаддимә»дән соң укытылуы шарт. «Биреләчәк дәрес сыйныфта ук аңлатылырга тиеш. Мөгаллим бу дәресне үзе сөйләп бирсә, сөйләгәндә сөаль-җавап тарикы [юлы] илә тәкрар итәргә [кабатларга] тиеш. Моңа ярты сабак вакыты үтеп, калган яртысында шәкертләрдән үткәндә укылган дәресләр соралыр. Һәрбер фасыл үтелгәч, бөтен фасылга кыска гына конспект төзелер. Моны әүвәл сыйныфта мөгаллим шәкертләр белән бергә тәртип кылып, соңыннан шәкертләрнең үзләренә генә тапшыру мөмкин. Тәкрарлаган вакытта китапны икенче мәртәбә башыннан аяк әүвәлге тәртибендә укып чыгу кирәкми, ә бәлки аерым-аерым мәсьәләләрнең үзгәрешен, тәрәккыйсен, тарихын тәкрарларга кирәк. Мондый мәсьәләләрне җиңелдән авырга тәртип белән төзеп, дәрес саен бер я ике мәсьәләне бирергә мөмкин» [3]. Г.Фәхреддинов дәресләрнең эчтәлеге баерак булсын һәм укучылар теманы яхшы хәтерләрендә калдырсыннар, аңласыннар өчен, күрсәтмә әсбаплардан һәм рәсемнәрдән файдаланырга өнди. Әмма үзе: «Укыган мәгълүмат мөмкин кадәр күренешле булсын өчен, китапларга күбрәк рәсем кую тиешлеген белсәк тә, хәзерге кыйммәтчелектә бу эшне булдыру мөмкин булмаганга күрә, бу фикердән дүнеп торырга мәҗбүр булынды», — дип яза [4]. Галим шулай ук төрле экскурсияләргә — тарихи биналар янына, курган казылган җирләргә, музейларга баруның кирәклеген ассызыклый.

Күрүебезчә, Габдерәшид Фәхреддинов, нигездә, төгәл фәннәр буенча мөгаллим булса да, тарих дәреслеге төзү принципларын һәм аны предмет буларак укыту методикасын да яхшы белгән.

Дәреслекнең эчтәлегенә килгәндә, аның «Русия мәмләкәтенең төзелә башлавы», «Киев дәвере», «Суздаль дәвере. Рус җиренең удельләргә бүленүе. Татарларның һөҗүме», «Рус җирләренең бергә җыелуы. Русларның татарлар хакимиятеннән чыгулары», «Дүртенче Иван», «Башбаштаклык дәвере», «Беренче Романовлар заманында рус җиренең әхвәле», «Бөек Русия дәвере. Пётр заманы», «Икенче Екатерина — Әби патша заманы», «Бе-


عبدالرشيد فخرالدينف.

روسيه تاريخى

آلتى يللق ابتدائى مكتبلرنك صوڭغى صنفى اوچون ترتيب ايتلمش.

КАЗАНЬ.
Лито-Типография Т-за „УМИД"
1919 г.

Фәхреддинов Г. Русия тарихы. – Казань: Лито-Тип. Т-ва «Умид», 1919. – 92 б.

ренче Александр заманы», «Төркстан, Кавказ явы һәм Балкан славяннары өчен сугышу», «Икенче Александрның исляхате [реформалары]», «Идарәи мотлаканның [абсолют] соңгы дәвере» кебек бүлекләре бар. Һәр бүлек вак бүлекчәләргә бүленгән. Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган бүлектә Г.Фәхреддинов Явыз Иван заманындагы Рус дәүләтенең эчке һәм тышкы сәясәтен тасвирлый. Автор укучыларга Иванның явызлыгы сәбәпләрен һәм нәтиҗәләрен күрсәтергә тели һәм моны яшьтән үк ата-ана, тәрбиячеләр һәм тирәлек биргән тәрбиягә бәйләп аңлата.

Искәрмәләр

1. Шараф Арслан. Сведения о детях Ризаэтдина Фахретдинова // Ризаэтдин Фәхретдин: Фәнни-биографик җыентык = Ризаэтдин Фахретдинов: Научно-биографический сборник. — Казан: «Рухият» нәшрияты, 1999. — Б.190.
2. Фәхреддинов Г. Русия тарихы. — Казан: Лито-Тип. Т-ва «Умид», 1919. — Б.2.
3. Шунда ук. — Б.3-4.
4. Шунда ук. — Б.4.

[...]

ДҮРТЕНЧЕ ИВАН

ДҮРТЕНЧЕ ИВАННЫҢ ЯШЬЛЕГЕ

Әтисе үлгән чакта, дүртенче Иванга бары өч кенә яшь булган. Угылы урынына мәмләкәтне анасы идарә иткән. Ләкин биш елдан соң Иванның анасы да үлгән. Идарә боярлар кулына күчкән. Идарәне үз кулларына алу өчен, зур боярлар бер-берсе белән тартыша башлаганнар. Боярлар арасында бер-берсен хурлау, яманлау, кычкырышу, хәтта кара-каршы йодрыклар белән сугышулар да булган. Бу эшләрнең барысы да 8-9 яшьлек Иван алдында булган. Боярлар Иванның үзен дә җәберләгәннәр, аны хурлаганнар. Иванның яшьлеге менә шундый талаш, сугыш эчендә үткән. Аның тәрбиясе хакында һич кайгыручы булмаган. Аны яхшылап укытмаганнар. Иванның бала уеннарында мәче балаларын биек тәрәзәдән ташлау, хайваннарны кыйнау шикелле бик начар уеннар булган. Ул шундый уеннардан кәеф тапкан. Үсә төшкәч, кешеләрне дә шулай җәберли башлаган. Җыелган халык арасына аю җибәрү, өйдәшләре белән атка утырып, урам тулы халык өстенә чабып, халыкны таптату шикелле начар эшләр эшләп күңелен ачкан. Боярлар Иванны яхшылыкка бер дә өйрәтмәгәннәр. Аның мондый эшләрен күреп: «Менә бу падишаһ батыр булыр, менә бу беркемнән дә курыкмас!» — дип, Иванның начарлыгына каршы бармыйча, аңа юл куйганнар.

Явыз Иван патша. С.Герберштейнның «Записки о Московитских делах» китабыннан

Иван бик зирәк бала булган: укырга бик тиз өйрәнгән, бик күп китап укыган, бу заманда дини китаплар гына булганга, Иванның да укыган китаплары гел дини генә булган. Ул бик тиз хәтеренә алучан булган. Укыган китапларының күбесен хәтердән белгән.

Иванга яхшы тәрбия бирүче булмаганга, һәрнәрсәне аның теләгәненчә эшләп, аның падишаһ буласын, падишаһка бар эш тә ярый, ул гади кеше түгел, ул үзенең халкын теләсә ни эшләтә ала, җанын аласы килсә, җанын ала, малын аласы килсә, малын алырга иреге бар, бу ирекне аңа Ходай биргән, дип юмалап, бозып бетергәннәр. Иван мондый тәрбиянең нәтиҗәсендә үзен-үзе тыя алмый торган усал кеше булып чыккан, ачуланса, чиктән тыш ачуланып, ачуын китергән кешене үтермичә туктамаган. Соңыннан эшләгән эшенә үкенеп, гөнаһын бетерер өчен, маңгаен шештергәнче идәнгә бәреп гыйбадәт кыла торган булган.

ДҮРТЕНЧЕ ИВАННЫҢ ТӘХЕТКӘ УТЫРУЫ

Унҗиде яше тулгач, дүртенче Иван тәхеткә утыра, падишаһ исеме белән таҗ кия. Ләкин тәхеткә утырса да, мәмләкәт эшләрен һич карамый: мәмләкәт эшләре һаман боярлар кулында кала. Иван өйләнгәч тә, үзенең яшь вакытындагы тәүфыйксызлыгын ташламый, боярлар халыкны кысалар, халык актык түземлеге белән мондый эшләргә чыдап тора. Бервакыт Мәскүдә ут чыга, шәһәр бөтенләй диярлек янып бетә [1]. Халык ачлангыч кала. Падишаһ та, боярлар да халыкның хәлен җиңеләйтергә тырышмыйлар. Халык арасында шәһәргә боярлар ут төрткән дигән хәбәрләр тарала башлый. Соңрак халык күтәрелеп, урамга чыгып, идарә башында торган боярларны тотып үтерә, йортларын талый, Иван бу вакыт шәһәрдә булмый. Ләкин халыктан ифрат курка, бу вакытка кадәр үзеннән көчле кеше бар дип белмәгән Иванга халыкның болай күтәрелеп чыгуы бик нык тәэсир итә. Ул үзенең Мәскәү янындагы авылыннан чыкмый ята.

Сильвестр исемле бер поп килеп, Иванны үгетли, яхшылыкка өнди, халыкның читен хәлдә калуын сөйли, халыкка ярдәм итәргә кирәклеген аңлата. Шомлы Иван соңгы вакыйгаларның барысын да үзенең начарлыгы өчен Ходай тарафыннан җибәрелгән җәза дип исәпләп тәүбә кыла, Мәскәү мәйданнарының берсендә җыелган халык алдына килеп, әүвәлге юньсезлеге өчен халыктан гафу үтенә.

Падишаһ янына Сильвестрдан башка нәселе югары саналмаган Адашев исемле тагын бер кеше кушылып, бергәләшеп халыкны тынычландырырга, мәмләкәт эченә тәртип кертергә керешәләр. Сильвестр Иванны тәмам куркытып, үзенә караткангa, Иван бу ике кешенең киңәшеннән башка бернәрсә дә эшләми. Сильвестр белән Адашев, мәмләкәттә тынычлык булсын өчен халык вәкилләрен җыеп, аларның ихтыяҗын белергә тиеш табалар. Бу корылтайның тикшергән иң мөһим мәсьәләләре идарә белән суд эшләре була.

Ул чакта идарә итү өчен падишаһ волостьларга наместниклар дип аталган түрәләр тәгаен иткән. Бу түрәләр халыктан налог җыйганда, күп җыеп, хәзинәгә тиеш кадәрдән артканын үз кесәләренә сала барганнар, хөкем вакытында ришвәт алып, күп ришвәт биргән кешеләрне һәрвакыт аклаганнар. Угры һәм качакларны тотмаганнар, тотсалар да, ришвәт алып коткарганнар. Беренче корылтай фикере буенча, волость халкына үз теләве белән түрә итеп үз арасыннан берәр кеше сайлап куярга имкян [мөмкинлек] биргән. Ләкин бу хак белән файдалану өчен, хәзинәгә махсус налог түләргә тиеш булган. Падишаһ куйган түрә дөрес хөкем итсен өчен, төрле җинаятьләргә җәза тәгаенләгәннәр. Түрәнең шул канун буенча хәрәкәт итүен карап тору өчен, волость халкы бер старшина сайлап куйган. Мөһим җинаять эшләрен йөртү өчен, бөтен өяз берләшеп, үзенә

аерым бер старшина сайлап куя алган.

Шулай итеп, бу законнарда эчке идарәдә байтак мәсьәлә халыкның сайлап куйган вәкилләренә тапшырыла. Бу законнарның байтак урыннары әүвәлге вечеләрне искә төшерә. Бу законнар гамәлгә куела башлагач, падишаһ һәм аның куйган түрәләренең башбаштаклыгы беткәч, халык тынычланган, иркенрәк сулыш алган.

КАЗАН ҺӘМ ӘСТЕРХАННЫҢ РУСЛАР ТАРАФЫННАН АЛЫНУЫ

Эчке эшләр бер тәртипкә куелгач, тыштагы дошманнар белән көрешү дә русларга җиңелләшкән. Руслар бу дәвердә Казан белән Әстерханны алганнар.

Казан ягындагы җирләр туграк, икмәклерәк булганга, рус халкы акрынлап бу якка күчә башлаган. Бу игенчеләр өстенә Дүртенче Иван заманында Мәскәүдә тыныч көн күрә алмаганга, аннан бик күп сәүдәгәрләр дә килгән. Болар белән Казан татарлары арасында бик еш кына вак сугышлар булгалап торган. Бу вак сугышлар соңыннан зур оеп, Казан өстенә бик күп рус гаскәре килеп, Казанны уратып алганнар. Бик озак сугышканнан соң, стенасын дары белән күтәртеп, руслар шәһәргә кереп сугышканнар, татарларның түрәләреннән бәгъзеләре русларга сатылганга күрә, Казан шәһәре ахырда руслар кулына төшкән (1552 ел).

Бу вакыйгадан дүрт ел соң Иделнең Каспий диңгезенә койган җирендә әүвәлге Алтын Урда урынына таэсис кылынган [нигезләнгән] Әстерхан ханлыгы да руслар кулына кергән. Шулай итеп, Идел нәһере [елгасы] бөтенләй рус елгасына әйләнгән. Волга буена рус мөһаҗирләре килә башлаган, ләкин монда тормыш куркыныч булганга күрә, бу җирләргә русларның иң гайрәтлеләре генә күчә алган.

РУСЛАР БЕЛӘН КЫРЫМ ТАТАРЛАРЫ АРАСЫНДАГЫ МӨНӘСӘБӘТ

Кара диңгез буенда күчеп йөргән татарларның күбесе Кырым ярым атасында [ярымутравында] торып, мәркәз идарәләре шунда булганга, аларга кырым татарлары исеме бирелгән. Кырымлылар русларга һәр җәй һөҗүм итеп, талап, әсирләр алып торган булганнар. Кырымлылар һөҗүменнән рус җирләренең җәнүб ягы [көньягы] зарарланган. Кырымлылар, җыелып, чокырлар, үзәннәр буенча биек үләнгә ышыкланып, йөзәр чакырымга кадәр рус җиренә кергәннәр, соңрак кинәттән күтәрелеп, артларында калган русларга һөҗүм итеп, талап-үтереп китә торган булганнар. Алган әсирләрен Төркиягә илтеп коллыкка сатканнар.

Кырымлылардан саклану өчен, руслар, үр казып, Кырым чигенә нygытылган калалар салып, анда гаскәри халыкны урнаштыра башлаганнар. Татарларның килү хәбәре ишетелү белән, аларга каршы чыгару өчен, һәр җәйне Ука [Ока] елгасы буена гаскәр җыеп, көзгә кадәр гаскәрне шунда тота башлаганнар. Көз көне бу гаскәрне тарата торган булганнар, чөнки татарлар җәен генә русларга һөҗүм иткәннәр.

ОПРИЧНИКЛАР

Иван янында Адашев һәм Сильвестр торган чакта, әүвәлге боярларның кадерләре кими башлаган: аларны падишаһ янына бик якын җибәрмәгәннәр, зур дәрәҗәле түрәләрне, гаскәр башлыгын халык үзе сайлап куя башлаган. Халык үзенә, әлбәттә, яхшы кешеләрне сайлап, аның нәселенең олуг булуына игътибар итмәгән. Шулай итеп, бөтен көчне үз кулларында тоткан әүвәлге боярлар бөтенләй эштән чыгарыла башлаганнар. Бу, әлбәттә, аларның кәефенә ошамаган, шуның өчен алар ничек булса да, Адашев белән Сильвестрны

патша яныннан тайдыру чараларына керешәләр.

Бервакыт Иван бик нык чирләгән. Бераз һушына килгәч, васыять яздырып, тәхетен кечкенә угылына тапшырачагын әйтеп, боярларны чакыртып, угылына ант итәргә кушкан. Боярлар арасында тавыш купкан, бәгъзеләре кечкенә вәли гаһед өчен идарә итәчәк боярлардан көнләшеп, ант итмәскә булганнар. Шомлы Иванга бу вакыйга бик нык тәэсир иткән, һәммә боярлар Иванның үлгәнен генә көтеп торалар, соңра хөкүмәт башына менәр өчен берберсе белән көрәшергә хәзерләнәләр икән дигән фикер Иванның башына урынлашып, күңеленнән боярларга аның ачуы кабарган. Шул чакта Иван тирәсендә йөргән руханилар һәм боярлар Адашев белән Сильвестрдан риза булмыйча, алар өстеннән юк-бар нәрсәләр белән әләкли башлаганнар. «Падишаһ булгач, мөстәкыйль хәрәкәт итә башларга кирәк, һәммә нәрсәгә үзең хуҗа булып, үзең әмер биреп торырга кирәк!» — дигәли башлаганнар. Шул сүзләргә бирелеп, Иван Адашев белән Сильвестрны янынннан китәргә мәҗбүр иткән. Моның өстенә хатыны даулаган. Шуннан соң Иванны яхшы якка күндерүче кеше калмый, ул әүвәлгечә үзен мактап торган боярларны гына үзенә якын китерә. Алар исә Иванны котыртып, намуслы боярларны аның алдында яманлап, Иванның бөтен ачуын әүвәлге ярдәмчеләренә, халык тарафдарларына каршы юнәлдерәләр. Иван иң элек Адашев белән Сильвестрның дусларына бәреләә: аларны асып-кисеп бетергәч, халык тарафыннан игътибар казанган боярларны үтертеп бетерә. Аларның бөтен малын, җирен алып, аларны үзенә «тугрылык» белән хезмәт итүче яшь дворяннарга бирә. Бу хезмәткәрләр, падишаһның башка хезмәткәрләреннән аерым саналып, аларның иң мөхкәм [төгәл] вазифалары, падишаһның шәхесен саклау һәм аның мөстәкыйль хаким икәнен халыкка күрсәтү була. Боларга бирелгән җирләр, шәһәрләр дә башка боярларга бирелә торган җирләрдән аерым саналган, бу җирләргә опричнина [2] дигәннәр. Бу җирләр һәм шәһәрләрнең хуҗаларын опричник, дип атаганнар.

Иван ифрат шомлы вә шикчелгә әйләнеп, һәр кеше дә аңа каршы, бар кеше дә аңа дошман кебек тоелган. Үзен саклаучы бердәнбер хезмәткәрләр итеп шул опричникларны таныган. Шуның өчен ул бары опричникларга гына ышана, алар өсләреннән шикаять белән килгән кешеләрнең берсен дә кабул итми. Опричниклар теләсәләр ни эшләп, халыкны талап, җәфалап бетергәннәр. Падишаһка ярау өчен, боярлар өстеннән шикаять итеп, аларны Иванга каршы халыкны хәрәкәткә котыртуда гаепләп, төрмәгә ябып, газаплап, ахырдан Иван алдына китереп үтергәннәр, Иван моңа кәефләнеп карап торган. Опричниклар тотып япкан халык белән бөтен төрмәләр тулган. Ул вакыт төрмәгә ябылудан җиңел нәрсә булмаган: опричник урамда берәр кеше белән сүз ача да соңыннан: «Менә бу кеше падишаһка тел тидерде», — дип, һич әйтмәгән сүзен әйтте, дип, үзен тотып төрмәгә алып китә яисә, сәүдәгәр кибетенә килеп, үзе берәр нәрсә ташлап калдыра да, соңрак иптәшләре белән килеп, тентү ясап, ташлап калдырган нәрсәсен табып, бу эштә хуҗасын гаепли, малын үзләренә ала, хуҗасын төрмәгә илтеп яба. Падишаһка я аның тирәсенә җыелган боярларга охшамаган башка кешеләрне һәм боярларны да шулай ук тоталар иде.

Бу опричниклар үзләренә махсус бер кыяфәттә йөргәннәр: өсләрендә кара кафтан булып, һәрвакыт кара атка атланып, иярләренә эт башы белән себерке бәйләп йөргәннәр [3]. Опричникларны күрү белән, халыкның кайсыкая качып-посып кала торган булган. Иван шәһәр урамыннан үткән чакта, урамдагы бөтен халык качып, урамнар тып-тын булып кала торган бул-

ган. Бу опричниклар, Мәскәүдә генә түгел, башка авылларга, шәһәрләргә дә барып, халыкны кырып, себереп йөргәннәр. Аларның эшләмәгән явызлыклары калмаган. Алар менә шундый юл белән Дүртенче Иван падишаһка итагать итәргә тиешлеген халыкка өйрәтә башлаганнар.

Иван Грозныйның бу җәзаларыннан боярлар гына түгел, бөтен рус җире зәгыйфьләнгән. Авыллар таланган, халык качкан, калганнары нинди кәсепкә керешергә белмәгәннәр. Иванга начарлыкларын тугры сөйләп торган бер кеше булса, ул да митрополит Филипп булган. Иван бу руханига тияргә башта бераз каушап торса да, соңыннан Филиппны да, ертык монах киемнәренә киендереп, бер монастырьга бикләп куйган. Ахырдан Иванның кушуы белән аны да буып үтергәннәр. Иванның бу эшенә каршы, түгел башка сыйныфтан, хәтта руханилардан да бер сүз әйтүче табылмаган, чөнки алар арасында да падишаһның эшләрен хуплап торучылар күп булган.

Мәскәү кенәзләренең берсе дә Новгород белән Псковка тимичә калмыйлар иде. Чөнки Новгород белән Псков халкы вечегә өйрәнгән, хөр торуның кадерен белә. Мәскәү кенәзләре кулында исә әүвәлге тәртипне бигрәк тә сагына иде. Мәскәү кенәзләренең барысы да Новгород белән Псковтан шикләнәләр, бу җирләрнең көчен мөмкин кадәр бетерергә, халкын яңадан аякка баса алмас хәлгә китерергә, әүвәлге хөрриятләрен оныттырырга тырышалар иде. Иван Грозный да дахили [эчке] сәясәттә ата-бабасы эзеннән бара, бервакытны атасы һәм бабасы, гаскәр җыеп, Новгород һәм Псков шәһәренә барган кебек, Иван Грозный да, опричникларын һәм дворяннарын җыеп, Новгород ягына юнәлә. Иван Грозный бу сәфәрендә шундый ерткычлыклар кылган ки, рус җире төзелә башлаганнан бирле мондый ерткычлыкларны күргәне булмаган — кергән бер калада халкын кыру, суга батыру, талау, асу, кисү, малларын яндырып бетерү, өйләрен яндыру кеби вәхшәтнең берсе дә калмаган. Бәгъзе урыннарда халык опричниклар килүен ишетү белән, бөтен мал-җиһазын ташлап, сазлыклар, урманнарга качарга тотынганнар. Иван, Новгородка барып җиткәнче, 6-7 каланы туздырып бетергән. Иван Новгородта халыкны өч атна буенча җәзалаган, асып, кисеп, газаплап үтереп, суга ташлап, малларын талап, туздырып, Псковка киткән. Псков халкы һәммәсе дә үлемгә хәзерләнеп, Иванны бик түбәнчелек белән каршы алганнар. Иванның моңа кәефе килгән, Псковка тими, Мәскәүгә кайтып киткән.

Иван Грозныйны бәгъзе вакыт намусы тотып, җаны кыйналган чаклары да булган. Ул хәтта үзенең бер сараен монастырьга әйләндереп, өч йөз опричникны монахлар киеменә киендереп, таңнан торып Ходага гыйбадәт кыла, маңгае күгәреп чыкканчы сәҗдә кыла торган булган. Гыйбадәт кылып беткәч, көндез Иван яңадан төрмәгә барып, ябылган кешеләрне газапларга керешә, икенче көн яңадан гыйбадәткә бирелә икән.

Бу җәзалар Иван Грозныйның соңгы елларында гына бетә. Соңрак ул авырып үлә. Иван Грозный идарәсенең ахырларында рус җире бик тәртипсезләнгән, урта рус җирләрендә торуы читен булганлыктан, халык Дон буена, Идел буена күчә башлаган. Болар алпавытлар кысуыннан, дворян һәм опричниклар кыруыннан качып килгән халык булган. Монда крестьян да, сәүдәгәр дә булган. Болар яңа җиргә килгәч, вак-вак авыллар булып утырганнар. Бу качып килгән халык казачий дип аталган. Казачий сүзе үзе төрекчә [төркичә] качкын, качак сүзеннән булган сүздер. Казачийлар сунарчылык белән тора башлаганнар. Бәгъзеләре бергә җыелып, Иделдә йөргән рус сәүдәгәрләренең көймәләренә һөҗүм итеп талаганнар.

Иван Грозный гаскәрләре бу казачийларны тарата алсалар да, алар, яңадан җыелып, икенче урында талап йөриләр иде. Казачийларның бер өлеше сәүдәгәрләрнең кәрваннарын талап көн күрә иде. Иван Грозный заманының ахырында шундый казачийлар шайкасының берсе Себер ханлыгын забыт итте [яулап алды].

Себернең алынуы. Кама елгасы буендагы җирләр Иван Грозный тарафыннан Строганов фамилияле сәүдәгәрләргә бирелгән иде. Алар бу җирдән күбрәк файдалану өчен, монда халыкның күчүенә ярдәм иттеләр, урман яндырып, ашлык чәчәргә басулар хәзерләп, күчеп килгән кешеләргә урынлашырга җиһаз да биргәннәр иде. Монда тоз күп чыкканга, тоз чыгарырга да эшчеләр күп кирәк була иде. Гомумән, монда килгән кешегә урын да, эш тә күп иде. Тормыш җиңел булса да, монда тынычлык булмаганга күрә, килүчеләр ул кадәр күп булмый иде. Монда искедән бирле торган фин халыкларының үз җирләрен бер дә тавышсыз гына русларга бирәселәре килми иде. Шуның өчен күчеп килгән русларга финнар тарафыннан һөҗүм итүләр еш була иде. Урал тауларының аръягында торган татарлар да, русларга һөҗүм итеп, аларны тараталар иде. Бу җирләрдән күбрәк файдалану өчен, монда кеше күчерергә, кеше күчсен өчен, бу җирдә тынычлык урнаштырырга кирәклеген Строгановлар яхшы төшенеп, үзләренә гаскәр төзи башлаганнар. Төрле урыннарда вак калалар салып, гаскәриләрне шунда урнаштырганнар. Шулай итеп, тирә-якка бераз тынычлык китерсәләр дә, татарлар һөҗүменнән саклану өчен, аларны боярлардан ераграк куарга тиеш табылган. Строгановлар, шуның өчен үзләренә башка урыннардан да гаскәр чакыра башлаганнар. Үз кешеләрен Идел буенча кәрван талап йөрүче казачийларга җибәреп, аларны да чакырганнар. Казачийлар арасыннан Ермак исемле бер атаман үзенең шайкасы белән Строгановларга хезмәткә килгән. Монда аны якында гына татарларга каршы чыгарганнар. Ул аларны җиңеп, кырып бетергәч, күбрәк гаскәр белән Урал тауларының аръягындагы Себер шәһәрен алырга җибәргәннәр. Көймәләргә төялеп, 850 кеше белән ашамлык алып, туп-мылтыклар белән Урал тауларының аръягына юнәлгән. Урал тауларын җәяү үтеп, Себер ягына чыккач, тагын көймәләргә утырып киткәннәр. Соңра Себер ханының гаскәренә очраганнар. Болар арасында сугыш башланган, руслар мылтыктан ата башлаганнар. Татарлар мылтыкны беренче мәртәбә күргәнгә, мылтыктан бик курыкканнар, күп сугышып тормыйча качканнар. Соңра Себер халыклары берәм-берәм Ермакка бирелә башлаганнар. Ләкин Ермакның үз гаскәре дә ахырдан азаеп калган. Бер урында Мәскәү падишаһыннан ярдәм килгәнне көтеп ятканда, үзенә татарлар һөҗүм итеп, казачийларны куганнар, шул чакта качып, Иртыш елгасы аркылы йөзеп чыгып барганда, Ермак суга батып үлгән.

Ермак Себернең кечкенә бер өлешен рус падишаһлыгына кушкан. Себернең башка өлешләре башка заманда, бик озак вакыт эчендә, азлап-азлап рус җиренә кушылып беткән. [...]

Искәрмәләр

1. Бу пожарда янып үлүче олуг кешеләрнең генә саны 1700дән артык булган, бала-чаганың хисабы да мәгълүм түгел.
2. Оприч — бөтен, аерым, үзенә башка
3. Эт башы — падишаһның дошманнары эт кебек; себерке — аларны себереп түгәргә ишарә имеш!

Чыганак

Фәхреддинов Г. Русия тарихы: алтыеллык ибтидаи мәктәпләрнең соңгы сыйныфы өчен тәртип ителде. — Казан: Лито-тип. Т-ва «Умид», 1919. — Б.38-46.

Кереш мәкаләне һәм текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.*

2012 ЕЛ — ТАРИХИ-МӘДӘНИ ҺӘЙКӘЛЛӘРНЕ САКЛАУ ЕЛЫ

ХӘТӘР КИТӘ – ХӘТЕР КАЛА...

1552 ЕЛНЫ КАЗАННЫ ЯУЛАП АЛГАНДА ҺӘЛАК БУЛУЧЫЛАРГА ГЫЙБАДӘТХАНӘ-ҺӘЙКӘЛ (ХРАМ-ПАМЯТНИК ВОИНАМ, ПАВШИМ ПРИ ВЗЯТИИ КАЗАНИ В 1552 Г. (ХРАМ-ПАМЯТНИК В ЧЕСТЬ НЕРУКОТВОРЁННОГО ОБРАЗА СПАСИТЕЛЯ)) КАЗАНСУ ЕЛГАСЫНЫҢ УҢ ЯК КУЛТЫГЫНДА, АДМИРАЛТЕЙСТВО БИСТӘСЕННӘН ЕРАК ТҮГЕЛ УРНАШКАН. БУ УРЫНГА КАЗАННЫ ЯУЛАГАНДА ҺӘЛАК БУЛГАН РУС ЯУГИРЛӘРЕ ҺӘМ ХӘРБИ ҖИТӘКЧЕЛӘР ҖИРЛӘНГӘН. БЕРЕНЧЕ ВАКЫТТА МОНДА ГАПГАДИ КӘШӘНӘ [ЧАСОВНЯ] ГЕНӘ ТӨЗЕЛГӘН БУЛГАН, ВАКЫТЫ-ВАКЫТЫ БЕЛӘН ЕЛАНТАУ МОНАСТЫРЕ (ЗИЛАНТОВ СВЯТО-УСПЕНСКИЙ МОНАСТЫРЬ) РУХАНИЛАРЫ ТАРАФЫННАН МӘРӘСИМ ҮТКӘРЕЛГӘН.

Һәйкәлнең дүрт ягына «В память победы над татарами в 1552 г.» дип язылган

Әлеге корылманы төзү эше Елантау монастыре башлыгы, архимандрит Амвросийның 1812 елда Казан халкына һәйкәл өчен акча җыйнау турындагы мөрәҗәгатеннән башлана. Башта һәйкәл гади бер таш багана булыр диеп күзаллана. Әмма император Александр Павлович проектны үзгәртергә куша һәм бу эшне Н.Ф.Алфёровка тапшыра. Архитектор һәйкәл проектында 1803-1814 елларда Мисырда һәм Грециядә күргән тәэсирләрен чагылдыра. Шунлыктан ул пирамида стилендә коллоналар белән төзелгән.

Һәйкәл төзү өчен империя күләмендә хәйрия кампаниясе үткәрелә. Һәйкәл халыктан җыелган, шәхсән император Александр I һәм дәүләт бүлеп биргән акчага төзелә.

Һәйкәл 1823 елның 30 августында тантаналы рәвештә ачыла. Архимандрит Амвросий вафатыннан соң, һәйкәл хуҗасыз кала һәм ташландык тора. 1832 елда төзекләндерелә. Башта һәйкәл Елантау монастыре карамагында була, ә 1830 елдан аны карапсаклап тору эшенә Казан сәүдәгәрләре алына, XIX гасырның икенче яртысында — XX гасыр башында бу хезмәт Казан шәһәре думасы хисабына башкарыла.

Пирамиданың үзәгенә Спас Нерукотворённый исемендәге кечкенә чиркәү «яшерелә». Аның стеналарына патша Иван IV һәм император Николай II портретлары эленә. (XX йөз башында соңгысын Александр I портреты алыштыра). Һәйкәлнең дүрт ягына да «В память победы над татарами в 1552 г.», дип языла.

1830-1832 елдагы реконструкция вакытында кеше сөякләре «никадәр тирән казыйсың, шуның кадәр күп чыккан». Подвалдагы склепның уртасындагы зур табутка баш сөякләре тутырылган булган. Ул лампадалар белән яктыртылган. Император Николай Павлович 1836 елны 1552 елда һәлак булганнарны хөрмәтләү йөзеннән бирегә килгәч, Елантау мо-

настыре җитәкчесе архимандрит Гавриилдан: «Монда кемнәр күмелгән?» һәм «Моның кадәр күп (сөяк) арасына татарларның җәсәдләре эләгергә мөмкин түгелме?» — дип сорый. Рухани руслар белән татарларның сөякләре кушылу мөмкин түгеллеге, җирләгәндә, тышкы билгеләре, киемнәренә карап аерылганлыклары турында әйтә.

Һәйкәл ел саен Иделдә һәм Казансуда язгы ташулар вакытында утрауда кала торган булган, ә 1888, 1926 елларда аны су баскан. 1956 елда



Куйбышев сусаклагычы һәм Жигули ГЭСе төзелү сәбәпле, Казансуның ярлары киңәя, һәйкәл ел дәвамында утрауда кала.

1918 елдан һәйкәл гыйбадәтханә вазифасын башкарудан туктый. Узган гасырның 50 нче елларында архитектор А.Г.Бикчәнтәев җитәкчелегендә бинага реставрация ясала, һәйкәлдәге чиркәүне хәтерләткән әйберләр, тәре алына, язулар күмелә.

2002 елда Казанны яулап алуның 450 еллыгы уңаеннан, панихида оештырыла. 2004 елда һәйкәлне Адмиралтейство (Киров) дамбасы белән тоташтыручы күпер-дамба ясалды. 2005 елда тарихи бина Рус Православия чиркәвенә тапшырыла, биредә төзекләндерү эшләре башкарылды. Һәйкәл-гыйбадәтханә 2011 елда Кизик ирләр монастыре карамагына бирелде.

Бу һәйкәлнең рус руханиларына кайтарылуы һәм төзекләндерелүе — Татарстан Республкасында берьяктан тарихи-мәдәни истәлекләрне саклау буенча кайгыртучанлык булса, икенче яктан толерантлык мөнәсәбәтләрен



чагылдырган күркәм үрнәкләрнең берсе булып тора. Әйе, тарих, хәтер яулап алганнарны да, яулап алынганнарны да онытырга тиеш түгел...
Инде менә ничәнче ел (1992 елдан!!!) татар җәмәгатьчелеге Хәтер көнендә Казанны яулап алганда шәһит киткән татар яугирләренә һәйкәл куеласы урынга чәчәкләр сала. Киләчәктә ул һәйкәлнең һичшиксез булачагына өмет итә...

Абдулла Дубин һәм
Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Әдәбият:

1. Загидуллин И. Празднование в России покорения Казани во второй половине XVI — начале XX в. // Казанское ханство: актуальные проблемы исследования. Материалы научного семинара «Казанское ханство: актуальные проблемы исследования». 5 февраля 2002 г. — Казань: Изд-во «Фән», 2002. — С.4-71.
2. Гавриил, архимандрит. Слово на день взятия Казани царём Иоанном Васильевичем Грозным и на освящение храма, сооруженного в памятнике над могилою православных воинов, за веру и отечество при взятии Казани живот свой положивших. — Казань: Универ. тип-я, 1833.
3. Никанор, архиепископ (Каменский). Казанский сборник. — Казань: Типо-литография ун-та, 1909.
4. Спутник по Казани: Иллюстрированный указатель достопримечательностей и справочная книжка города / Под. ред. Н.П.Загоскина. — Казань: Лито-тип. ун-та, 1895.
5. Гавриил, архимандрит. Историческое описание памятника, сооружённого в воспоминание убиенных при взятии Казани воинов на Зилантовой горе. — Казань: Универ.тип., 1833.
6. Баженов Н. Плавание к Зилантову монастырю и Казанскому памятнику. — М.: Универ. тип., 1846.

Л.Гобәйдуллин фотосы



СӘНГАТЬ

Иҗат итү татлы җимеш түгел,
Катмарланып беткән нык тамыр.

Мөдәррис Әгъләмов

«КАЗАН КЫЙССАСЫ»

РОЗАЛИНА ШАҺИЕВА,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

СӘНГАТЬ ТАРИХЫНДА ГАҖӘЕП ФАКТЛАР БАР... КАЙБЕР ТЫНГЫСЫЗ ИҖАТ ӘҺЕЛЛӘРЕ, БҮГЕНГЕ КӨН КЫСАЛАРЫН ҖИМЕРЕП, БИЛГЕСЕЗЛЕККӘ, ФАНТАЗИЯ КИҢЛЕКЛӘРЕНӘ – ТӘМУГ, ҖӘННӘТ, УЗГАН ГОМЕР, ҖИР АСТЫ, ОКЕАН ТӨБЕ, ХӘТТА «ТЕГЕ ДӨНЬЯ МӘХШӘРЕ»НӘ УРГЫЛЫП, ЮГАЛУГА ДУЧАР БУЛГАН СӘНГАТЬ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕН, ШӘҺӘРЛӘР, ГАСЫРЛАРНЫ, ЦИВИЛИЗАЦИЯЛӘРНЕ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫНА КАЙТАРАЛАР. ГОМӘРНЕҢ «ИЛИАДА»СЫ, ДАНТЕНЫҢ «ИЛАҺИЛЫК КОМЕДИЯСЕ», ШЛИМАННЫҢ «ТРОЯ»СЫ ШУНДЫЙЛАРДАН.

Нурлы Казан. 1997 ел, кин.м., 450x850

Рәссам Фиринат Халиков та әлеге символик «мәңгелеккә чумып», Казан ханлыгының югалган, соңгы чор катламнары белән капланган беренчел «портретын» алып чыкты. Борынгы Казан хәрабәләре, чит ил сәяхәтчеләре язмалары, безгә кадәр югалмыйча килеп җиткән бөек ядкәрләр исәбенә (тәхет, таҗлар, кабердашлар, савыт-саба, корал-көбә, дәүләт символлары, Мөхәммәдьяр шигырьләре) торгызылган бу шәһәрне ул дистәләгән тарихи панорамаларында, реконструкцияләрендә гәүдәләндерә. X-XII гасырларны үз эченә алган, ягъни ханлыкның оешуыннан җимерелүенә кадәрге чорны колачлаган сәнгать әсәрләре төрле модуляцияләрдә, ракурсларда, акварель, нәкыш, панноларда чагылдырыла. Гомуми караш тарих фәненең ниндидер интеграцияләнгән фикере буларак, җәмәгатьчелек тарафыннан дөреслеккә туры килә торган хак образ дип кабул ителде. Рәссам тудырган дөнья Казан тарихына бер өстәмә булды. Мисалга, күпфигуралы дивар бизәге — «Нурлы Казан» панносын алыйк. Биредә рәссам мәдәнияте, сәүдә, сәяси бәйләнешләре белән дан тоткан, яңарыш чоры кичергән Казанның җыелма образын бар тулылыгында сурәтли. Композицияләре — Суриков, Репинныкы кебек, табигый яшәеш рәвешенә якынайтылган, ә халык портреты тулаем милли үзенчәлекләргә ия.

Әйтергә кирәк, Ф.Халиков үзенең тарихи әсәрләрендә вакыйгаларны бары бер чор, кешелек җәмгыятенең үсешендә мәгълүм бер баскыч нигезендә бәяләми, ә меңьеллыклар кимәлендә үлчәнгән яңа «тарихилык», вакыт берәмлекләре белән эш итә башлады… шул ук вакытта кыюлык таләп итә торган урта гасыр низагларын, гасырлар гөрелтесен, кешелек тарихында фаҗигале эз калдырган бөек каршылыкларны сурәтләргә омтыла. Боларның берсе әле моңарчы татар сәнгатькәрләре кул тидермәгән, ялган тарихчылар тарафыннан «бөек кушылу» — «берләшү» дип бәһаләнгән Казан алыну вакыйгасы иде…

…Әле 1994-1995 елларда Киров шәһәрендә урнашкан остаханәсендә ясала башлаган, соңыннан Казанда (1997-1998) тәмамланган зур күләмле нәкыш эше — «Казан сугышы» шул темага багышланган. Киндер тукымада автор урта гасырның һәлакәтле һәм җан тетрәткеч орышларының берсе булган «Казанны алу» сугышын сурәтли. Биредә бөек шәһәр өчен барган бер айлык аянычлы орыш, һөҗүм бер сюжетка туплана: басып алучыларның Болак аша чыгуы, шәһәрне тупка тотуы, посад стеналарын җимерүе һәм моңа каршы атка атланган казанлыларның, шәһәр капкасыннан чыгып, дошманнарга кискен каршылык күрсәтүләре, көчкә-көч килү, бәрелешләр һ.б. Зур тукыма өер-өер гаскәриләр, җайдаклар, төрбәагач корылмалар, ут, шартлау-шартлату күренешләре белән тулган. Шәһәр өстен юл-юл кызгылт-соры, көйрәп торган ут кисәүләреннән чыккан төтен чолгап алган. Әлеге күренеш, шәһәрдә барган мәхшәрне тасвирлап, әсәргә куркыныч кайгы-афәт төсмере өсти. Рәссамның вакыйгаларны бербөтенгә туплап, ут белән чолганган мөселман башкаласы тирәсендә панорама итеп җәюе Казан трагедиясен фаҗигале эпос итеп сурәтләргә мөмкинлек бирә… Тәртипсез рәвештә уңнан сулга хәрәкәт иткән яугир төркемнәре, җәяүле гаскәриләр, җайдаклар, югарыдан ату өчен махсус ясалган агач «турлар» һәм «манарачыклар», һәлак булган сугышчыларның гәүдәләре, әйтерсең, ерактагы яшен уты белән яктыртылган. Казанның үлмәс мистик күренеше, рус елъязмаларында әйтелгәнчә, аның ниндидер илаһи феномен икәнлеген ка-

XVI йөздә Казан. Посад дивары корылышы, 1995 ел, кин.м., 144x123

батлый. Ә сугышны автор котылгысыз һәм мәгънәсез чара буларак сурәтли.

Менә мәскәүлеләр ату корылмаларын шәһәр капкасына якынайта, моңа җавап итеп, казанлылар сөңгеләрен тырпайта; пушка ядрәләренең бер-бер артлы Казан капкаларына ургылу мизгеле, моңа атлыларның каршы чыгуы һ.б. — болар барысы да шулкадәр сәнгатьчә камил, тормышчан, реалистик рухта башкарылган ки, әйтерсең, бер ритмда төзелгән, бертигез кисәкләрдән торган эпос... Картинаның нәфислек көче (магиясе) ирексездән Гомәр (грек шагыйре) поэмаларын хәтерләтә: андагы гүзәл гекзаметр үлчәмнәре кебек, биредә дә сәнгати куәт, төсләр гармониясе, киң эпик ритм, сугышның канлы вәхшилеген оныттырып, кайсыдыр якны җиңүче итеп түгел, күктән иңгән тарихи фаҗига корбаны буларак сурәтли. Пиротехник эффектларга бай картина, асылда, безнең ата-бабаларыбызның, бүгенге тынычлык өчен әллә нинди газаплар, канкойгыч алышлар, җәһәннәм аша үтүе турында сөйли. Бу фикер картина ракурсы белән дә куәтләнә. Анда борынгы коллизия, баталь фактлар «уйлар божрасы»на тупланган; сугыш манзарасы да бүгенге көн биеклегеннән — кош очышы югарылыгыннан алынган. Ә ерактагы какшамас Казан — әйтерсең күңел көзгесе, хыял сарае, тутыкмас асылташ... Мәңгелек шәһәр!

Шулай итеп, Ф.Халиков бу әсәрендә һәм аннан соң иҗат ителгән «Хан сараендагы соңгы минутлар» (2002), «Сөембикәнең хушлашуы»

Сөембикәнең хушлашуы, 2001 ел, кин.м., 150x250 (фрагмент)

(2001), «Шаһгали белән Явыз Иван Казан янында» (2001) һ.б. әсәрләр төркемендә, күпсанлы эскизларында, бер сүз белән әйткәндә, «Казанны алу» эпопеясында Казан ханлыгының җимерелүен, рус академистлары К.Венич, В.Худяков, Г.Угрюмовлардан аермалы буларак, Россиянең «бөек җиңүе» яисә гүзәл һәм дәгъвалы Сөембикә ханбикәнең шәхси трагедиясе итеп кенә түгел, ә дөньякүләм тарих агышында билгеле бер фаза итеп сурәтләде; көчәеп киткән Россиянең киңәюенә, Идел буе сәүдә юлларын кулга төшерүдә, Себер, Кара диңгез, Каспий, Кавказга чыгу юлларында көчле мөселман дәүләте — Казан ханлыгының зур бер киртә булуын күрсәтте. Шунысы кызык: рус елъязмаларындагы рәсемнәрдән аермалы буларак (Мәскәүнең тарих музее кулъязмаларына иллюстрацияләр, Россия дәүләт архивы документларына караган рәсемнәр; XVI-XVII гасырлар. Монда аноним авторның «Казан тарихы»н (XVI г.), А.Курбскийның «Казанны алу риваяте»н (XVI г.) дә кертергә кирәк), ул, чын мәгънәсендә, Казанның һәлакәтен халыкның физик үлеме, чукындыру, таркалу процесслары аша күрсәтүдән баш тартты. Әсәрләрендә һаман саен казанлыларның тиңдәшсез батырлыгын, сабырлыгын, кыюлыгын, тәвәккәллеген, киләчәккә өмет баглап эш итүләрен күрсәтте («Япанчы һөҗүме» — тукыма, майлы буяу, 2001; «Кол Шәриф мәчете янындагы сугыш» — кәгазь, майлы буяу, 2005). Соңгы әсәрдә рус кулъязмаларында тасвирланган баш өстенә ике кылыч чалыштырып куйган Казан сәете Кол Шәриф урынына өскә, сугышчыларның күз күреме биеклегенә изге китапны куйган иманлы сәет сурәтләнгән.

Казан өчен барган сугышларның иң ачысы, соңгысы, фаҗигалесе булган, риваятьләргә кереп калган бу

Сөембикәнең хушлашуы, 2001 ел, кин.м., 150х250 (фрагмент)

күренеш рәссам тарафыннан караңгы куе буяулар, йөгерек, йөрәк өзгеч сызымнар белән башкарылган. Мондагы йөзләр!.. Картинада, чынлап та, кырылыш, кан кою, үле гәүдәләр тулып ята... Ләкин бу фаҗига икенче планда... Беренче планда — шәкертләре тарафыннан стена кебек чолгап алынган кыю, акыллы, милләтпәрвәр сәет... Үлем һәм каза китерүчеләрне автор — соры, канэчкеч караңгы масса итеп «ачулы пумала» белән, ә казанлыларны көчәйтеп, аларның изге ярсуларын кабартып, үстереп ясый... Ул энергия, әйтерсең, җилдә дулкынланган яшел әләмнәр, изге порталлардагы алтын-көмеш бизәкләр, күккә төбәлгән мәчет манаралары аша көчәеп, дошманга каршы ургыла...

Ф.Халиков Казан фаҗигасенең аерым шәхесләренә бүтән картиналарында да кагылды. Шуларның берсе — «Шаһгали һәм Явыз Иван Казан янында» (2001). Биредә рәссам «Казан тарихы»на мөрәҗәгать итә: «Патша үзе 17 августта... Арча кырына килә, Арча капкасы каршына килеп баса... Уңкул полкларын Шаһгали кул астындагы Нугай капкасы каршына куя». Патша, Казан манзарасына карап, шәһәрнең матур стеналарын, крепостен күрә дә җилкенеп куя. Рәссам аның җир төсле күгәренгән битен (профильдән), фанатик йөзсызыкларын, Казанга төбәлгән калтыранган кул торышын сурәтли. Атка атланган патшаны уңнан сулга хәрби түрәләр, сакчылар чолгап алган, кая карама — туплар, мылтыклар, иконалар... Картинаның уң ягында — ялагай касыйм морзаларының бөгелгән гәүдәләре арасында — фронталь рәвештә — тәбәнәк кенә симез кара ат өстендә Казан тәхетен дәгъвалаучы кәкре аяклы, холыксыз, үз юлы булмаган (йөзе дә формасыз!) Шаһгали тасвирланган. Атының төсе картина гаммасы эчендә күмелгәнгә, ул Иван Грозный белән бер атка утырган сыман кабул ителә. Шулай итеп, нечкә ком-

Казан өчен сугыш, 1996 ел, кин.м., 100х300

позицион алым аша автор вәгъдәсез, имансыз, хыянәтче Шаһгалинең чын тарихи йөзен ача. Бу картинага атап эшләнгән эскизларның берсендә ерактагы җәүһәр кебек җемелдәгән Казан күренешенең төсе белән тоташкан ап-ак ат өстендә утыра... Ап-ак ефәк яллы ат. Аның артында — Казанны сурәтләгән якты метафора — корбан булган, октябрь суыгында кырау төшеп агарган Казан образы тора... Ниһаять, «Казанның соңгы ханы Ядегәрнең чигенүе» (2001 — эскиз, кәгазь, акварель) әсәрендә дә Ф.Халиков үзенең Казан кыйссасына соңгы төгәллек, тәмамланганлык, эпилог төсмерен бирергә тели. Шулай итеп, «Казан өчен сугыш»тагы («Казан сугышы») детальләп күрсәтелмәгән элементлар мөстәкыйль картиналарда, күренешләрдә чагылыш таба.

Әйе, Ф.Халиков — Казан тарихы упкыннарына беренчеләрдән булып төшүче. Борынгыны белмәсәң, киләчәкне күрәзәләп булмый, ди ул... Бөек орышны сурәтләүгә бәйле рәвештә: «Татар тарихын объектив бәһаләмәү, зур этапларын күрмәү — рәсми фәндә хөкем сөргән «болгар тарихы»на гына кайтарып калдыру — бик аяныч... Алтын Урда, Казан ханлыгы чорлары, шәхесләр, вакыйгалар, сәүдә, сәясәт, зур орышлар, үзләренең чагылышын табарга тиеш...» «Казан — мәңге үлмәс Феникс-кош, аның гел үзгәреп торган драматик тарихы, апогее — 150 еллык Казан ханлыгы чоры, ханлыкның үсеше, гүзәллеге һәм фаҗигале җимерелүе — гыйбрәтле тарихи, сәнгати материал... Мин әле башладым гына... Алда — тау кадәр эш», — ди бүген Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Сәнгать академиясенең әгъза-корреспонденты...

«Әйе, татар сәнгатькәрләре бу те-

мага керергә теләмиләр иде: ни өчен яңа баштан төпсез коеларга төшәргә? Ни өчен тарихның кайнар күмерләрен кузгатырга, яраларны яңартырга? Әгәр тирәнгә, үткәнгә карамасак, аны барламасак, без тарихсыз калабыз. Без бүгенгә кадәр тарихи риваять кисәкләре, Мөхәммәдьяр поэмалары, Сөембикә бәетләре, 8 манаралы мәчет хакындагы Мәрҗани фаразлары исәбенә яшәп килдек. Казанның бөеклеге һәм «гүзәл җимерелүе» яшәп килгән тарихи картина стандартларына туры килми иде шул. Шуңа күрә «бөек орыш хакында» да — ләммим. Казанны алуны, алда әйтеп киткәнебезчә, «оялчан» тарихчылар «воссоединение» (ирекле кушылу), диләр иде.

Ә Рим белән Карфаген арасындагы сугышлар, Англиядә 30 ел барган «ак роза белән алсу роза» сугышы, Франция белән Россия һәм, ниһаять, Беренче, Икенче Бөтендөнья сугышлары?

Һәр сугышның үз фәлсәфәсе, үз хакыйкате... Тарих ул җиңү ритмнарыннан гына тормый, аның триумфаль адымнары (кайвакыт) фаҗигале фазалары белән тоташа. Римның җимерелүе, Вавилонның, бүгенге Багдадның гөрселдәп авуы... Ләкин чигенгән чакта халык үзенең яраларын төзәтә, гүзәллек, бәхет, мәдәният, яшәеш өчен яңа энергия, көч туплый... Мин бабаларымның эчке кодын укыдым. Татар халкы — тормышка гашыйк халык, аның киләчәге ышанычлы. Шуны ясыйм...» — ди рәссам Ф.Халиков.

Бүгенге Татарстан, Казан, нәкъ шул код буенча үзенең көчен, идеалларын, бөеклеген кайтарып, ата-баба корганны истә тотып, бөек орышлары, батырлыклары алдында баш иеп, бүтән халыклар белән дустанә рәвештә, хезмәт, дуслык аша киләчәккә — тынычлыкка омтыла.

ӘДӘБИЯТ

Безнең өчен алар кауры белән
Ак кәгазьгә алтын койганнар.

Мөдәррис Әгъләмов

ГАЯЗ ИСХАКЫЙ:
«...КАРА КӨННӘРЕБЕЗНЕҢ БЕТЕП КИЛГӘНЕНӘ, КОЯШ ТУУЫНЫҢ ЯКЫНЛАШУЫНА СӨЕНӘ АЛАБЫЗ...»

КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ 1552 ЕЛДА ЯВЫЗ ИВАН ТАРАФЫННАН ЯУЛАП АЛЫНУЫН ХАЛКЫБЫЗ ХӘЗЕР ХӘТЕР КӨНЕ БУЛАРАК БИЛГЕЛӘП ҮТӘ. ШУЛ КӨН УҢАЕННАН, МИНЕМ ТАРАФТАН УКУЧЫЛАРГА ХАЛКЫБЫЗНЫҢ БӨЕК УЛЫ, ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КЛАССИГЫ, ЯЛКЫНЛЫ ПУБЛИЦИСТ, ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ «МАТӘМ КӨНЕ» МӘКАЛӘСЕ ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ. УЛ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ БӘЙСЕЗЛЕГЕН ЮГАЛТУГА 380 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕ БЕЛӘН ЯЗЫЛГАН. МӘКАЛӘ БЕРЛИНДА ГАРӘП ХӘРЕФЛӘРЕ БЕЛӘН НӘШЕР ИТЕЛГӘН «ЯҢА МИЛЛИ ЮЛ» ЖУРНАЛЫНЫҢ 1932 ЕЛГЫ ОКТЯБРЬ САНЫНДА БАСЫЛЫП ЧЫГА.

Әлбәттә, Гаяз Исхакый публицистикасында татар халкының авыр язмышына, катлаулы тарихына, бүгенгесенә һәм гүзәл киләчәгенә ышанган мәкаләязмалар бик күп. Аларның һәрберсе Г.Исхакыйга гына хас булган рухта, аһәңдә язылган.

«Матәм көне» мәкаләсендә автор тарафыннан күтәрелгән мәсьәләләр бүген дә үзенең кыйммәтен югалтмаган. Ул, тарихи фактларга таянып, Иван Грозный заманыннан алып Романовлар нәселенә кадәрге һәм аннан соң килгән социал-демократлар дәверендә татар кешесе кичергән сәяси һәм икътисади золымнар хакында сүз алып бара. Илдәге мондый авыр тормыш, яшәеш, билгесезлек, үз чиратында, халыкта ризасызлык тудырган. Изелеп яшәгән барлык халыклар бергә тупланып, шуңа каршы көрәш алып барганнар. Алар, автор билгеләвенчә, Чура Батыр, Сәед Аксакал, Степан Разин, Емельян Пугачёв кебек тарихи шәхесләр җитәкчелегендә оештырылган фетнәләрдә азатлык, ирек даулап көрәшкә күтәрелгәннәр. Шуңа да «Хәтер көне» хәтеребезне яңарту, иманыбызны ныгыту көне булсын иде.

МАТӘМ КӨНЕ

ГАЯЗ ИСХАКЫЙ

15 октябрьдә Казан алынуга, татарның истикъляляы бетерелүгә 380 ел тула. 1552 елның бу көнендә Иван Грозный гаскәре, Казан каласын ватып кереп, урамда озын сугыштан соң каланы кулга төшерә. Каладан качып чыгып, Казан елгасының аргы ягына чыгарга өлгергән берничә меңле татар егетләре дә, бик каты сугышсалар да, дошман сафын җырып чыгып, мәмләкәт эченә керә алмыйча һәлак булалар. Шуның аркасында мәмләкәт эчендә яңадан гаскәр җыяр өчен кирәк булган «оеткы» югала. Татар милләтчеләре Казанны коткарырга бердән килә алмыйлар. Ачыккан, арыган урыс гаскәре мәмләкәт эченә чыгып, талап, үзенең тамагын туйдырырга өлгерә. Татар халкы башсыз калганга, вакытында бу арыган дошманга кирәкле йозырыкны индереп өлгерә алмый. Бераз вакыт үтеп, урыс гаскәре хәл җыеп җиткәч кенә татар халкы тагын сугышка башлый. Мишә тамагында тагын кала корыла. Кирәк Себердән, кирәк нугайлыктан ярдәм булмаганга, бу батырлар да, биш еллык сугыштан соң, үзләренең соңгы терәкләре булган Мишә тамагын 1557 елда калдырып китәргә мәҗбүр булалар. Шуның берлә Казан ханлыгы бөтенләе берлә Иван кулына керә.

Кырым ханлыгы бу вакытларда шактый куәтле татар дәүләте иде. Ул Казан берлә зур мөнәсәбәттә булып, кирәк вакытта аннан ярдәм алынып торылса да, бәхетсезлеккә каршы, Кырым идарәсендә ул чакта Иван Грозныйның сүзен тыңлаучылар көчле булганга, Кырым дәүләте Казанга кирәкле булган ярдәмне вакытында бирә алмый. Кайбер батыр хан угыллары кул астында күңелле Кырым егетләре җыелып, Казанга килергә чыксалар да, алар да вакытында сугыш мәйданына килеп җитә алмыйча һәлак булалар. Ике илдә дә халык арасына таралган «Чура батыр» хикәясе генә бу егетләрнең батырлыгын бүгенгә чаклы сөйләп килә.

Иван Грозный, үзенең бу җиңүе кара көчкә таянып кына булганын белгәнгә, ул чакта мәдәнияттә Мәскәүдән өстен булган Казанны ватыра; татарның гаскәрен һәм бөтен укыган көчен үтереп бетерергә әмер чыгара. Исламны «поганный» дип атап, ул диннең һичбер хокукын танымый, аның әһелен мөмкин булган бөтен мыскыллаулар берлә мәсхәрә итәргә боера. Казан тирәсендә булган бөтен татар авылларын яндыра.

Төркия дәүләте бу вакытларда бик көчле булса да, аның олуг патшасы Сөләйман Кануни төрекчелектән бик ерак торган кеше булганга, ул Идел буеннан килгән татар илчеләренә һичбер колак салмый. Ул үзенең бозга язган планнары өчен төрек милләтенең көчен һәм вакытын әрәм итү берлә мәшгуль була һәм шуның аркасында урысларга теләгәннәрен эшләргә форсат бирә... Хәзәр диңгезенә юл ачар өчен, Иван Грозный Әстерханны да алырга хәзерләнә һәм ике елдан соң аны кулына төшерә; тагын берничә ел үтә — Идел буеның бердәнбер арка таянычы булган Себер татар ханлыкларын бозарга да муаффәкъ була [көче җитә]...

Иванның бу хәрәкәте бер кечкенә генә урыс кенәзлеген бер зур урыс империясе ясар өчен бик кирәкле эш

булса да, ул вакытка кадәр Азиянең иң зур патшалыкларын корган төрек милләте өчен бу эш бик зарарлы һәм аның киләчәге өчен бик куркыныч бер эш иде. Ләкин төрек милләтенең аерым кабиләләргә аерылган халыклары арасында, аның бер-берсенә дошман булган ханнары-солтаннары эчендә әле бу хәрәкәтнең төп мәгънәсен аңлаганнар, кирәк Төркиядә булсын, кирәк Төркестанда булсын, юк иде. Бу куркынычны аңларга, Идел буе татарының гына бу зур көчкә каршы торырга көче җитәрлек түгел иде. Читтәге төрекләрнең, бу милли куркынычны аңламыйча, Идел буен үз башына гына калдырулары аркасында, Идел буендагы үзен генә сөйгән хәмиятьсез [саксыз] мирзалар арасында урыс дустлыгы агымы туды. Алар урыс белән дус булып тору мөмкин дигән фикерне акрынлап кына шәһәрле татарлар арасына да керттеләр. Болар арасыннан урыс дәүләтенә хезмәт итүче «йомышчы»лар чыкты. Шулар арасында бер кыйсем татар укымышлылары, үзенең халкыннан аерылып, урыска якынлашты. Бу татарлар арасыннан чыккан мирзалар һәм йомышчылар, Русиянең төп идарәсенә катышып, Иван Грозныйдан соң, үзе чукынган булса да, әле татарлыгын онытып өлгермәгән Борис Годуновны Мәскәү тәхетенә дә утырта алганнар иде. Аның баласы Фёдор да «монамах бүреген» кию берлә Мәскәү кенәзлегеннән бер шәрекъ патшалыгы ясарга юллар хәзерләргә керешкән иде. Годунов гаиләсе үтерелгәч, Мәскәү илендә тагын башбаштаклык башланды.

Идел буеның чын халкы һичбервакыт урыс берлә аңлашу тарафында булмаганга, ул вакытлыча башын иярга мәҗбүр ителсә дә, күңеле берлә һаман үзенең тарихына баглы калган иде. 1605 елда Мәскәүдә башланган таҗ-тәхет гаугасыннан Идел буе да үзе өчен файдаланырга кереште. Ул Ләһстан [Польша] корольләре берлә мөнәсәбәткә керде һәм Ялган Дмитрий ягында булган булып, 1612 елны Казанны кайтарып алып, тагын бер мәртәбә үзенең истикъляллын җирләштерде.

Урыс көчләре тагын җыелып өлгерде. Кара урыслардан Михаил Романов Мәскәү кенәзе булып сайланды. Моның берлә Казанның хәле тагын авырга калды. Ныгып җитәргә өлгермәгән татар ханлыгы тагын егылды. Идел буе тагын бик каты талау һәм кысу астында калды. Бу вакытларда да әле урыс халкы бик надан булганга, Мәскәү патшалары дәүләтчелекне тәбган [ватандаш буларак] белгән татар мирзаларыннан файдаланырга һәм алардан «йомышчы»лар һәм түрәләр алырга мәҗбүрләр иде. Шуның аркасында бу кара урыс Романовлар заманында мәмләкәт эшләрендә татар мирзалары һәм татар йомышчылары көннән-көн зурая киләләр һәм көннән-көн көчәя баралар иде. Ләкин халык һаман үз фикерендә калды. Ул үзенең югалган ирегең кире кайтарыр өчен бер форсат көтеп ята иде. 1664 елда башкорт илендә Сәед Аксакал күтәрелде. Аңа бөтен Идел катышты. Шул күтәрелү берлә Русиядәге эшләр бик чуалды. Урыс казаклары аякка калыкты. Стенка Разин дигән бер атаман чыкты. Аңар да бик күп татар, мишәр катышып, Идел буеннан урысларны куу башланды. Урыс түрәләре шәһәрләрдә кала бирсәләр дә, авылларда Мәскәүнең хөкеме бетте. Казан ханлыгының терелүе җиңеләйгән кебек тоелды. Ләкин Мәскәү хөкүмәте бик күп кан түгеп һәм бик зур вәхшилекләр күрсәтеп булса да, бу күтәрелешләрне басты-

рып килде. Бу күтәрелүләрдә ханлыкны кайтару зур роль уйнап килгәнгә, Мәскәү 1708 елгы указы берлә «Казан ханлыгы» тәгъбирен бетерде. Аның туфрагы һәм халкы урыс губерналары арасында бүленде. 1694 елгы янгында Казан каласының иске татар кыйсеме тәмамән янып беткәнгә һәм аның бик күп тарихи биналары-мөәссәсәләре [оешмалары] утта югалганга, аның мәгънәви кыйблалыгы да көчсезләнде. Халык алдында ирекле көннәрне җанландыра торган хатирәләр күздән югалды.

Мәскәү һөҗүме моның берлә генә туктамады. Ул татарларның бөтен хокукларын бетерү юлына төште. Пётр үзенең 1713 елгы указы берлә татар мирзаларының мирзалык хокукларын бетерде. Чукынырга күнмәгән татар алпавытларының имтиязлары [дәүләт тарафыннан бирелгән хокук-рөхсәт кәгазьләре] берлә бергә җирләресулары да тартып алынды. Шулай ук Русия идарәсендә зур роль уйнаган татар «йомышчы»сын татарның мәгънәви тормышыннан аерып алып ташларга керește. Шуның өстенә, татарларны христианлаштырыр өчен яңа төзелгән комиссияләргә бик зур хокуклар бирде. Алар мөселманнарның мәсҗедләрен турыдан-туры ябарга керештеләр. Шул әмер буенча, 1724 елда бер Казан вилаятендә генә 418 мәсҗед ваттырылды. Мәскәүнең берсе өстенә берсе өелгән бу золымы татар халкының сабырын да ахырына кадәр җиткезгән иде. Халык каршына тагын бер форсат килеп чыкты. Идел буенда Пугачёв исемендә бер казак баш күтәрде. Бу илләрдә күпчелек безнең халык булганга, Пугачёв урыс крестьянына боярларның җирен алып бирергә, татарларга Казан ханлыгын кире кайтарырга вәгъдә итте. Татар-башкорт Пугачёвка кушылды. Урысның Идел буендагы гаскәре, бояры һәм түрәсе — бар да бетерелде. Татар-башкорт гаскәре тагын бергәләп Казанны алды. Татар халкы дәүләтен тагын кайтарды. Ләкин бу да озын гомер сөрмәде. Каты сугышлардан соң, урыс өченче мәртәбә Казанны кулына алды.

Ләкин ул вакытта Мәскәү тәхетендә утырган Екатерина, татарларны болай бер туктамый талап, җәберләп торуның ахыры урыслык өчен бик начар булып бетәчәген күз алдына китереп, татарларга карашын үзгәртте. Аның Шәрекъта уйнарга теләгән сәясәтенә, бигрәк тә Кырымны Русиягә кушу теләгенә, Идел буендагы татарларга каршы кылынган бу начар мөгамәләләр бик зур зарар итеп киләләр иде. Ул бик либераль булган булып, 1784 елда, татар мирзаларына таланып алынган җирләрен кайтармаса да, аларның дәрәҗәләрен кайтарды. Татарларның сәүдәләренә каршы куелган кайбер законнарны бетерде. Аларның шәрекъ мәмләкәтләре берлә сату итүләренә киң юллар куйды. Казанга кечкенә генә мохтариатлы бер татар шәһәр идарәсе бирде. 1788 елда ул, татарларның дине булган ислам динен бер дин итеп танып, үз имзасы берлә Казанда беренче мәсҗедне бина итәргә рөхсәт итте. «Духовный собрания» исемендә бер мөфтилек ясарга изен [рөхсәт] бирде. Екатеринаның бу сәясәте Идел буен тынычландырып бетермәсә дә һәм безнең халкыбызны үз теләгеннән ваз кичтермәсә дә, ул сәүдәгәрләр сыйныфының куәтләнүенә һәм безнең дини оешмаларыбызның ныгуына сәбәп булды. Шуның аркасында халыкның байлыгы артты. Казан шәһәре фабрик-завод күплеге ягыннан, Мәскәүдән кала, беренче урынга менде. Шуның аркасында Казанда һәм аның әйләнә-тирәсендә бик күп мәдрәсәләр салынды. 1799

елда башланган матбагачылык бик күп китапчылар мәйданга китерде. Казан Русия мөселманнары һәм аларның күршеләре өчен бер милли-дини үзәк төсен алды. Беренче Александр вакытында да Казан бу урынын югалтмады. Кара урыс Беренче Николай Казанның куәтләнүеннән һәм татар халкының баюыннан куркып, аның бер мәркәз булып китүеннән каушап, аңа каршы, сәясәт ягыннан гына түгел, хуҗалык ягыннан да бик зур кампания ачты. Казанны ярлыландырырга һәм татар халкын зәгыйфьләндерергә кирәк булган әллә никадәр тәдбирләр ясады. Икенче Александр заманында дәвам иттерелгән бу сәясәт Өченче Александр вакытында да татарларны чукындыру-урыслаштыру һәм аларның милли мәдәниятләрен бетерү юлына куелды. Мәшһүр миссионер Ильминский татарның мәдәни-мәгънәви тормышында теләгәнен эшли ала торган бер сатраб хәлен алды. Татарларны җирсезләштерү, аны пролетарлаштыру өчен, Мәскәү бөтен XIX гасыр буена кылмаган золымын калдырмады.

Бу авыр тартышта татар халкы бер милләт булу ягыннан ныгыса һәм чыныкса да, ул Мәскәүнең хөкүмәт банклары берлә тартышуда җиңелде. Аның иленә бик күп урыс мөһаҗире китерелгәнгә, бигрәк тә аның Уралдагы кыйммәтле җирләре таланып алынганга, аның мәмләкәтенең төсе үзенең этнографик берлеген саклый алмады. Мәгънәви берлекне бетерер өчен дә урыс хөкүмәте бик күп көч сарыф итеп, элгәреге кабилә аермаларын — татар, башкорт, мишәр, типтәр һ.б. — чыгарырга теләсә дә, дини һәм милли берлек хисенең куәтлелеге аны нәтиҗәсез калдырды. Киресенчә, ул, халыктагы урыска каршы дошманлыкны үстергәннән-үстереп, аны аурупача бер төскә салды.

1905 елгы урыс-япон сугышында урыс байрагының җиңелүе бөтен Идел-Уралда бер бәйрәм кебек каршы алынды. Аның артыннан күтәрелгән революция аркасында бирелгән азмаз иркенчелектән файдаланып, татар халкы тагын «үзлек» байрагын күтәрде. Ләкин бу чакта урысның үз «демократы» да патшалыкка каршы сугышып килгәнгә һәм бу киләчәк демократ дәүләттә миллият һәм дин аермасы булмаячак, дип вәгъдәләр әйтеп, кәперенеп килгәнгә, Идел буе төрек-татары да бу «үзәкне» үзенең милли-дини-мәдәни мохтариаты төсендә генә йөретте. Ул шуны булдырырга тырышты. Столыпин заманындагы реакция дәвере дә Идел-Уралның шул 5 нче елгы революциядә күтәрелгән милли-мәдәни мохтариат байрагын көчләләндерү тирәсендә үтте. Ул мәктәбен, җәмгыятен үз кулына алырга керешге. Ул авылда үз туфрагын үз кулына кертергә һәм шәһәрдәге йортны-җирне һәм бөтен сәүдәне үз ихтыярына алырга тотынды. Бу берничә ел эчендә генә табигый рәвештә дәвам итә алган бу икътисади тартышта татар халкы бик зур уңышларга иреште. Казан матбугаты, җәмгыятьләре берлә Русия мөселманнарының күбесенә мәдәни мәркәз булып өлгерде. Идел буе шәһәрләренең зурларында, кечкенәләрендә йорт-җирнең зур бер өлеше татар кулына күчте. Русиянең һәрбер шәһәрендә татар сәүдәгәре, җәтмәсен җәеп, кармагын салып, ирегә өчен кирәкле матди балыкны тотарга керешге. Татар яшьлеге бөтен мәктәпләргә тулып, гыйльми көч хәзерләргә тотынды. Татарның фикер тормышы үсеп, үзенең киләчәк идеалын билгеләргә керешге.

Татар халкы үзенең тарихында урыстан бик күп таяк ашагангамы, әллә үсеп җитеп, кабиләчелектән үтеп,

милләтчелеккә басып өлгергәнгәме, бу идеалны билгеләгәндә үзе утырган Идел буен гына күздә тотмады. Ул башка төрек өлкәләрен дә онытмады. Андагы кардәшләренең эшләрен дә үзенең эше итеп, аларның кайгысын үз кайгысы итеп йөретте. Үзенең аз көчен алар берлә дә уртаклашырга кереште. Ул шул киң төрек-татар дөньясын бер барлык итеп карап эш итте. Дөнья сугышы болай бик тиз башланып китеп, Идел-Урал егетенең җилкәсенә бу юлда бик зур йөкләр йөкләмәгән булса иде, шулай ук башка төрек кабиләләре дә «кабиләчелек» дәвереннән чыгып өлгерә алган булсалар иде, Идел-Урал төрегенең бу үзен-үзе онытып, кардәшенә ярдәмгә чабуы бик зур нәтиҗәләр тудырган булыр иде. Ләкин 1917 елгы революциянең вакытыннан иртәрәк килүе безнең бу фикер хәрәкәтебезне үсеп җитмәгән көенчә туктатты. Татар халкының бер байрак берлә барыр өчен Мәскәү һәм Казанда чакырган корылтайлары һәм бик үк рәтләнеп җитмәгән гаскәр көченең төрле төрек өлкәләренә ярдәмгә куып йөретүе дә кирәкле нәтиҗәне бирә алмады. Төрек-татар көчләре берләшә алмады. Киресенчә, Идел-Уралның үзендә меңьеллык тарихы бер барлык булып килгән халык эчендә, төрле башкорт старшиналарының старшина һәм старосталык хисләрен уятты. Ул урыс сәясиләренә кабиләләр арасындагы ярыкны киңәйтеп-зурайтып уйнарга юл ачты, большевикларга төрек-татар халкына каршы нинди юлдан хәрәкәт итәргә кирәклеген күрсәтеп бирде, безнең эчке тормышыбызның үзебездән дә яшергән урынтын юлларын дошманга белдерде. Халкыбызга каршы, берлегебезгә каршы хыянәт итте.

Татар халкы бу яхшылыкка каршы начарлык берлә, кардәшлек тойгысына каршы хыянәт берлә бирелгән җавaптан аптырап калды. Шулай булса да, ул эшеннән туктамады. Үзен-үзе туплап, көчен Идел-Урал җөмһүрияте тирәсендә җыярга кереште. Зәгыйфь булса да, Казанда бер хөкүмәт оештырылды. Аның гаскәри көче тагын илне — бөтен Идел-Уралны сакларга хәзерләнде. Мәскәү, Казанның — үзенең мәңгелек көндәше булган Казанның тагын күтәрелүен күреп, каршы чыкты. Урысның кызылыагы, берләшеп, Казанга һөҗүм итте. Милли идарәсе җимерелде. Гаскәре таратылды. Хәзинәсе таланды. Казан артыннан, нәкъ Иван Грозный вакытындагы кебек, башка төрек өлкәләре дә кызыл урыс кулына керделәр.

Казан үзенең байрагын дүртенче мәртәбә яндырырга мәҗбүр булды. Татар халкының үзлегене саклау юлында милли барлык байрагының күтәрелү-яндырылу тартышларында 380 ел вакыт үтеп китте. Тик ут, тимер берлә алынган Казан, уктан, кылычтан кичерелгән татар халкы үлмәде дә, бетмәде дә. Дөньяда һичбер халык күрмәгән золым астында яшәсә дә, ул үзенең теләгеннән чигенмәде. Ул үзен һаман үз илендә хаким итеп хис итте. Урысның бөтен мәэмүрен-түрәсен «тиле бояр» дип каравында булды. Борынгы Русия СССРга әйләнеп, борынгы кара урыс кызыл кумачка уралып, миллият бетте, без барыбыз да интернационал булдык, дисә дә, ул һаман үзендә һәм үзлегендә калды. Аның коммунист һәм комсомол булганнары да үзенә аерым милли оешмалар тудырды һәм аерым милли тормыш берлә яшәде. Аның зурлары, тагын борынгы буын кебек, бер төрек-татар коммунист фиркасе ясау уе берлә мәшгуль булды һәм СССР эчендә коммунизм нигезендә бер төрек-татар җөмһүрияте кору артыннан китте. Аның һичберсе

үзенең Русия эчендә калуын һәм үзенең яһүди кебек, җирсез-йортсыз бер милләт булып торуын күз алдына китерә алмады. Ул һаман да, безнең бабайларыбыз-әбиләребез көткән кебек үзенең байрагын, үзенең үзлек байрагын, үзенең истикъляль байрагын күтәрүнең форсатын көтә. 380 елда бабаларыбыз һәм әбиләребез көткән кебек, хәзер дә руль бу кадерле көнне көтә.

Халкына иманы аз һәм урысчылыгы күп булган кайбер милләттәшләребез: «Бу 380 елда мәйданга чыкмаган истикъляль моннан соң чыгачакмы?» — диярләр. Ләкин тарих өчен бу 380 ел бик кыска бер нәрсә. Истикъляльны югалту һәм ирексезлектә яшәү бер буын өчен бик зур бер бәла булса да, безнең кебек, бер мең ел эчендә әллә ничә мәртәбә истикъялын югалтып, әллә ничә мәртәбә дөньяның иң зур патшалыкларын кора алган бер милләткә, вакытлы килгән бәхетсезлек кенә һәм вакытлы бер хасталык кына. Ул аерым кешеләрдә булган фәкыйрьләнү я авыруга сабышып юлдан калу кебек бер нәрсә генә. Ул — көне килү берлә себереп ташлаган төсле бетәчәк, югалачак һәм онытылачак бер нәрсә.

Ләкин бу көн кайчан киләчәк? Бу истикъляль бәйрәме кайчан булачак? Объектив шартлар безгә моның мөхәкъкак [ачык] булачагын күрсәтәләр. Тик көне кайчан? Мин моны белсә идем, инде күптән багучы булган булыр идем һәм шуңа карап эшләрне корыр идем. Ләкин мин бу көннең тиз киләчәген хис итәм һәм аның тиз килүенә ышанам. «Багучылык»ка киткәндә, бик күп кешеләрне канәгатьләндерерлек нәрсәләр беләм. Мәсәлән, 1910 елда Варшавада Машков дигән бер тарих галиме «Механика врождения» исемендә урысча бер китап нәшер итә. Урыс хөкүмәте, бу китап ләһләрнең [аларның] милли тойгыларын ялкынландыра, дип китапны тараттырмый, җыеп ала. Менә бу 200 битлек зур бер гыйльми китапта бу галим тарихны да риязи [төгәл] гыйлемнәр кебек катгый нигезләргә бина ителгән, дип дәгъва итә. Ул халыкларның үсүләре-җимерелүләре барысы да билгеле кагыйдәләр берлә бара, ди. Тарихта үзенең дәгъвасына бик күп мисаллар китерә. Профессорча, халыкларның тормышындагы 400 еллык бер дәвер — тарихи бер тәүлек. Икенче 400 ел эчендә шулай ук кояш чыгачак һәм шулай ук кояш батачак. Шулай ук тарихи вакыйгалар да кабатланачак. Милләтләр дә истикъляльларын югалтачаклар һәм тагын кайтарып алачаклар. Милләтләр баеячаклар-ярлыланачаклар, галимләшәчәкләр-наданлашачаклар. Бу 400 елны ул алтын, көмеш, бакыр һәм тимер исеме берлә йөзәр еллык 4 дәвергә бүлә. Аның фикеренчә, үзенең көмеш дәверен үткәрә торган бер халык бер билгеле вакыттан соң алтын дәверенә керәчәк. Шулай ук бакыр дәверендә булган бер халык һаман төшә барып, аның хәле начарланганнан-начарлана барачак һәм ул, тимер дәверенә кереп, бөтенләй өзеләчәк.

Ләкин моның ысулында иң авыр эш — бу дәверләрнең башланган вакытын табу. Аның руман, герман, урыс һәм безнең тарихыбыздан алган мисаллары, чынлап та, бик кызыклы. Элек тә бик көчле булган Бизанс [Византия] мәдәниятен корган юнан тарихының соңгы дәверләрен алыйк. 1453 елда төрекләр Истанбулны алалар, юнан милләте истикъялын югалта. 1830 елгы фетнәләрдән соң алар бер кечкенә кенәзлек коралар. 1855 елда Севастополь сугышыннан соң алар, мөстәкыйль булып, мәйданга чыгалар. 1154 елда Чыңгыз

туа. Бу яктагы төрек-татарларның алтын дәверләре башлана. Бер зур империя барлыкка килә. 1554 (дүрт йөз елдан соң!) Идел буенда Чыңгыз ханлыгының бөтен шәһәрләре урыс кулына кереп бетә. Моның берлә Идел буе татарының тимер дәвере башлана. Хәзер бу профессорның сүзенә күрә, Русиянең алтын дәвере 1912 елда тәмам булып, ул үзенең тимер дәверенә аяк баса. Бу хәл 2012 елга кадәр дәвам итәчәк.

Машковның сүзенә караганда, шул йөз ел эчендә Русиядә менәниләр булачак (бу китапның 1910 елда чыкканын, сугышны һәм большевизмны белмәвен дә онытмаска кирәк!): 1912 елда Русиядә тимер дәвере башланачак. Ләкин бу 1917 елга кадәр хис ителерлек булмаячак. Баштарак ул укыган халыкка гына сизелерлек булып, 1927 елда бөтен халыкка тукылачак. Тормыш бик кыйбатланачак. Иң кирәкле нәрсәләр, бигрәк тә, ашауэчү әйберләре бик азаеп, дәүләтнең финансы бозылачак. Сату-алу һәм сәнәгать мөәссәсәләре ярлыланачак. Шуның нәтиҗәсендә бик зур ачлык булачак. Байларны талаулар һәм урыс булмаган милләтләр утырган өлкәләрдә баш күтәрүләр башланып, баштарак алар хөкүмәт тарафыннан бастырыла алачак. Кайбер өлкәләр дошман кулына керәчәк. 1927-1977 еллар арасында Русиянең бик күп вилаятьләре аерылачак. Халыкта динсезлек һәм әхлаксызлык таралачак. Гаилә корылышы тәмамән бетәчәк. Бу дәвер үзенең табигый юлыннан үтсә, 2012 елда Русиянең күтәрелүе башланачак. Берәр төрле гайре табигыйлек керсә, Русия дә Рума императорлыгы кебек бөтенләй югалып китәчәк.

Машков хисабына күрә безнең илебезнең үз истикъляллына кавышуы 1952 елларда булачак. Бу дәвердә Идел-Уралның алтын дәвере кергәнгә, ул Чыңгыз дәүләтен җанландыра алачак һәм бөек төрек-татар императорлыгы яңадан дөньяга чыгачак.

Машковның урыслар хакында язган сүзләре бу көнгә кадәр хәрефенә-хәреф дөрест чыкты. Шуңар күрә, аның безнең хакта язганнарының да дөрест булып чыгуын өмет итә алабыз. Үзебезнең кара көннәребезнең бетеп килгәнен һәм безнең дә тарихыбызда таң дәверен яшәгәнебезне уйлап, кояш тууының якынлашуына сөенә алабыз.

Чынлап та, Русиянең бу көнге хәле большевиклар тарафыннан коммунизм җирләштерү уңышлары кебек күренсә дә, читтән караучыларга ул урыс халкының дәүләтчелек банкротлыгы һәм «бөек Русиянең үлем җеназасы гына». СССРда яшәүче урыс булмаган милләтләрнең 15 (журналда «05» дип куелган) ел эчендә бер туктамый сугышып килүләре большевиклар карашыннан никадәр «контрреволюциончылык» һәм «буржуачылык» дип аталмасын, алар — Русиянең аерылу-бүленү] көченең куәтләнүен күрсәтә торган җанлы дәлилләр. Бу тартышта башка төрек илләре берлә бергә безнең Идел буе төрек-татары да үзенең дәгъвасын бөтен саф буйлап алып барганга һәм аның аерым бер дәүләт булып яшәү өчен кирәк булган бөтен шартлар табылганга күрә, аның да мөстәкыйль бер дәүләт булып мәйданга чыгуы форсатка гына бәгланган бер нәрсә икәнлегендә бүген һичбер объектив кешенең шөбһәсе юк һәм була алачак та түгел. Ул һичбер көтелмәгәндә безнең дә алдыбызга килеп басачак. Тик шул көнне каршы алырга безнең хәзер булып җитүебез генә кирәк.

Кереш мәкаләне һәм текстны басмага филология фәннәре кандидаты ***Гөлназ Хөснетдинова*** *әзерләде.*

КОЛ ШӘРИФ

***

И күңел, бил баглама, күбне кичүргән дөнйадыр,
Бу үлем ширбәтен халыкга ичүргән дөнйадыр.
Сән сыгынма дөнйада мән бакъи калгаймән тийү,
Күб йанар вакътда чырагларны [ут, шәм] үчергән дөнйадыр.
Угълыны атадин айырыб, кызны анадин тәкъи [шулай ук],
Йыглатыб бер-бер ишекдә зари кыйлган дөнйадыр.
Әүүәлене кемсә белмәс, ахырыны һәм тәкъи,
Әүүәле һич, ахыры һич, бер көһенә [сәләмә, иске] дөнйадыр.
Кол Шәриф, атаң-анаң, сәндин борынгылар кани [кая],
Барчаны куйыныга ашнәи [дус] кыйлган дөнйадыр.

Борынгы Казан урамында. Нияз Хаҗиәхмәтов

Ханның Кол Шәриф белән әңгәмәсе.
Нияз Хаҗиәхмәтов.
Киндер, майлы буяу.
2003 ел

ШАГЫЙРЬНЕҢ ҺӘЛАКӘТЕНӘ 460 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕ БЕЛӘН

ШАГЫЙРЬ КОЛ ШӘРИФ ХАҖИ ТАРХАНИ

МАРСЕЛЬ ӘХМӘТҖАНОВ,
филология фәннәре докторы, профессор

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫНДА СОҢГЫ ЕЛЛАРДА ГЫНА ТЕЛГӘ АЛЫНА БАШЛАГАН ПАТРИОТ ҺӘМ КАҺАРМАН ШАГЫЙРЬНЕҢ ИСЕМЕ ИНДЕ ХӘЗЕР ШАКТЫЙ КИҢ ТАНЫЛУ АЛДЫ. КРЕМЛЬ УРТАСЫНДАГЫ АНЫҢ ИСЕМЕН ЙӨРТКӘН ЗАТЛЫ МӘЧЕТ КАЗАННЫ ГЫНА ТҮГЕЛ, БӨЕК ШАГЫЙРЬНЕҢ ИСЕМЕН ДӘ БӨТЕН ДӨНЬЯГА ТАНЫТТЫ.

Шагыйрьнең тулы исеме Кол Мөхәммәд-Шәриф сәйед Мансур сәйед углы, сәйедләр нәселеннән Сәйед ата оныгы икәнлеге аның безнең көннәргә кадәр сакланып калган бердәнбер «Зафәрнамә-и вилаяте Казан» («Казан вилаятенең җиңүе») әсәрендә китерелә [1].

Кол Шәрифнең биографиясенә иң тулы чыганак — хәзергә аның кулы белән язылган, югарыда искә алынган тарихи язма. Шагыйрьнең Казанга килүе аның атасы Мансур сәйеднең Сафа Гәрәй хан белән дуслыгыннан башланган. Мансур сәйед белән Сафа Гәрәй хан 1546 елда Казанда яшәгән булып, шул елда шәһәрдәге фетнә вакытында Әстерханга китеп баралар. Кол Шәриф әсәрендә язылганча, Мансур сәйед 1550 елга кадәр үлгән була инде. Әтисе үлгәч, Кол Шәриф әтисенең дусты Сафа Гәрәйнең сәйеде булып калган.

Сафа Гәрәй хан 1549 елның мартында һәлак булганнан соң да, иң абруйлы дәүләт эшлеклесе, дипломат санала, гомеренең соңгы көннәренә кадәр Ватан һәм иман сакчысы булып хезмәт итә.

Кол Шәрифнең тормышына беркадәр аның уникаль әсәренең теле дә чыганак булып тора. Ядкәрдән аңлашылганча, шагыйрь Бохарада укыган, аның бабалары да Алтын Урдадан чыгып, Бохарага барып төпләнгән сәйедләр булалар. Кол Шәрифнең әтисе — Мансур, Мансурның әтисе — Сәйед ата. Сәйед атаның исеме Себердәге сәйедләр шәҗәрәсендә дә күрсәтелә [2]. Касыйм ханлыгыннан калган сәйедләр шәҗәрәсендә дә Борһан сәйед исеме XV-XVI гасырлар чигендә яшәгән

кешегә туры килә. Касыйм ханлыгына 1502 елда Әстерханнан Мәскәүгә чыгып, Касыйм тәхетендә Шәйех-Әүлияр солтан утырган (1516 елда үлә). Аның дәверендәге Касыйм сәйедләренең Әстерханнан әлеге солтан белән бергә килүләре мөмкин.

Борһан сәйед исеме Касыйм сәйедләре — Шакуловлар шәҗәрәсендә дә бар. Ул шәҗәрәдә 49 нчы сан белән 31 нче буында күрсәтелә.

Шакуловлар шәҗәрәсеннән бер өзек:

	31 буын	
49.	Сәйед Борһан сәйед	48
	32 буын	
50.	Сәйед Кашки	49
	33 буын	
51.	Сәйед Бүләк сәйед	50
	34 буын	
52.	Акмөхәммәд сәйед	51
53.	Ишмөхәммәд сәйед	51 һ.б.

Тарихчы В.В.Вельяминов-Зернов язуына караганда, Казанны 1552 елда урыслар алган вакытта, алар ягыннан Ак сәйед шәриф сәйед углы катнашканлыгы мәгълүм. Бу очракта Ак сәйед исеменең Акмөхәммәдтән кыскартылган булуы ярылып ята. Аның атасының исемен әйтмичә, хөрмәтләп, «шәриф сәйед» дип язуга да беркеткәннәре аңлашыла. Акмөхәммәднең атасы Бүләк сәйед тә тарихи шәхес, аның кабере Касыймның Иске Бистә зиратында булганлыгы ачык мәгълүм. Кашки сәйеднең дә кабере Касыйм шәһәренең Иске Бистә зиратында куелган булган [3].

Акмөхәммәд сәйед Казан алынганда — 1552 елда, Шаһ Гали гаскәрендә полк командиры буларак катнаша, димәк, аның яшен 35ләрдә дип чамаларга була. Ә инде аның улы Кашки сәйеднең Касыйм шәһәрендә 1587 елда зур дәрәҗәле түрә булуы В.В.Вельяминов-Зернов тарафыннан табылган патша Фёдор Иванович биргән ярлыкта күрсәтелгән [3].

Димәк, безнең каһарман шагыйребез касыймлы Акмөхәммәд сәйед белән кордаш булган.

Касыйм шәһәренә сәйедләрнең кайдан килүләре хакында да тарихи сорау куярга ярый. Акмөхәммәд сәйед — Шаһ Гали хан тарафдары, Шаһ Галинең атасы Шәйех Әүлийар солтан һәм Әстерхан ханзадәсе Бәхтийар икесе 1502 елны Әстерхан ханлыгыннан Мәскәү кенәзлегенә хезмәткә күченеп киләләр [4]. Әлбәттә, алар Мәскәүгә ике бертуган булып кына түгел, үзләренең яраннары, сакчылары, дуслары һәм фикердәшләре белән күчеп киләләр. Ихтимал, алар арасында сәйедләр дә булгандыр.

Югарыда китерелгән Шакуловлар нәсел шәҗәрәсен андагы бабалар турындагы тарихи мәгълүматлар ярдәмендә тәнкыйть күзе белән карап карыйк.

Акмөхәммәд сәйед 1552 елда ир уртасы кеше булганда, аның бабасы итеп күрсәтелгән Кашки сәйед Касыймның зур түрәсе була. 1587 елда аңа Фёдор Иванович патша биргән ярлык моны дәлилләсә дә, хронологик яктан урын буталчыклыгы килеп чыга.

Акмөхәммәднең атасы Бүләк сәйед булуга әле тарихи каршылык күренми. Бүләк сәйеднең Шаһ Галинең атасы белән Әстерханнан килгән булу ихтималы ачыла. Бу кеше Әстерхандагы Мансур сәйеднең якын кардәше булырга тиеш. Ә Әстерханга сәйедләр кайдан килгән соң? Бу сораугa Себердә табылган сәйедләр шәҗәрәсендәге кайбер шәхесләрнең исемнәре җавап бирә. Аннан безнең өчен кызыклы булган бер өзек китерәбез:

«Сәйед Җәлалетдин. Сәйед Җәлалетдин улы Сәйед Борһан.

Сәйед Борһан улы Сәйед ата. Сәйед ата улы Сәйед Тупучак... һ.б.» [2].

Әлеге шәҗәрә өзеге борынгыдан бирле күчерелеп киленгән «Сибирийәдәге Айтигин шәҗәрәсе» дигән тексттан алынды. (Аның төп нөсхәсе Санкт-Петербургтагы Ризаэтдин бине Фәхретдин архивы фондында саклана).

Шәҗәрә текстында нәсел тарихы дәвамында 27 буын алышынуы күрсәтелә. Соңгы 27 нче буын кешесе — Хорамшаһ хуҗа 1877 елның 23 апрелендә Тара шәһәрендә үлеп, шунда күмелгән [2].

Хорамшаһ хуҗа — Сәйед атадан килгән 12 нче буын. Хәзер 12 буынны хронологиягә салып чыксаң, Сәйед атаның 1500 елларда яшәгән зат икәнлеге ачыла.

Кол Шәрифнең «Зафәрнамә-и вилаяте Казан» әсәрендә автор үзен Сәйед ата оныгы дип күрсәтә: «Тагын бер капкада пәйгамбәребез нәселеннән Сәйед ата оныгы, мәрхүм һәм мәгъфүр [ярлыканган] сәйеднең углы Кол Мөхәммәд сәйед бөеклеге дәвам итсен, башлап яшь дәрвишләрне һәм суфыйларны туплап, газа [изге сугыш] атына атланып, янә сугышка чыныктырып, сугыш киемнәре киеп, кяфергә каршы хәзерләү һәм караудa иде» [5].

Бу юллар аның авторын ниндидер бүтән исемнәр белән күрсәтергә теләүче скептик татар тарихчыларына һәм әдәбиятчыларына ялгыш фикердә булуларын күрсәтерлек көчкә ия. Юкка гына Казанны саклап, 1552 елның октябрендә сәйед Кол Шәриф шәкертләре белән Ватан өчен соңгы сулышына кадәр үзен аямыйча көрәшмәгән.

Йомгак ясап әйткәндә, без югарыда татар халкының әле фәнни яктан аз өйрәнелгән шәҗәрә язмалары мәгълүматлары нигезендә Кол Шәрифнең XIV гасырда Мисыр мәмлүкләре иленнән Алтын Урдага килеп, аның төрле өлкәләренә таралган сәйедләре системасында тарихи урынын ачыкладык.

Шагыйрьнең бердәнбер әсәрендәге образлар системасы һәм иҗатына тәэсир иткән көнчыгыш поэзия титаннарының төсмерләренә карап, укымышлылыгы, әдәби зәвыгы, менталитеты турында да беркадәр язып үтәргә мөмкин. Мәсәлән, шигырьләрендә Идел буе поэзиясе өчен хас булмаган Җәйхун (Амудәрья) елгасы атамасы кулланув, аның Урта Азия менталитетын да саклавын күрсәтә.

Гомумән, Кол Шәриф әсәрләрендә Фирдәүси һәм Нәваи тәэсире шактый нигезле күренә. Мәсәлән, аның дүртьюллыкларында Казанны саклаучы батырларны Дара (Дарий), Искәндәр (Александр Македонский), Рөстәм, Баһрам кебек атаклы фарсы батырларына тиңләп тасвирлавы шул хакта сөйли.

Бер үк вакытта Кол Шәриф әсәрләрендә татар чәчәннәре иҗаты элементлары да чагылып үтә.

Безнең кайбер әдәбиятчылар Кол Шәриф Мансур сәйед улын XVII гасыр ахырында иҗат иткән Кол Шәриф исемле суфый үзбәк шагыйре белән буташтыралар. Хәлбуки, үзбәк шагыйренең иҗаты Үзбәкстанда да, Төркиядә дә яхшы ук билгеле һәм аның хакында фәнни мәкалә дә басылган.

Кол Шәриф Хаҗитархани — XVI гасырда яшәгән бердәнбер патриот һәм тормышны, тарихны белеп иҗат иткән уникаль шәхес. Казан турындагы бер газәле генә дә шагыйрьне бөекләр дәрәҗәсенә күтәрә.

КОЛ ШӘРИФ ШИГЫРЬЛӘРЕ

БӘЙЕТ

Гозат [газыйлар] әһлинә гамәлдә —
Хөсне лотафәт [нәфислек] бар.
Зәфәр [җиңү] тапса — ганимәт [байлык],
Зур шәһадәт [таныклык] тапса —
Җәннәт бар.

КЫЙТГА

Кимгә бер ук атса — мөшрикләр [дошманнар] йөзигә
Дин өчен,
Гүййә Хак йулыйда —
Бер бәндә азат әйләйә.
Бу әҗердә [савабта] бергәдүр
һәр ким гозат [газыйлар] өмидидә —
Бер ук атылгай, йә —
шәмшир [кылыч] бонйад [башлангыч, нигез] әйләгәй.

КЫЙТГА

Бер кичә көндез гозат
Өмидилә ат багламак —
Йахшыйдыр бер ай тоташ
соум [ураза] вә кижә әгъләм [гамәл, эш, көч түгү] дин.
Улса гәр ризык вә савабы —
Тигерсәйдүр корбдә [дан, хөрмәт, якынлык],
Улмаса имин улгусыйдур
фетнә-и Дәҗҗалдин.

ГАЗӘЛ

Аһ, вә уйла үлүмдин —
тәндәге җан тетрәйүр,
Җандин айырылмак бәладүр, —
тийү бәдән тетрәйүр.

БУ ҮЛҮМДЕР БАРЧАНЫ...

Бу үлүмдер барчаны
мәгъмүм [кайгылы] вә мәхзүн [моңлы] әйләгән.

Бу үлүмнең хорфидин [җүләрлегеннән]
чәшмә-и [күзләре] хайван тетрәйүр.
Йир йүзүдәги үлүмнең
зәрбәтидин [сугуыннан] халык ара,
Күктәге йолдызлар вә шәмсе [кояш]
дәрәхшан [ялтыраган] тетрәйүр.
Ки йөзин йыртыб
карар тиб,
ки кызарыб, саргайыб,
ки качыйб пәнһан [яшертен] булуб
Һәм маһтабан [ай яктысы] тетрәйүр.
Дәфгы итиб [кире кайтарып] булмас үлүмни,
Мал бириб ләшкәр йигыйб [гаскәр җыеп].
Бу сәбәбдин вә һәм йитиб,
Хан бәлки солтан тетрәйүр.
Күңлүнә төшкәндин үтрүр
Ки вә һәм [кайгы] нәгяһан [көтмәгәндә].
Зилзилә [давыл, җир тетрәү] әйләб бигуаһ [шаһитсыз]
Вә бийабан [бушлык, дала] тетрәйүр.
Әй, Шәрифи, мөстәгыйд [хәзер булып торучы]
Булмак кирәк үлмәс борун.
Йукса димәкдин нәсудин [тишелмәгән, эшкәртелмәгән энҗе]
Тетрәйүр ан тетрәйүр.

КАЗАН ШӘҺРИ
(Газәл)

Гаҗәб бер җай [урын] гыйшрәтдүр [күңелледер] җиһанда —
Бу Казан шәһри,
Моныйң тик булмагай гамәлдә бер
Дар әл-аман [тынычлык, иминлек] шәһри.
Казан тик шәһәр мәгъмүри [төзек] табулмас
Дөнйада һәргиз [һәр урында].
Казандин аш ичәдүрләр ничаклы
Бу җиһан шәһри.
Бу бер милке ирүр калмыйш абаэ
Гайн җәд ханлардин.
Ирүр бу йир һәмишә дөнйада хан ибне [улы]
Хан шәһри,
Йирин-йортыйн сатыйб бирмәс
Атасыйныйң йасакыйн [налог өчен].
Ничүк килгәй ушал мәлгун, имәсдүр [түгелдер]
Бу Ибан шәһри.
Шәрифи, китмә бу йирдин газаи [изге сугыш]
Өмиде гәр булса,
Бу көндин соң дигәйләр ким, — булдыр
Сахиб [хуҗасы] Казан шәһри.

КАЗАН ХАНЛЫГЫНДА МӘРХҮМ ПУЛАТ БӘКНЕҢ УГЛЫ МАМАЙ БӘК БЕРЛӘ НУРГАЛИ МИРЗАГА — КАЗАННЫ 1550 ЕЛДА САКЛАП КАЛГАН БАТЫРЛАРГА

Мөбаризлар [сугыш мәйданына чыгып бергә-бер сугышучылар]
торур саф-саф кашыйда,
Куйубән таҗ носрәтне [җиңү, уңыш, ярдәм] башыйда.
Ирер мәйдан ара һәр бери бер шир [арыслан],
Орурлар һәр заман дошманга шәмшир [кылыч].

КАЗАН ШӘҺӘРЕНДӘ ХАЛЫКНЫҢ АТАКЛЫ ГАСКӘР БАШЛЫГЫ ҺӘМ СУГЫШЧЫСЫ КУЗЫЙЧАК УГЛАНГА (Шигырь)

Күрсә коффра [дошманнар] илә һәр ким хәреб [сугыш]
Аййамида [шәфкатьсез],
Даимә [һәрчак] ислам шәмширин [кылычын] кулыйда
Оставар [эзтабар],
Димәгәй ул кеши һәргиз гомридә
бергиз тәкый [гадел, юаш].
Ля фәта илла Гали, ля сәйфулла зөлфөкар*.

КАЗАН КАЛАСЫНЫҢ БЕР КАПКАСЫН САКЛАУЧЫ БАТЫР ЯШЬЛӘРНЕҢ ҖИТӘКЧЕСЕ ИСКӘНДӘРГӘ ТИҢ АЛЫП, БАҺАДИР АКМӨХӘММӘД УГЛАНГА

Ирүр безим ичрә [арага], рәзем [сугыш]
ичрә Рөстәм [Туранның легендар батыры],
Бу йирдин, булмасун һич сәййәсе кәм [эше ким].

КАЗАННЫҢ ТАГЫН БЕР КАПКАСЫН САКЛАУЧЫ ДАРА ҺӘМ ИСКӘНДӘРГӘ, РӨСТӘМ ҺӘМ БАҺРАМНАРГА ТИҢ БАТЫР БУЛГАН БАРБУЛСЫН АТАЛЫККА

Илаһи ул дөнйада бар булсын!
Һәмишә [һәрвакыт] фәтх [җиңү] носрәт [тантана]
йар булсын [юлдаш булсын]!
Баһадирлыкта һәм булса, кеми йук,
Бу көн тайса шәһадәт [иманы] һәм гаме йук [исе китми]
Үз тәвабигъ [иярченнәре] вә ләвахаклары [хезмәтчеләре]
берлә торур ирди.

*Тәрҗемәсе: Ирләрнең ире Галидер, кылычларның иң үткене зөлфөкардыр — Кузыйчак угланның даими әйтә торган сүзе булган. — М.Ә.

КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ БЕР КАПКАСЫНДА ШӘҺӘРНЕҢ БӘГЕ, БОЛГАР ВИЛАЙӘТЕНЕҢ ХАКИМЕ, СОЛТАННАРНЫҢ КҮЗ КАРАСЫ, ХӨРМӘТ ҺӘМ БӨЕКЛЕК ЭНҖЕСЕ, ХАННЫҢ ХӘЗИНӘ КАПКАЛАРЫН АЧКАН БИБАРС БӘКНЕҢ ГАЙРӘТЕ АРТСЫН

(Аңа багышланган бер уникеюллык фарсы телендәге шигыре дә бар.)

БӘЙЕТ

Гәрчә һәр утны килиб сүндерсә булгай
Су койуб.
Буйлаллыйг утны ки һәм су берлә
Булмас сүндерүб.

ШИГЫРЬ

Суга балыйк утга сәмәндер [чаян] кирәк,
Иш күнидә мәрд диләвер [курку белмәс ир] кирәк.
Ир кешигә ки һиммәт [дәрт, тырышлык], әгәр булса йар,
Гакыйбәт [ахырында] эл-әмер, морадыйн [теләгәнен] табар.

ШИГЫРЬ

Сакласа һәр кимни дошмандин
Ходай ләм йәзәл [югалмый белми].
Хаҗәт ирмәсдүр аңа кимәк
Зәррә гали хисар [зур ныгытма].
Сакламас булса такый (йук)
Бу икәүдин мәнфәгать.
Сакласа мөмкин имәс
Бер тилне кисмәк зөлфөкар.

Искәрмәләр

1. Кол Шәриф һәм аның заманы. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — Б.16-22.
2. Сибирийәдәге Айтигин шәҗәрәсе // Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре. — Беренче том. — Казан, 2012. — 434 б.
3. Әхмәтҗанов М. Сәйед Шакуловның шәҗәрәсе // Мәңгелеккә аяк басканда: Сәйед Кол Шәриф. — Казан: «Идел-Пресс», 2006. — Б.53.
4. Ахметзянов М.И., Шарифуллина Ф.Л. Касимовские татары. — Казань: Изд-во «Магариф», 2010. — С.139, 140.
5. Зафәрнамә-и вилаяте Казан // Мәңгелеккә аяк басканда: сәйед Кол Шәриф. — Казан: «Идел-Пресс», 2006. — Б.18.

Шигырьләрнең укылышы һәм сүзләргә тәрҗемәләре **Марсель Әхмәтҗанов** *тарафыннан эшләнде.*

СОҢГЫ СУГЫШ

(Бөек сәед Кол Шәриф турында тарихи эссе)

ДАМИР ИСХАКОВ,
тарих фәннәре докторы

Үз вакытында татарның күренекле тарихчысы, дин белгече Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дип аталган хезмәтендә Казан ханлыгында «габбасилардан һәм бөек сәедләрдән күпмедер шәхесләр булып, аларның башында нәкыйбел-әшрәф дип аталган мелла Шәрифкол исемле бер зат торуы» һәм аның «ислам ханнары һәм шәһәр халкы алдында ихтирамга һәм зур хөрмәткә лаеклыгы» турында язылган иде. Бу хәбәрне биргәндә ул кайбер риваятьләргә таянган булса кирәк, чөнки тарихчының Кол Шәрифкә багышланган алдагы юлларында «сөйлиләр» дигән сүзләр бар. Мәрҗани үз хезмәтендә тагын ике әйберне күрсәтә: 1) «Россия кенәзләре Казан ханнарына илчеләр аша хатлар күндергәндә, мелла Кол Шәрифкә дә махсус хат һәм бүләкләр җибәрә иделәр», — дип яза ул. 2) Кол Шәрифнең үлеме турында болай ди: «...россиялеләр Казанга һөҗүм иткәндә, ул, үзенең иярченнәрен җыеп, мәдрәсәгә керә һәм, мәдрәсә түбәсенә чыгып, руслар белән бик каты сугыша. Руслар аны мәдрәсә түбәсеннән чәнчеп төшерәләр һәм ул шулай итеп шәһит була...»

Дөресен әйткәндә, соңгы дәверләргә кадәр бездә Кол Шәриф турында язучылар әллә ни күп булмады (Галимнәрдән — М.Әхмәтҗанов һәм мин үзем дисәм, бу дөрес булыр). Шуңа күрә дә югарыда Мәрҗани тарафыннан китерелгән мәгълүматларны безгә кадәр тикшереп караучы да күренмәде. Ә баксаң, алар бик тә тирән мәгънәгә ия икән...

Әгәр дә без рус тарихи чыганакларына мөрәҗәгать итсәк, Шиһабетдин хәзрәт язганнарның кайбер якларын раслап була. Мәсәлән, Казанны алучылар арасында булган рус кенәзе, воевода Андрей Курбский үзенең «История о великом князе московском» дигән хезмәтендә рус гаскәрләренең



Мәдрәсә диварлары янында Кол Шәрифнең аяусыз көрәше. Нияз Хаҗиәхмәтов

1551 елгы Казан Кремле эчендәге сугышын тасвирлаганда, түбәндәгене күрсәтә: «…прогнали войско казанского царя (сүз Мөхәммәд-Ядегәр хан турында бара. — *Д.И.*) аж до мечетей, что вблизи его двора стоят (ягъни, хан сарае янында. — *Д.И.*), и встретились там с их обызами, сеитами и молнами и с их великим епископом, а по их языку великим анарыем (латинча «honor» — хөрмәтле, дәрәҗәле сүзеннән. — *Д.И.*), або амиром по имени Кул Шериф мулла, и сразились они с нашими так сильно, что все до единого погибли…» Шуңа охшаган мәгълүмат Мәскәүнең рәсми елъязмасы булган Никон (Патриарх) елъязмасында да бар: «…и приближа христиане к мечети к Кул Шерифу х Тезитьскому врагу (оврагу — *Д.И.*), и тут с Кул Шерифом молною многие неверные совокупившеся и зле биющеся, — убиша Кул Шерифа с его полком, … одолеваху Кул Шерифа, со всеми его побиша». Һәм ниһаять, Казанда әсирлектә булып, соңыннан Мәскәү ягына кайтып киткән исеме билгесез бер рус авторының «Казанский летописец» дип танылган әсәрендә Казан эчендәге сугыштан соңгы вакыт һәм Иван IVнең шәһәр эчен чистарту турындагы боерыгын үтәүне тасвирлаганда: «…ту же наидоша в трупии том и сеита казанского убита, и … князя Чапкуна», — дип әйтә.

Чыганаклар барысы да бер сүздә — Кол Шәриф сәед рус гаскәрләренә каршы батырларча көрәшеп үлә, ягъни, чыннан да, шәһит була.

Ләкин, без шушы фактны гына тасвирласак, бу ул заманнарда булган вакыйгаларга карата бик тар бер караш кына булыр иде. Чынлыкта татар тарихчылары Кол Шәриф турында, хәзер инде Мәрҗани дәвере белән чагыштырганда, күпкә яхшырак беләләр. Шул турыда берничә сүз әйтеп китү кирәк булыр.

Һичшиксез, А.Курбский Кол Шәриф турында язганда, аны «бөек епископ», «әмир» һәм «бөек анарый» дип исемләгәндә, сүз бу шәхеснең татар чыганакларында күренгән титулы турында бара. Әйтик, Сәхибгәрәй

ханның 1523 елгы ярлыгында аксөякләр арасында «садати/судати — гозам/газам» исемнәре искә алына. Ә ул тезмә «бөек сәедне» аңлата — «садат» төшенчәсе сәед дигән мәгънәгә ия, ә гозам/газам — хуҗам дигән сүз булса кирәк. Чынлыкта, Мәрҗани китергән «нәкыйбел әшраф» дигән төшенчә дә шул ук мәгънәгә ия (нәкыйб — җитәкче дигән сүз, әл-шәриф — сәедләр нәселеннән дигәнне аңлата, ягъни «сәедләрнең җитәкчесе» килеп чыга). Урысчага тәрҗемә килеш сакланган бер Кырым ханлыгының 1542 елгы «дәфтәр»ендә дә мондый сүзләр бар: «А се величество учителей великих». XV йөз Кырым ярлыкларында ул төшенчәгә «сәйид-ес садатлар» дигән юллар туры килә дип уйларга урын бар. Нәтиҗә шул: Кол Шәриф Казан ханлыгындагы барлык руханиларның башлыгы, бөек сәед — «нәкыйбел-әшраф» булган. Аның нәсел очы кая барып тоташа соң? Бу турыда төгәл мәгълүмат юк, ләкин бер гипотеза әйтеп була.

Эш шунда ки, кайбер мәгълүматлар буенча (алар турында минем 2011 елны басылган «Институт сеййидов в Улусе Джучи и позднезолотоордынских тюрко-татарских государствах» дип исемләнгән хезмәттән тулырак карый аласыз) Кол Шәриф аннан алда Казан ханлыгының бөек сәеде булган һәм 1551 елның көзендә Шаһгали тарафынан 70 татар аксөяге белән бергә үтерелгән Кол Мөхәммәднең туганы (энесе?) дип уйларга урын бар. Һәм бу очракта алар икесе дә Мансур сәеднең уллары булып чыгалар. Соңгысы бер дәвердә Кырымда бөек сәед булып, 1531 еллар тирәсендә Әстерханга Исламгәрәй белән бергә күчкән булса кирәк. Менә шушы гипотеза белән эш иткәндә, бик кызык нәтиҗәләр килеп чыга.

Беренчесе. 1550 елны Казаннан госманлы солтан Сөләймән Кануни тарафына юлланган хатта (аның авторы — Шәриф Хаҗитархани) бөек сәед Кол Шәриф алдыннан бөек сәед булган Кол Мөхәммәд сәед турында мондый юллар бар: «...Тагын бер капкада (Казан Кремле капкасы турында сүз бара. — *Д.И.*) пәйгамбәребез нәселеннән (игътибар! — *Д.И.*) Сәед ата оныгы, мәрхүм һәм мәгъфүр сәеднең углы Кол Мөхәммәд сәедбөеклеге дәвам итсен...» Әлеге чыганакны башлап бастырган Төркиядә иҗат иткән башкорт тарихчысы Әхмәдзәки Вәлиди-Туган фикере буенча, бу урында сүз Ясәвийә тәрикатые турында бара. Ә хәзер исә АКШ тарихчысы Девин Де Вис хезмәтләренә таянып шунысын да әйтергә була: «Сәйед-Ата» дип исемләнгән шәхес Үзбәк хан һәм аның халкын, ягъни Алтын Урда татарларын, ислам диненә кертүчеләрнең җитәкчесе булган, аның чын исеме — Әхмәт, атасының исеме — Гәбделхәмит; алар сәедләр нәселеннән, ягъни шәҗәрәләре Мөхәммәд пәйгамбәргә (с.г.һ.) барып тоташа. Нәкъ менә шушы тарихта калырлык хезмәте өчен Үзбәк хан аны «шәрифләрнең башлыгы» — «нәкыйбе әш-шәриф» яки «әс-сәеде әш-шәриф» итеп билгели. Бу сүзләрдәге «нәкыйб» төшенчәсенең «эзләү, тикшерү» дигән беренчел мәгънәсе булып, инде монголларгача дәвердә үк ул сүз «җитәкче» дигәнне белдергән һәм сәедләрнең рәисен аңлаткан. Ханның боерыгы буенча бу югары дәрәҗәле урын Сәед-Атаның нәселенә беркетелә һәм алар хәрби эшләрдә дә әһәмиятле роль уйнаганнар. Хан сараенда утырганда Сәед-Ата һәм аның варислары сарайда ханнан аз гына түбәнрәк, әмма солтаннардан югарырак урында утырганнар. Димәк, бу шәхесләр, чыннан да, бик дәрәҗәле булганнар. Алар Чыңгызыйлар һәм бөек татар бәкләре белән туганлашканнар да. Соңыннан безгә мәгълүм татар ханлыкларындагы барлык сәедләр дә шушы нәселдән булганнар, ахрысы. Бу фикерне рас-

лаган тагын бер чыганак — Касыйм шәһәрендә сакланган Шакуловлар шәҗәрәсе. Алар да Касыйм ханлыгындагы сәедләр нәселеннән.

Шулай итеп, югарыда китерелгән чыганактагы Кол Мөхәммәд сәедкә карата кулланылган «пәйгамбәребез населеннән Сәед-Ата оныгы» (монда оныгы — киң мәгънәдә. — *Д.И.*) дигән сүзләр Кол Шәрифкә дә кагыла дип уйлыйм.

Икенчесе. Кол Шәрифнең соңгы сугышы, һичшиксез, газават сугышы булган. Ләкин аны аңлау өчен, безгә тагын бер тапкыр тарихи чыганакларны барлап чыгарга кирәк. Инде югарыда әйтелгәнчә, Үзбәк хан дәвереннән башлап Сәед-Ата варислары хәрби эш белән дә шөгыльләнгәннәр. Казан ханлыгында да бу шулай булган. Мәсәлән, Олуг Урдага каршы Кырым ханына ярдәмгә җибәрелгән рус гаскәре белән бергә хәрәкәт иткән Казан гаскәрендә 1491 елны Бораш сәед тә күренә. Шундый ул хәл Касыйм ханлыгында да күзәтелә. Анда XVI гасырда сәедләр гаскәри эшләрдә катнашып кына калмаганнар, аларның үз хәрби оешмалары да булган. Ул рус чыганакларында «Сәед полкы» дип аталган. Әгәр дә без Казан ханлыгына кире кайтсак, 1549 елда руслар белән Казан гаскәре арасындагы сугыш вакытында шәһәрне саклап аның бер капкасы янында хәрәкәт иткән Кол Мөхәммәд сәеднең кул астында «яшь дәрвишләрдән һәм суфыйлардан» торган гаскәри берләшмәсе булуын күзәтәбез. Мөгаен, бу аерым бер хәрби берәмлек булгандыр. Шушы күзлектән караганда, Кол Шәрифнең 1552 елда хафизлар, сәедләр, муллалардан торган «полк» башында көрәшүе дә шул ук иске традициянең бер чагылышы булган булса кирәк.

Ләкин 1552 елгы вакыйгаларның Кол Шәриф өчен булган бөтен трагик эчтәлеген аңлау өчен, аның 1550 елны төрек солтаны Сөләймән Канунига язган хатына мөрәҗәгать итү таләп ителә. Бу хат «Зафәрнамәи вилаяте Казан» исеме астында билгеле. Хатта 1549 елны Казан гаскәренең рус гаскәрен тар-мар итүе тасвирлана. Әмма, ныклап тикшереп укысаң, ул язманың бик тә хикмәтле һәм фәлсәфи яклары да килеп чыга.

Аның авторы, ягъни сәед Кол Шәриф, сүзне башлаганда: «Казан мөселман өлкәләреннән еракта һәм кяфер өлкәсенә чиктәш урнашкан», — дип әйтә. Шуннан соң ул өстәп куя: «Һичкем яманның күршесендә булмасын!» Кол Шәриф, дипломат буларак, аек акыллы кеше булган һәм үз дәверендәге сәясәтне бик тә дөрес аңлаган. Бу турыда аның түбәндәге юллары сөйли: «Казанга һичбер җирдән ярдәм һәм таяныч ирешмәс, бары тик Тәңре якын һәм фәрештәләр ярдәмче». (Бүгенге көннәр искә төшмиме, мөхтәрәм укучылар?) Шулай да хатның авторы дәвам итә: «Шушы авыр сәбәптән Казан шәһәренең падишаһлары кяфер иле белән килешүләр аркылы мәмләкәтләренең җитешлеген тәэмин итәләр. Халкының рәхәте һәм яшәеше өчен Мәскәү белән солых төзелеп, ике арада илчеләр йөрешер, аңлашып һәм барышып, килешеп йөрмәктә иделәр», — ди ул. Тагын өстәп куя:

Тәртип ике яклыдыр,
һәм ул ике сүздә аңлатыла:
Дусларга гайрәт һәм дошманнар
белән барып йөрешмәк.

Әмма «имансыз Иван» барыбер Казан шәһәре янына килеп, аны 1549 елны камап ала. Шул турыда язган Кол Шәриф башкалага багышланган бер газәл китерә:

Гаҗәйеб бер җай-гыйшрәттер
җиһанда бу Казан шәһре.
Моның тик булмагай галәмдә,
борадәр, әл-Аман шәһре.

Аннан соң ул бу шәһәрнең «хан шәһәре» икәнен искәртеп, әйтеп куя:

Йирен-йортын сатып бирмәс
атасының ясакыны,
Ничек килгән ушал (шушы) мәлгунь
имәсдер (түгелдер) бу Ибан шәһре.

Алга таба Кол Шәриф бик җентекләп ике арадагы 1549 елгы сугыш хәрәкәтләрен тасвирлый. Һәм Кол Мөхәммәд сәед тирәсендә булган сугышчылар турында язганда, ул сәеднең «дәрвишләрне һәм суфыйларны туплап, газа атына атланып (ягъни — газават юлында — *Д.И.*), карауда» булганлыгы турында яза. Сугыш барышын ул болай тасвирлый (хәзерге тәрҗемәдә бирелә):

Хәнҗәр чыңы бар мәйданны каплады,
Казан шәһәрендә кан
Әму-Дарьядай акты.

Кол Шәриф әфәнде гади шәхес булмаган. Шуңа күрә дә ул бу язмада берьюлы ике фикерне әйтә. Башта ул рус гаскәре килгән вакыт турында сөйләп, Коръәннән бер аять китерә һәм Аллаһы исеменнән аңлата: «...яманлык та Аллаһтан [...] нигә алар (ягъни, казанлылар — *Д.И.*) моның шулай икәнлеген аңлый алмыйлар икән?» — ди ул. Ә инде татарларның җиңүе турында язганда өстәп куя: «Әгәр Аллаһ сезгә ярдәм итсә, үзегезне һичкем җиңә алмас». Бу шулай ук Коръәннән бер сүрә. Ниһаять, ул нәтиҗә ясый: «Тәңре явыз кавемне соңгы кешесенә кадәр юк итте, Тәңрегә мең шөкер булсын. Каланың ике тарафында кара кяфер үлесе кылыч һәм хәнҗәр корбаны, кортларга ризык булып ятарлар иде. Аяк басарлык та җир калмады». Шунысын әйтергә кирәк: бу сугыш турында рус елъязмалары бер дә язарга яратмыйлар...

Хатның ахырыннан аның төрек солтанына мәгълүмат буларак җибәрелгәнлеге күренә. Ләкин шунысы аңлашыла: Кол Шәриф ул яктан ярдәм килмәячәген яхшы белгән. Алай гына да түгел, ул үзе дә бер дилемма алдында торган, чөнки Казанга килгән куркынычның ничек тәмамланырга мөмкинлеген аңлаган хәлдә, үз-үзенә мөрәҗәгать итеп болай ди:

Шәрифи, китмә бу йирдән,
газа әмидегәр булса,
Бу көндин соң дигәйләр кем,
будыр сахиб Казан шәһре.

Китерелгән юллардан күренгәнчә, туганы Кол Мөхәммәд үлгәннән соң, бөек сәед дәрәҗәсен алган Кол Шәриф инде 1550 елны ук, яңа урыс һөҗүме була калса (ә татарларда аның булачагын аңлау булган), Казан җиреннән китмәскә карар кыла. Кол Шәрифнең Әстерхан һәм Кырым белән бәйлелеген исәпкә алганда, читкә китү мөмкинлеге, әлбәттә, булган. Аның позициясе Ясәвийә тарикате рухи дөньясына барып тоташкан. Ә ул дөнья исә Харәзем ягы мөселманнары һәм Алтын Урда чорларында формалашкан ислам җәмгыяте белән бәйләнгән. Шуңа күрә дә 1552 елны Казан ханлыгында алып барылган газават сугышы чынлыкта бөтен мөселман өммәтенә дә кагылган, ләкин, Кол Шәриф күрсәтеп үткәнчә, ул дәвердә бу дөньядан төрле сәбәпләр аркасында татарга ярдәм һич килерлек булмаган.

Тагын бер мәсьәләгә тукталып китү кирәк. Кайбер очракларда сүз, Кол Шәрифнең дипломатик эшчәнлеге турында сөйләнгәндә, аның бу өлкәдә тискәре гамәлләре булганлыгы турында бара. Бу мәсьәләгә карата Татарстанда тарихи әдәбият язучылар да булды. Төгәлрәк әйткәндә, сүз аның 1551 елны Сөембикәне һәм Үтәмешгәрәйне русларга бирүдә катнашканлыгы турында бара. Ләкин, бу

вакыйгаларга, чыннан да, турыдан-туры катнашкан Кол Шәрифкә генә гаеп ягу дөрес булмас, чөнки ул бары тик гомумдәүләт карарын үтәүче генә булган. Моның шулай икәнлеген ул вакыйганы яктырткан тарихи чыганаклардан күреп була.

1551 елның апрель аенда рус гаскәрләре Казанга каршы һөҗүм башлыйлар һәм июль аенда шәһәрне чорнап алалар. Авыр вакытлар җитә, казанлылар бу гаскәргә каршы тора алмаячакларын аңлап, баскынчылар ягына илчеләр аркылы хәбәр җибәрәләр. Менә аның эчтәлеге: «...к Шигалею и воеводам бити челом, чтобы государь (Иван IV — *Д.И.*) пожаловал, гнев свой им отдал, а пленити не велел, а дал бы им на государство царя Шигалея, Утемыш-Гирея государь к собе взял с материю Сююмбика-царицей». Бу тәкъдимне алып килүчеләр икәү була: «мулла» Кол Шәриф һәм кенәз Бибарс Растов. Әйтелгән тәкъдимнең «бөтен Казан җире» исеменнән булганлыгын рус елъязмалары бик ачык раслый. Шуны да онытмаска кирәк: Казаннан килгән илчеләр Мәскәүнең шартларын шунда ук кабул итмәгәннәр, алай гына да түгел, аларга каршы торырга тырышканнар. Шуңа күрә дә рус елъязмаларында 1551 елның 9 августы белән бирелгән хәбәрдә татар илчеләре турында әйтелә: «во многом заперлися». Димәк, алар Мәскәү таләпләрен кабул итмәгәннәр. Хәтта, рус елъязмачысы бу турыда язганда өстәп тә куя: «...обычай бо их бяше изначала лукавьствовати». Аңлашылганча, татар ягы үз мәнфәгатьләрен якларга тырышкан. Әмма, мәскәүлеләр бу юлы көч куллану белән яныйлар һәм казанлыларга әйтәләр: «не учинятъ на государеве воле... На ту же осень ... государь (Иван IV — *Д.И.*)... хочет ратию со всеми людьми». Шушы турыдан-туры янау һәм басымнан соң гына Казан илчеләре Мәскәү таләпләрен кабул итәргә мәҗбүр булалар. Ул таләпләрнең иң әһәмиятлесе, инде әйтелгәнчә, Сөембикәне һәм аны улы Үтәмешгәрәйне мәскәүлеләргә бирү була. Аңлашыла ки, шушы таләпләрне кабул итәргә мәҗбүр булган ике татар илчесе — Кол Шәриф һәм Бибарс бәк бу очракта бары тик дипломатлар буларак кына хәрәкәт иткәннәр, ягъни Сөембикәне һәм Үтәмешгәрәйне Казанда калдыру аларга гына бәйле булмаган. Шуңа күрә дә бу вакыйгаларга мөнәсәбәтле Кол Шәрифтән генә аерым рәвештә гаеп эзләү дөрес булмас иде. Чынлап та, 1551 елның 14 августында руслар белән килгән Шаһ Гали каршында казанлылар Мәскәү ягының бөтен шартларын үтәү турында килеп баш игәндә көч кем ягында икәнлеге бик ачык күренә. Рус елъязмасында бу турыда түбәндәге хәбәр бар: «...Приехали к царю (Шаһгали янына — *Д.И.*) и боярам Кулшериф молна и Маамет сеит Мансыр сеитов сын (Казан ханлыгының бөек сәеде — *Д.И.*), и все с ним шихы и шихзаде, имамы и молозаде и азии, и дербыши, да Кудайгул-улан, а с ним уланы все, да Муралей князь (Ширин нәселеннән булган бәкләр-бәге Нургали бәк — *Д.И.*), а ним многие князи и мурзы». Күренә ки, монда Казан ханлыгының барлык югары катламы турында сүз бара. Менә шушы хөкем итүче дәүләтнең элитасы мәскәүлеләргә үзләренең хөкемдарларын бирергә мәҗбүр ителәләр. Ягъни Сөембикәне һәм аның улын мәскәүлеләргә биреп җибәрүдә шушы бер төркем татар элитасы гаепле булган. Ә монда аерым шәхеснең бөтенләй җаваплылыгы юк дип әйтә алабызмы? Җаваплылык күпмедер дәрәҗәдә бар! Бик бар! Әмма аныкы гына түгел... Кол Шәрифнең фаҗигасе дә шунда. Ул азаккача аяусыз көрәшеп шәһит китә... Тарих, хәтер безгә сабак алыр өчен дә бит...

КАЗАН ХАНЛЫГЫ ЧОРЫ – МИЛЛИ ӘДӘБИЯТ ДӘВЕРЕНӘ КАПКА

(XV йөзнең икенче яртысы — XVI йөзнең беренче яртысы)

ДАНИЯ ЗАҺИДУЛЛИНА,
филология фәннәре докторы

Казан ханлыгы чоры әдәбияты төрки телле әдәбиятлар үсешенең ике зур этабы арасында тора һәм классик төрки телле әдәбият тарихында милли әдәбият дәверен башлап җибәрә. Тарихчы галим Равил Әмирханов шундый фикердә тора. Чыннан да, бу чорда соңрак татар әдәбиятында традициягә әйләнәчәк үзенчәлекләр формалаша. Шуларны берничә мисалда карап үтик.

Чор әдәбияты — суфичыл әдәбият. Нәкъ менә Казан ханлыгы чорында татар суфи әдәбияты хасил була, аның үзенчәлекләре күренә башлый. Әйтик, күренекле шагыйрь, сәет һәм дипломат Кол Шәрифнең һәр шигыре суфиның Аллага якынаю юлын сурәтли. Менә «Әлхәмдүлиллаһ рабби ил-галәми...» («Җиһанны бар итүче Раббега мактау...») шигыре. Ул тәүбә мәкамендә Аллаһ белән сөйләшү кебек иҗат ителгән. Лирик герой Аллага мөрәҗәгать итә, аны дин һәм иман, изге китап өчен, мөселман булып туган

өчен, Мөхәммәдне җиргә җибәргән һәм Кыямәт көне киләсен аңлаткан өчен зурлый, үзен җитәрлек рәвештә аңа багышламаганлыгына үкенә һәм тәүбә итә. Шагыйрь, әйтерсең лә, тәүбә процессын күзәтеп бара. Тәүбә догасы берничә үтенечне үз эченә сыйдыра: «нәфесебезне дошман ясама»; «гөнаһларыбызны кичер»; «кирәк булса, Үзеңнән ку»; «кирәк булса, Үзең каршы ал»; «өметебез өзелмәсен». Охшаш мотивлар башка суфи шагыйрьләр иҗатында XIX гасырның ахырына кадәр килеп җитә. Тәүбә мотивы, зикер кебек үк, суфи поэзиядә иң киң таралганнардан санала. Соңрак алар Мәүла Колый, Шәмсетдин Зәки, Һибәтулла Салихов һ.б. бик күп шагыйрьләр тарафыннан кат-кат шигырь түренә менгерә.

Суфи әдәбиятта үзенә җәлеп иткән сәерлекләр, ачыласы серләр бар. Мәсәлән, урта гасырлар татар суфи шигъриятен дөньяга танылган фарсы суфи әдәбияты белән чагыштырсак, төрки поэзиянең гади, төссез стильдә язылуы күзгә ташлана. Шигырьләр көйле, музыкаль булсалар да, алар образ-бизәкләргә, символларга бай түгел. Ләкин арада бик сирәк кенә башка төрле, нәфис, катлауландырылган стильдә язылган шигырьләр дә очрый. Шундыйларның берсе — Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьярның «Нәсыйхәт» шигыре.

Казан ханлыгы чоры әдәбиятының күренекле вәкиле Мөхәммәдьяр (1497 ел тирәсе — 1552) үзеннән соң ике зур әсәр — «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге», 1540) һәм «Нуры содур» («Күңелләр нуры», 1542) поэмаларын калдыра. Аларда әсәрләрнең язылу вакыты һәм урыны (Казан) күрсәтелгән, автор хакында берникадәр мәгълүмат китерелә: Мәхмүд хаҗи улы булуы, иҗат эше белән шөгыльләнеп, күп җәфалар чигүе, икенче поэманы Мөхәммәд-Әмин хан төрбәсе янында, мохтаҗлыкта төгәлләве шундыйлардан. Ләкин авторның «Нәсыйхәт» шигыре үзенең язылу рәвеше белән бу поэмалардан да, чор әдәбиятындагы башка әсәрләрдән дә аерылып тора.

«Нәсыйхәт» — символлар ярдәмендә катлауландырылган, укыган саен яңа эчтәлеккә юл күрсәтә торган әсәр. Ул күпкырлы бриллиант кебек — һәр укылыш мәгънәгә яңа төсмерләр өсти. Шигырь үзе ике: шартлы-символик һәм үгет-нәсыйхәт өлешләренә бүленә.

Әсәрдә шартлы-символик дөнья сурәте традицион парлы суфи символлар гөл-былбыл һәм җир тормышын белдереп килгән баг, бакча, тикән (тигәнәк, кешедәге тискәре сыйфатларны белдерә) символлары аша тергезелә. Парлы гөл-былбыл символы Илаһины һәм аңа гашыйк кешене аңлата. Мөхәммәдьяр әсәрендәге былбыл яки гамил (егет) бакчада тигәнәк үскәнгә борчыла. Ләкин беркөнне гөлне күрә, аңа гашыйк була һәм сорый: бакчада тигәнәк нигә кирәк? Шулай автор тормышта тигәнәк, ягъни явызлык күп дип белдерә, бакча хуҗасының шул кайгыдан чәчләре агарган. Димәк, дөнья бөтенләй башка нигезгә — явызлыкны (тигәнәкне) кирәк тапмый торган, Аллаһка мәхәббәт нигезенә корылырга тиеш. Әлеге фикер символларга яшерелгән, шартлы-символик өлеш шуны укырга ишарә ясый: *«Белек әһле бу рәмзе бәлкә аңлар, / Колак салмас кә бу мәгънәйә әгъйар»*, ягъни «белүчеләр минем шигыремне аңлар, башкалар әһәмият бирми узар».

Үгет-нәсыйхәт өлешендә лирик герой кешеләргә мөрәҗәгать итә, явыз булмаска (*«Гөле сач ул багыңа, булма җаһил»*) өнди. Әгәр һәр кеше гашыйклык юлына чыкса, яхшылык кына кылып, «гөл» өчен яшәсә, җир «гөлстан»га әверелер иде дип белдерә.

Икенче мөрәҗәгать — «дөрес яшә», хакыйкатькә таянып яшә, шул вакытта сиңа шайтан явызлык кыла алмас. Шулай шагыйрь, тормышны явызлыктан арындыру өчен, кешене камилләштерү кирәклеген билгели.

Шигырьнең соңгы юллары шартлы-символик һәм үгет-нәсыйхәт өлешләрен тоташтыра, монда лирик герой үз сагышының сәбәбен күрсәтә: *«Дәригъ улды бу дөньяның зийасы, / Хәйасыз улды мөәмин, йук вәфасы».* Ягъни «дөньяның нуры югалды, чөнки мөселманнар яшәеш гаме белән янудан туктады». Шул рәвешчә, шагыйрь үзе яшәгән чорга, кешеләргә бәя бирә, аларны дөрес, Илаһига йөз тотып яшәргә чакыра. Бу хакта турыдан-туры үгет биреп тә, шартлы рәвештә символларга яшереп тә сөйли. Алга таба символларга яшереп, үзгә эчтәлек бирү татар әдәбиятының күркәм сыйфатына әйләнә.

Казан ханлыгы чоры әдәбиятында формалашкан һәм аннары милли әдәбиятта әһәмиятле урын яулаган тагын бер үзенчәлек — шигърияттә татарларга якын булган шәһәрләрнең сурәтен, истәлеген тергезү. Аны башлап җибәрүчеләрнең берсе Казан ханы Мөхәммәд Әмин (1487-1496, 1502-1518 елларны тәхеттә утыра) була. Шагыйрь-ханның иҗатыннан бары бер шигырь сакланып калган. «Гыйкаб» («Үч») дигән бу шигырь Аксак Тимернең Болгарны җимерүен искә төшерә. Автор аны «ислам йортын» җимергәне, мөселманнарны үтерүе, фетнә китерүе өчен гаепли, Алладан аңа җәза сорый. Шулай итеп, ул татар халкының хәтеренә бабалары яшәгән Болгар исемле гүзәл һәм изге шәһәр истәлеген уючылардан була.

Тагын бер шигырь — Шәрифинең «Зафәрнамә-и вилаяте Казан» («Казан иленең җиңүе», 1550) әсәре исә Казан образын күз алдына бастыра. Тарихи-публицистик характердагы бу шигырьдә 1550 елның февраль вакыйгалары, казанлыларның Иван IV һөҗүмен кире кайтаруы сурәтләнә. Автор Казанны Болгарның дәвамчысы һәм башкаласы дип атый. Татар шагыйрьләре арасында беренчеләрдән булып, җентекләп шәһәрне, аның матурлыгын, архитектура үзенчәлекләрен күрсәтеп бара. Безнең телгә җайлаштырылган өзек китерик:

Гаҗәп! Җиһанның иң күңелле урыны
бу Казан шәһәре,
Дөньяда юк мондый урын,
иминлек шәһре,
Казан төсле чәчәк атучы шәһәр
һич булмас,
Казанда һәр кеше аш-су табар.
Шундый ул галәм шәһәре Казан.
Хан бабалардан безгә калган
безнең дәүләт,
Хан учагының үзәге.

Мөхәммәдьяр исә Казанны шагыйрьләр шәһәре дип атый:

Бер гаҗиб бу шәһәрнең эче тулуг,
Шагыйрь улмыш барча кечек вә олуг.

Шулай итеп, Казан ханлыгының талант ияләре иҗатыннан сакланып калган азсанлы җәүһәрләр безгә бу чорда милли әдәбият формалашу, аның үзенчәлекләре, хәтта соңрак традициягә әйләнәчәк кайбер сыйфатлары хакында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Кешелеклелеккә һәм галәми гамьнәр белән яшәргә чакыручы шагыйрьләрнең әсәрләре аларның зәвыклы, укымышлы, әхлак һәм милли хәтер төшенчәләрен мөһим санаган шәхесләр булуы хакында сөйли.

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ,
ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ

(13.10.1946 — 26.11.2006)

СИНЕҢ КУЛДА КАЛӘМ...

Үзең!
Үз теләгең белән
Үз тамагыңны киртләгән –
Тукталып калмаска тиеш
Халкың тапшырган каләм!

Үз сукмагың!
Үзең салдың,
Беркем көчләп кертмәгән.
Карасы бетсә, каның бар –
Халкың тапшырган каләм!

Ата-бабаң беркайчан да
Уракка кичекмәгән.
Син дә кырда. Синең кулда
Халкың тапшырган каләм.

Җырны чикләмәгән вакыт,
Ә гомерне чикләгән...
Рәнҗеп туктамасын
Сиңа
Халкың тапшырган каләм!

*Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовның кайбер сүз энҗеләрен журнал битләреннән чүпли аласыз.

ИСЛАХ ДӘВЕРЕ МИРАСЫННАН

ХАКЫЙКАТЬ

ГАБДУЛЛА БУБИ

Бисмилләһиррахмәниррахим
Беренче җөз'е (кисәк)
Хакыйкать
яхуд
ТУГРЫЛЫК
Наширләре:
Галиәсгар Камаледдинов вә шөрәкәсе
Дозволено цензурою. С.-Петербургъ,
9 Іюня 1904 г.
КАЗАНЬ
ГОРОДСКОЙ ПАССАЖЪ
Лито-Типографія И.Н.Харитонова
1904

(Дәвамы. Башы журналның 5-6 саннарында)

Бисмилләһиррахмәниррахим.

Инде исти'зан аятенә яңадан кайтыйк. Аннан иң элек йокыга ястүдән соң ятып, таңнан элек тору вә өйлә алдыннан, тәгамнән бер-ике сәгатьтән соң ятып алу аңлашыладыр. Һәм сәламәтлек саклау китапларында бәян кылынганча, йокыны ошбу рәвешчә кылу тиеш вә адәмнәргә бик файдалыдыр. Бәс, кайбер адәмнәрнең төне буенча театрда-фәләндә йөреп, көне буенча йоклаулары төнне көн вә көнне төн кылып, яратылыш кануны вә кешенең табигатенә вә моннан хәбәр биргән [Вә җәгәлнәнәл ләйлә либәәсә, вә җәгәлнән нәһәрә мәгәәшә] (Төнне — (йокы өчен) өртү, көндезне көн күрү, ризык табу өчен (хезмәт итү вакыты) итеп бар кылдык, Нәбә, 10-11) аятенә каршы вә сәламәтлеккә бик зарарлыдыр. Ягъни [Аллаһы Тәгалә сезгә кичне гаурәтне өртүче кием кебек качкан дошманларыгыздан пәрдә вә йоклый торган караңгы бүлмә, вә көндезне хаҗәт вә кәсепләрегезне карый торган, мәгыйшәткә [тормыш көтү] муафыйк бер вакыт кылды]...

Исти'зан аятеннән аңлашылган нәрсәләрнең икенчесе [Аллаһ үзенең аятьләрен шушы сурәттә ачыклыйдыр] Аллаһы Тәгаләнең һәрбер хөкемен безнең гомуми файдабыз өчен кушуыдыр. Чыннан да, Аллаһы Тәгалә Галим вә Хәким булганлыктан, һичбер эшне файдасыз, хикмәтсез кушмас. Вә бернигә дә мохтаҗ булмаганлык-

тан, Үз файдасы өчен дә әмер кылмас. Шуңа күрә әмер вә тыюдан максат безнең файдабызга булган бернәрсә булса кирәк. Дөрестән дә, Аллаһы Тәгаләнең колларына шәфкате атаның баласына шәфкатеннән артыграк булганлыктан, һичкемгә бер зарар килүенә разый түгелдер. Шуның өчен дә шәригате Исламия файдасы күп булганны важиб [тиешле], аз булганны мөстәхәб [яхшы] вә зарары күп булганны хәрәм, аз булганны мәкруһ [кискен тыелмаган], вә файдасы да, зарары да булмаганны мөбах [тыелмаган] әйләгәндер. Бинаән галәйһи [шуның өчен] нәсехтә дә бер хикмәт булырга кирәк. Иштә [шулай булгач], бән дә бу рисаләдә [җыентыкта] мәнсух [хөкеме бетерелгән] булган аятьләрнең хикмәтләре хакында язмакчымын. Бәс, моннан аңлашылды ки, безнең кайбер иске голәмәбезең вөҗүб [мәҗбүри тиешлелек] безгә зарар булганлыктан, безнең файдабызга булган җомга намазыннан калган эшләргә кире кайту кебек нәрсәләрнең һичбере важиб [тиеш] булмас дидекләре шәригатебезгә яла ягу, бик бөек бер кабахәттер. Инде моннан аңлашылды ки, Аллаһы Тәгаләнең һәрбер хөкеме теләсә әмер, теләсә тыю булсын, берәр сәбәпкә таяна. Ошбу исти'зан аятендә дә керү дөрес түгеллекне [сезнең өчен өч мәхрәм] (шәхси, аулак, вакыт) вә керү дөреслекне [бер-берегез белән керешеп, аралашып торасыз] илә сәбәбен күрсәтеп китергән. Ләкин шул кадәресе бар: кайберләрендә сәбәп искә алынса да, күбесендә телгә алынмый. Менә ошбу сәбәбе китерелмәгән хөкемнәрдәге хикмәтләрне чыгару вә каршы килүчеләргә күрсәтү һәрбер мөселман адәмнең вазифасыдыр.

Инде Имам Сөйутыйның борынгы галимнәргә каршы чыгып, хөкеме бетерелгән аятьләр исемлегеннән сызган кыйсмәт [мирас бүлү] аятенә карата әйткән сүзен китерик. Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре дигән [әгәр мирас булып калган малны бүлешкән вакытта варис булмаган якын кардәшләр, ятимнәр вә мескеннәр янда булсалар, аларга да мирас малыннан ризыкланыр кадәре инфак кылыгыз (өлеш чыгарыгыз) вә моның өстенә начар сүз әйтеп, миннәт [кылган игелек өчен нидер өмет итү] кылып, хәтерләрен калдырмагыз. Бәлки: «Алыгыз, Аллаһ мөбарәк кылсын, күп бирә алмадык», — дип, күңелләрен хуш кылып җибәрегез. Тәфсире Кәшшаф әфәндебез галәйһиссәлам соңында да бу аять илә гамәлне әсхаб кирамнан [хөрмәтле сәхабәләр] риваять кылган. Чыннан да, бу хөкем дә гамәл кылырга бик тиешле булган бер хөкемдер. Чөнки көтелмәгән җирдән, кәсепсез-фәләнсез Аллаһы Тәгалә тарафыннан колына бирелгән малның шөкерен варисның үтәве мөмкин түгел, мәгәр ошбу адәмнәргә инфак белән генә. Бәс, бу заманда әлеге аятьнең хөкеме илә гамәл кылынмавына карап, аны мәнсух димәк исти'зан аятендә сөйләнгән кебек артык кыю әйтелгән фикер. Ләкин шунда эш бар: бу аятьтәге әмер вөҗүбнеме, нәдебнеме [эшнең хупланган гамәл икәнлегенме] аңлата? Кайберәүләр сүзенә караганда, бу инфак важиб [хәер юлында сәдака бирү] түгел. Әгәр важиб булса иде, башка важибләр кебек, я Коръәндә, я хәдистә микъдары бәян кылыныр иде. Хәлбуки, Коръәндә дә, хәдистә дә, хәтта әсхаб вә мөҗтәһидин [Коръәннән мөстәкыйль хөкем чыгаручылар] дин галимнәренең сүзендә дә бу инфакның микъдары бәян кылынмаган. Бәс, бу инфак мөстәхәб [куллана торган] булырга кирәк. Ләкин ихтималдан [ул малдан ризыкландырыгыз] иң киме бер ашар кадәре булуы аңлашылганга, микъдары бәян кылынмаган булыр. Әмма бу хөкемнең хикмәтенә карап, көтелмәгән җирдән кергән малдан бер микъдарын халык-

ка бүлеп бирү вә үзе сөйгәнне мөселман кардәшенә сөймәк өчен важиб [тиеш] булу ихтималы бик зур. Чыннан да, малны табарга вә җыярга иҗтиһад кылырга кирәк, милләт файдасына сарыф өчен. Мал булганлык өчен түгел. Малны мал булганлык өчен сөю шәригать һәм гакыл ягыннан иң кабахәт вә бик ямьсез булган бер нәрсәдер. Шәригать күзлегеннән яхшы түгел, анысы мәгълүм. Гакыл күзлегеннән яхшы түгел, чөнки малны мал булганлык өчен сөйгән адәм мал табу өчен һичбер хәрәмнән, фәкыйрьләргә золым вә хыянәттән, хәтта урлашу яки урлаганны җыюдан да чирканмас. Бер адәмгә бер тиен бирмәс, бирә башласа җаны чыгар. Салам өстендәге эт кеби үзе дә ашамас, кешегә дә ашатмас, Карун исемен алыр. Һәркем дошман тотар, «йөзе кара, бәласен күрсен» дип, дога кылыр. Мал саклап, бетмәсәм генә ярар иде дип куркып, мең бәла вә хәсрәттә гомере узар. Хәтта ахыр гомерендә дә малы күзендә булып, һичбер хайратка [хәерле эшкә] васыять итә алмаенча, мең бәла белән малыннан аерылып, җәһәннәмгә китәр. Моннан өч ел элек мин белә торган бик саран вә малны мал булган өчен сөя торган бер бай адәм хаҗга киткән иде. Моны юлда әҗәл якалаган, янында күп акчасы бар икән. Иптәш хаҗилары изге юлга васыять ит дип өнди башлаганнар. Бик озак инкарь кылып маташса да, иптәшләренең кыставына чыдый алмаган, 25 тәңкә тәгаен кылган. Иптәшләре моны бик азсынганнар: «Барыбер акчаң үзеңнән кала, кыямәттә файдасы тияр, изгелеккә күбрәк куй», — дип тагын кыстый башлагачтын, — «инде артыгы булмас, зинһар, кыстамагыз», — дип җан биргән. Менә бу вакыйга малны Аллаһ өчен сөймәгән адәмнәргә бик бөек бер гыйбрәттер. Әмма малны Аллаһ өчен сөйгән адәм тапкан малыннан милләте юлында сарыф кылыр. Һәрбер адәмнең яхшы карашын казаныр, вөҗданы рәхәтләнер. Аллаһка тәвәккәле тәмам булганлыктан, кәсебендә иҗтиһад вә Аллаһ өчен сарыфында дәвам кылыр. Малым бетәр дип курыкмас. Бу адәм акчасын түгел, бәлки акчасы моны каравыллар. Шушылай рәхәт яшәп, һәрбер яхшы кешенең догасын алып, мәхәббәтен казанып, шатлык илә дөньядан күчәр. Вә җаны тәнендә чагында яздырган васыятьләре вафатыннан калыр. Иштә [шулай булгач], иң сәгадәтле үлем дә ошбу үлемдер. Бәс, һәрбер байлыгы булган адәмгә сихәте яхшы, форсаты кулында вакыт барачак җире Аллаһ хозуры икәнлеген белеп вә исәпләп, шуңа күрә эш йөртергә кирәк. Менә мәрхүм Хөсәенов Гани байдан гыйбрәт алыгыз, Аллаһның рәхмәтендә булсын. Бик яхшы вә милләт файдасына вә дин юлына сарыфы бик күп иде. Вә бөек васыятьләр яздырырга исәбе һәм бик бар иде. Ләкин сихәте бик камил булганлыктан, алай кисәктән генә үләрен бер дә күңеленә китермәс иде. Мескен мәрхүм исәпләгән васыятьне язып гамәлгә ашыра алмады. Гафил [надан] икән, әҗәл авына төшеп, үлем тырнагы астында бу дөньядан китте. Шушылай бик бөек изгелектән мәхрүм буларак ахирәткә сәфәр кылды. Дөрес, мәрхүм Аллаһның рәхмәтендә булсын, башка мәдрәсә карау, мөгаллимнәр тәрбияләү кеби хайраты [хәерле гамәле] да күп иде, ләкин бу васыять хосусын [асылын] гамәлгә ашыра алса, башка төсле бер эш булыр иде. Бәс, мәрхүмнең рухы шөбһәсез әйтә торгандыр: «Кәшки [эх], форсат вакытымда мәңге киселмәячәк вә мөселманнарга күп файда китерәчәк, вә һәркемнең мәхәббәтен үземә җәлеп итәчәк, вә Аллаһы Тәгалә хозурында тагын да йөземне агартачак бөек васыятьләр яздырсамчы», — дип. Ләкин ахирәткә баргач, кайтмак

юк. Вә калган варисларның үлгән адәм өчен кайгыру формасы дәхи юк. Иштә, бу вакыйга да һәрбер байлыгы булган адәмгә бик бөек бер дәрес гыйбрәттер. Әхмәд байның күзен ачкан вә алдындагы пәрдәләрне ерткан ошбу үкенечле вакыйга булды, Аллаһ күрсәтмәсен. Әгәр һәрбер мөселманны хәсрәтләндергән бу вакыйга килеп чыкмаса иде, ихтимал, милләт хадиме Әхмәд бай да васыять язуыны озакка сузып, эш булмас борын мәрхүм Гани бай кеби кисәктән әҗәл тырнагына эләгер вә кулы буш, вә бик хәсрәт илә миллионнарча мөселманнарны елатып, бу дөньядан сәфәр кылыр иде. Бәс, һәрбер байлыгы булган адәмгә кирәкле нәрсә сау-сәламәт чакта форсатны ганимәт [кадерен] белеп, хайратка [хәерле гамәлләргә] сарыф планнарын ясау вә мөмкин кадәре күбрәк итеп васыять язудыр. Дөрес, балаларына да сумма куярга кирәк, ләкин 100 мең суммалы кешегә балаларына 70 мең куеп, 30 меңне хайратка васыять итсә, дөресрәге үзе илә бергә Аллаһ хозурына алып китсә, балалары өчен дә җитәрлек вә үзе өчен дә бик яхшыдыр. Һәркем Аллаһ хозурына алып барачак игелекле гамәлләрен үз кулы илә үзе хәзерләргә тиеш. Үлгәчтен, балаларым минем өчен кайгырырлар дип күңелгә китерергә ярамый. Һичбер байның баласы атасы соңында аның рухына дип зур игелек эшләгәне юк. Васыять яздырудан куркырга ярамый. Васыять яздырган дип, вакыты җитмәенчә әҗәл килеп тотмас. Васыятькә яздырган мал үзең үлмәенчә кулыңнан китмәс. Ул акчаны теләгән рәвешле куллану үлгәнче ярый. Бәс, васыять язуның бер дә курка торган җире юк. Кайсы төшеннән куркасың? Торганы үзеңә файда, дөньяда малың кулыңда тора, ахирәттә дә алдыңда була. Шуның өчен дә Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре изгеләр бәндәләрне мактар [вә мим мә разәкънәәһүм йүңфикуун] дип сыйфатлаган. Ягъни «салихлар шулардыр ки, алар без биргән малдан Аллаһ юлында инфак кылырлар». Мәзкүр Әбүл Касыйм бу аятьне дә зәкят илә мәнсух дигән. Хәлбуки, моның мәнсух булуына һичбер сәбәп юк. Әгәр инфак важиб булган зәкятка кайтарып калдырылса, бик заһир [ачык] зәкят аяте бу аятьне ныгытып, куәтләп килә. Әгәр нафилә [өстәмә] буларак каралса яки гомум контекстан аңлашылган важиб зәкят илә нафиләләрдән гомумирәк булган инфак булып аңлашылса, ул вакытта мәнсух түгел. Чөнки бу аять мактауны белдерә торган хәбәр булып килгәнлектән, ни важибне, ни башка хөкемне һичберене аңлатмыйдыр. Бәлки бары Аллаһ юлында инфакның бик яхшы бер эш икәнлегене аңлатадыр. Бу инфак бу заманда да бик яхшы эш, бәс, аять зәкят илә ничек мәнсух булсын?! Шуңа күрә Имам Сөйутый да бу аятьне хөкеме бетерелгән аятьләр җөмләсеннән төшереп калдырган. Инде Имам Сөйутый хәзрәтләренең, борынгыларга каршы килеп, аларның 225 дигән мәнсух аятьләрне 25кә калдыруы дөрес булгачтын, безнең дә Имам Сөйутыйга каршы килеп, ул да мәнсух дип санаган кайбер аятьләрне мөхкәмат [хөкеме үз көчендә калган аятьләр] җөмләсенә кертергә ярарга кирәк. Чөнки нәсхендә [үзгәртүләрдә] бер хикмәт күренеп тормаган аятьләрне мәнсухаттан санауның зарары бик күп, хәтта чит дин руханиларыннан кайберләре шул 225 аять илә безгә бәхәс кылып та маташалар вә әйтәләр: «Сезнең Коръәндә 225 аятьнең хөкемнәрен үзгәртеп, яңа хөкем куйган, хәлбуки, бер хөкемне бер тапкыр кушып, яңадан үзгәртмәк наданлык күрсәткече ки, Аллаһы Тәгаләдә булуы мөмкин түгел. Бәс, сезнең Коръәнегез Аллаһы Тәгалә тарафыннан булмаса кирәк». Иштә, мине бу рисаләне

язарга мәҗбүр кылган нәрсә дә бу ошбу бәхәстер. Мин бу бәхәсне күргәчтен, насих-мәнсух [хөкеме бетерелгән] китапларын карадым вә төрле ышанычлы тәфсирләргә кайтып, мәнсух саналган аятьләрнең тәфсирләрен вә иңү сәбәпләрен карадым. Имам Сөйутый әйткәнчә, бу аятьләрдән 225-не мәнсух түгел, хәтта Имам Сөйутыйның мәнсух санаган 20 аятьтән дә кайберләрен мөхкәм [төгәл] дип таптым вә мәнсух булганнарының һәммәсендә бер сәбәп вә хикмәт күрдем. Иштә, мин бу рисаләдә ошбу 20 аятьне тикшерәчәкмен. Вә мәнсухларын гайре мәнсухларыннан аерачакмын. Вә мәнсух булганнарының хикмәтләрен берәм-берәм тәфсил кылачакмын. Бәс, мәзкүр бәхәсне китергәннәргә әйтәбез: сез хаталанасыз, Коръәндә бу кадәр мәнсух юк. Дөрес, кайбер галим исемен йөртүчеләр 225 мәнсух санаганнар, ләкин белеп түгел, белмәенчә санаганнар. Болар мәнсух аятьләрне җыярга теләгәннәр дә, көчләре җиткән кадәр мәнсух табарга тырышканнар. Хәтта югарыда телгә алынган истисналарны [чыгарма] да мәнсух аятьләр җөмләсенә кертеп бетергәннәр. Әмма чынлап караганда Коръәндә мәнсух аятьләр бик аз. Вә мәнсух булганнарының һәммәсендә бер сәбәп вә хикмәт бардыр ки, аларны нәсех кылу җәһаләт [наданлык] түгел, киресенчә, нәсех кылмаса, җәһаләт булыр иде. Сез нәсехне җәһаләт дип әйтәсез, хәлбуки, Адәм галәйһиссәлам шәригатендә бер корсактагы ир икенче корсактагы кыз кардәшен никахланыр иде. Вә хәзрәте Хаува һәрбер корсакта бере ир, икенчесе кыз ике бала табар иде. Үз кардәшен никахлану сәламәтлек ягыннан зарарлы булуы мәгълүм. Моны хайван асраган адәмнәрдән дә белергә мөмкин. Алар, колын яки бия зарарлана дип, һичбер вакытта биянең үз колынын үзенә чаптырмаслар. Ике җенестән ике агуны бергә катыштырган вакытта кайчак адәм өчен бик файдалы бер эш булып киткән кеби ике нәселдән ике авыруның никахланып катышуларыннан да бик таза бер бала вә үзләренә сәламәтлек хасил булса да булыр. Минем бик күп ишеткәнем бар, әйтәләр: «Фәлән кыз кыз вакытында бик чирле, бик начар иде. Иргә бару килеште, тазарып китте», — диләр. Әмма бер җенестән ике агуны берсен икенчесенә кушуда агудан башкасы хасил булмаган кебек, бер нәселдән ике вәрәмнең [авыру] берен икенчесенә кушу да авырудан башка нәтиҗә бирмәс. Шуңа күрә кардәшне кардәшенә никах хәрәм булмак кирәк. Ләкин Адәм галәйһиссәлам заманында икенче нәселдән адәм юк иде. Әгәр кардәшне кардәшенә никах рөхсәт ителмәсә, хәзрәте Адәмнең нәселе киселгән булыр иде. Бәс, Адәм нәселен дәвам итү зарурәте өчен Аллаһы Тәгалә бу никахны хәләл кылды. Шулай булса да, мөмкин кадәре аерды. Бер карында булган ирне шул карындагы кызга хәләл кылмады. Әмма соңра бәни Адәм күбәйде. Нәселләр аерылды да бу зарарлы никахка хаҗәт калмады. Бер нәсел икенче нәселдән алу мөмкин булып китте. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре дә бу никахлануны Тәүратта хәрәм кылды. Бу никахны башта бер хикмәт өчен дөрес күреп, соңра башка бер хикмәт өчен хәрәм кылуыннан Аллаһы Тәгаләнең белемсезлеге түгел, бәлки камил гыйлем вә хикмәте аңлашылган кеби, безнең Коръәндәге нәсехләрдән дә [менә сөйләп күрсәтербез] Аллаһы Тәгаләнең камил гыйлем вә хикмәте аңлашыладыр. Тәүрат буенча хыйтан [сөннәткә утырту] тиеш вә дуңгыз хәрәм, вә талак рөхсәт ителгән, вә нәҗасәтләр [шакшы нәрсәләр] һәммәсе тыелган иде. Хаварийййун [апостоллар] үз гөманнарынча бу хөкемнәрне мәслихәт түгел дип, сөннәткә

утырту белән талакны тыеп, дуңгыз вә шакшы нәрсәләрнехәләл кылдылар. Ләкин боларның бу нәсехләрендәге хикмәтләр безгә бер дә мәгълүм түгел (!...) Бер падишаһ бер мәслихәт өчен бер шәһәрдә идарә яки яулап алынган җирдә бертөрле хөкем урнаштырып, соңра ул мәслихәт хасил булганлык вә ул җир ныгып җиткәнлектән, әүвәлге хөкемне гамәлдән төшергән кеби, Аллаһы Тәгалә дә һәрбер заманда ул заманга муафыйк хөкем кушадыр. Аллаһы Тәгаләнең гыйлем вә хикмәтенә мөхалиф [каршы] болай кылу түгел, киресенчә, алай кылмаудыр. Бу әүвәлге хөкем безнең карашка мотлак булганга үзгәртү төсле күренсә дә, Аллаһы Тәгаләнең гыйлемендә фәлән заманга кадәр дип чикләнгән булганлыктан, үзгәртү-алыштыру вә җәһел-фәлән [надан-лык] аслан лязем [тиеш] түгел. Бер падишаһ бер адәмне хезмәткә алса вә хезмәт мөддәтен [вакытын] үзе генә белеп, хезмәт итүчегә әйтмәсә, шул мөддәт җиткәчтен, хадимне хезмәтеннән җибәрү, мөддәтне белмәгән вә әбәди [мәңге] дип уйлаган хезмәтчегә нисбәтән алыштыру төсле күренсә дә, чынлыкта исә алыштыру түгел, бәлки падишаһ билгеләгән мөддәтне бәян итү булган кебек, безнең карашка мотлак вә Аллаһы Тәгаләнең гыйлемендә фәлән вакытка кадәр чикләнгән шәригать хөкемен нәсех кылу да үзгәртү түгел, бәлки Аллаһ гыйлемендә булган мөддәтне бәян буладыр. Ләкин нәсех шәригатьтә бар, диндә юк. Шәригать намаз, рузә вә хокукка кагылышлы җәзалар — хөкемнәрдән, дин исә Аллаһның барлыгын вә берлеген, вә кыямәтне, вә боларга охшаш нәрсәләргә иман китерүдән гыйбарәттер. Иман мәсьәләләре рациональ дәлилләр белән дәлилләнгән вә акылга ятмаган һәрнәрсә ялгыш булганлыктан, һичбер вакыт аңа нәсех килмәс. Шуның өчен дә Аллаһы Тәгалә тарафыннан һәрбер пәйгамбәргә җибәрелгән игътикад [инану] бертөследер. Адәм вә Нух, вә Муса, вә Гайсә галәйһиссәламгә иңгән игътикад барыбер безнең Әфәндебез салләллаһү галәйһи вәсәлләмгә иңгәннән [Куль һүәллаһү әхәд. Аллаһүс самәд. Ләм йәлид вә ләм йүүләд. Вә ләкүн ләһү күфүввән әхәд, Ихлас, 1-4] гыйбарәт иде. Корәешләр Әфәндебез галәйһиссәламнән: «Син безне дәгъват кылган Раббыны безгә сыйфатлап күрсәт», — дигәндә, Аллаһы Тәгалә бу аятьләрне җибәрде. Ягъни [Әйт Син, әй Мөхәммәд! Мин сезне дәгъват кылган Аллаһ сез белгән вә җирләрне, күкләрне Халикъ дип икърар кылган Аллаһтыр. Бу кадәр тәртип белән яраткан Зат, табигый, Галим вә Кадир, вә Хәй, вә Сәмигъ, вә Басыйр, вә Мөтәкәллимдер. Бу Аллаһның Затында вә сыйфатында шәриге юктыр. Дәхи Самәддер, ягъни Ул гына мохтаҗун иләйһи [бернигә дә мохтаҗ түгел], Аннан башка мохтаҗун иләйһи юктыр. Бәс, Үзе бернигә дә мохтаҗ түгелдер. Шуңа күрә һичбер вакыт хикмәтсез эшне кылмас. Һичбер нәрсәне тудырмады, чөнки бала кирәк атасына ярдәм вә аңа хәләф өчен. Ганийи бизатиһи булган Зат ата-анага мохтаҗ дәхи булмас. Һәм дә Аңа хатын булырга тиң булган һичбер нәрсә юк. Вә ата-ана булырга Аңа охшаш вә якын булган нәрсә юк. Иштә, ошбу кыска вә бик кыска сүрәнең кыскача мәгънәсе ошбудыр. Вә игътикадка [инану] кагылышлы иң әһәмиятле хөкемнәрне дәлилләре белән бергә үз эченә аладыр.

Дәвамы алдагы саннарда.

Басмага ***Ренат Миңнегалиев*** *әзерләде.*

ХАН МӘЧЕТЕНДӘ

(ХЫЯЛ)*

ГАЛИ РӘХИМ

ГАЛИ РӘХИМ (1892-1943) – ЯЗУЧЫ, ТЕЛ ГАЛИМЕ, ТАРИХЧЫ. «МӨХӘММӘДИЯ» МӘДРӘСӘСЕНДӘ, АННАН СОҢ КАЗАНДАГЫ КОММЕРЦИЯ УЧИЛИЩЕСЫНДА, МӘСКӘҮ СӘҮДӘ ИНСТИТУТЫНДА БЕЛЕМ АЛА. «ҖИР ЙӨЗЕ», «ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫ ӨЧЕН МАТЕРИАЛЛАР ҖЫЮ ЮЛЫНДА БЕР ТӘҖРИБӘ», «УТЫЗ ЕЛЛЫК ХЕЗМӘТ», «БЕРЕНЧЕ ТЮРКОЛОГИЯ КОРЫЛТАЕ ҺӘМ АНЫҢ ТИКШЕРГӘН МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ» КЕБЕК ФӘННИ ХЕЗМӘТЛӘР, «ҖАНВАР» ПЬЕСАСЫ, «БЕР ШАГЫЙРЬНЕҢ ӨЙЛӘНҮЕ» ХИКӘЯСЕ, «ИДЕЛ» ПОВЕСТЕ АВТОРЫ.

Хан мәчетенең ләхет шикелле тар юлларыннан үтеп югары чыгуга, тәрәзәләрдән өргән саф, хуш исле язгы җил минем бөтен гәүдәмне чолгап алды. Манарада миннән башка берәү дә юк иде. Иделгә таба караган тәрәзәләрдән берсенең төбенә утырдым да карарга тотындым. Түбән карап булмый – баш әйләнә. Бөтен шәһәр уч төбендә генә кеби, күзләремне ераккарак күчердем. Әнә буйдан-буйга Идел ялтырап ята. Ул, ташып, бик күп җирне каплаган. Аның өстендә күз аермаслык дәрәҗәдә кечек пароходлар, көймәләр йөзәләр. «Идел гөрли икән», дим. Күккә карадым. Күк яз көне генә була торганча саф, ачык зәңгәр төстә иде. Күк буенча яз көне генә була торган кечкенә-кечкенә ак болыт кисәкләре агылалар иде.

Төн буе йокламый чыкканга талчыккан, авырайган башымны хан мәчетенең эре-эре саргылт кирпечләрдән салынган диварына терәдем. Ул салкын иде. Күкнең ерактагы томан арасында күренә торган, күгелҗем таулар белән кушылган төшенә карый башладым. Уйларым әллә кайларга йөгерделәр… йөгерделәр… Күземне таулардан алуыма, Идел белән кала арасын тутырган халыкны күреп гаҗәпләндем. Әле генә ташу суы астында булган үзәннәрнең коры җиргә әверелүенә ул кадәр исем китмәде. Бәлки шул урыннарны тутырган адәм дәрьясын күреп аптырадым. Бу халык хисапсыз иде, алар еракта каралып яткан нарат урманнарыннан алып Идел белән кала арасында булган бөтен болынны, шикәргә ябырылган кара чебен кеби, сарып алганнар иде. Уңга карасаң да кабара халык, сулга карасаң да кабара халык.

Шәһәргә карасам, тип-тигез генә төпле таш йортлар, такта түбәләр, агач йортлар берсе артыннан берсе рәтсез-чиратсыз тезелеп киткәннәр. Шәһәр биек агач койма белән кыршатылган. Койманың тышкы ягында тирән канау, койма авызы үр өстенә менгезеп, рәттән тезеп утырткан бүрәнәләрдән корылган.

*Хикәя «Аң» журналының 1913 елгы 13 нче санында басылып чыга (Б.225-228).

Шәһәр эчендә дә тулы халык. Ерактан ук ялтырап күренә торган тимер киемнәреннән, кулларындагы озын сөңгеләрдән бу халыкның гаскәр икәнлеге беленеп тора. Шәһәрнең коймасы берничә урыннан бозылган. Шул ачыклыклардан, гарасат купкан төсле, халык мәж кайный, анда сугыш. Шәһәр тышындагы гаскәр кала эченә басып керергә тырыша. Кала эчендәгеләр каршы торалар. Күтәрелгән кылычларның ялтырап-ялтырап киткәнлекләре күренә. Шалтыр-шалтыр корал тавышы аркылы бертуктаусыз меңнәрчә халыкның шаулавы ишетелә. Бу гөрелдәү бер акрынлый, тагы күтәрелеп китә, вакыт-вакыт гөрелдәү аркылы ялгыз-ялгыз тавышлар ишетелеп китәләр. Сирәк-сирәк мылтык һәм туп аткан авазлар килә.

Менә ачыклык турысында халык артыграк дулкынлана башлады. Тыштагы гаскәрнең, акрын гына агылып, кала эченә кергәне күренә. Менә шәһәрне саклаучы гаскәр белән кергән гаскәр катышты. Каланың урамнары ду килеп сугыша торган халык белән тулды. Тавыш тагы да куәтләнде. Хәзер гүелдәү аркылы аермачык җиңүчеләрнең шатлыклы авазлары ишетелә, койма ачыклыкларыннан шәһәр эченә яңа гаскәр тула тора. Менә инде шәһәрнең уртасындагы зур мәйдан да гаскәр белән тулды. Һәммә җирдә сугыш…

Менә бераз гына сугыш басылган кеби булды. Кала сакчыларының төрле төшкә таралган гаскәрләре бер җиргә оеша башладылар. Менә алар кузгалды. Төрле урамнарга таралган дошман гаскәрен кысарга тотындылар. Әнә тегеләр качалар, әнә инде аларны коймаларга илтеп терәделәр. Тагы сугыш куәтләнде. Тышкы яктан тагы ургылып-ургылып дошман гаскәре керә башлады. Менә шәһәрне саклаучы гаскәр чигенә. Менә качалар. Арттан дошман гаскәре басып килә. Аларның чиге күренми. Алар бөтен шәһәрне басканнар. Качучы гаскәр аларга караганда ап-аз гына булып күренә. Сугыш утлары якынлаша, утлары якынлаша…

Манараның астында гына тавыш купты. Тәрәзәдән башымны чыгарып карадым. Манараның әйләнәсендә әле яңадан бер кат койма барлыгы әле генә күземә чалынды. Бу койма бик калын итеп таштан салынган иде. Койманың эчке ягында искиткеч зур матур биналар, мәчетләр, сарайлар бар иде. Хәзер биналар арасында да, таш койма өсләрендә дә шыгрым гаскәр. Аларны хәзер аермачык күреп була. Кайсыларының өсләрендә тимер киемнәр, башларында тимер бүрекләр, кайсыберләре исә башларына тире бүрек, өсләренә сары чикмән генә киеп, билләренә пута бәйләгәннәр, кайсыларының аягында итек, кайсыларыныкында чабата, кулларында кылычлар, сөңгеләр, җәяләр, калканнар…

Күземне яңадан шәһәр өстенә ташладым. Анда күп йортлар яна иде. Кара төтен шәһәр өстенә җәелеп, бөтен шәһәрне ут алган төсле итеп күрсәтә иде.

Ул да булмады, койма өсләрендә сугыш башланды. Койма өсләренә җыелган халык аркылы һөҗүм итүчеләр күренми иде. Алар, ничек итептер, тышкы яктан койма өстенә үрмәлиләр, сөңгеләр белән өстәгеләргә һөҗүм итәләр, ә өстәгеләр аларны шулай ук сөңгеләр белән чәнчеп төшерә торалар иде. Төркем-төркем халыклар койма астына ташлар, агач кисәкләре ташыйлар, икенчеләре аларны койма өстенә менгерәләр, койма өстендәгеләр аларны һөҗүм итүчеләр өстенә ыргыталар иде. Менә таш ташучыларның берсе узып барышлый, ни өчендер, манара түбәсенә күтәрелеп карады. Аның йөзенә үлем куркусы чыкканлыгы беленеп тора иде.

Менә әллә ни булды: кальга [кечкенә крепость] эчендәге гаскәр бер якка агыла башлады. Манара тирәсе буш калды. Ерактан ук бик каты сугыш тавышы ишетелә башлады. Озак вакыт үтмәде, төркем-төркем белән чабышып кергән дошман гаскәре кальга эчен тутырды. Аларның шатлыклы тавышлары күккә чыга иде. Тәрәзәдән башымны чыгарыр-чыгармас кына мин аларны карый башладым. Өсләре-башлары канга буялып беткән иде. Кайсыларының йөзеннән кан ага иде. Алар, котырган кешеләр төсле, кулларындагы канлы коралларын селкеп кычкыралар иде.

Менә кайдандыр ике кеше килеп чыкты, кулларында кораллары юк иде. Сары чикмәннәреннән, җонлы бүрекләреннән мин аларның бая гаскәр кальга өстендә сугышканда таш ташыган кешеләр икәнлеген белдем. Алар курыккан куян шикелле як-якларына карандылар да кораллы кешеләрне күргәч кача башладылар. Котырган кешеләр төркеме белән аларга таба чаптылар. Теге сары чикмәнлеләрнең берсе аксак иде. Ул иптәшеннән артка калды. Менә ул артына әйләнеп карады. Куучыларның якын икәнен күргәч, кинәт тукталып, тегеләргә каршы җиргә тезләнде дә кулларын күтәрде. Аның йөзе ап-ак булган иде. Кылычлыларның берсе кулындагы кылычы белән тегенең башына чапты. Сары чикмән егылды. Кораллы кешеләр, аны таптап узып, качкан кешенең артыннан йөгерделәр.

Менә берсе кайдандыр бер хатынны өстерәп алып килә. Хатын тыпырчына, китәргә азаплана. Аларның артыннан бер карт килә, өстенә кигән озын киеменнән аның сугышчы булмаганлыгы беленеп тора. Ул теге хатынны өстерәгән тимер бүрекле кеше артыннан чак-чак өлгерә, ул, ахры, аны тегенең кулыннан коткармакчы була бугай. Сугышчы исә аңар әйләнеп тә карамый, үзенең тоткынын өстерәүдә дәвам итә. Менә аның катына иптәшләре җыелып, нәрсәгәдер тавышлана башладылар. Әнә берсе кулындагы сөңгесе белән картның аркасына чәнечте. Карт йөзтүбән егылды.

Шул арада манараны төтен каплап алды, бернәрсә дә күренмәс булды. Тәрәзәдән башымны алып, тирәякка карасам, манара тирәсендәге бөтен биналарның дөрләп янганнарын күрдем. Бөтен дөнья ялкын вә төтен диңгезе иде. Вакыт-вакыт төтен манараны каплап ала иде. Мин куркып калтырый башладым. Тешләрем шакшак бәреләләр иде.

Җил төтенне читкәрәк алып киткәч, тагы тәрәзәдән сузылып, түбән таба карадым. Манара тирәсендә гаскәр күп үк иде. Бары берничәсе генә кайдандыр кечкенә-кечкенә мичкәләр тәгәрәтеп китереп, манара астына урнаштыралар иде. Кинәт бу мичкәләрнең дары мичкәләре булуы уема килеп төште. Тегеләр тагын манараны дары белән күтәрттермәкче булалар иде. Минем күңелемә үлем куркусы төште. Кулларым, аякларым салкынланып киттеләр. Түбән төшәргә куркам, чөнки тегеләр үтерәчәкләр, монда калсам да, барыбер бетәчәкмен…

Шул арада әллә нинди теләк хасил булды. Мичкә тәгәрәтүчеләр дә, эшләреннән тукталып, бер якка таба карый башладылар. Матур кара атка атланган бер кеше чабып килде дә манара алдында кинәт атын туктатты. Аты, туктатканга ачуланып тыпырчына, үргә сикерә башлады. Өстендәге кыйммәтле киемнәреннән, атыннан, ат өстендәге кыйммәтле ияреннән бу кешенең зур дәрәҗәле кеше булуы күренеп тора иде. Ул гайрәтле вә ачулы тавыш белән мичкә тәгәрәтүче гаскәриләргә нидер әйтеп кычкырды. Тегеләр һәммәсе атлы кеше алдында тез чүктеләр. Аттагы кеше манараның башына карады,

аның кара сакаллы йөзенә ачу галәмәте җәелеп, чәһрәсен [йөзен] йөрәк яргыч төскә керткән иде. Ул атыннан төште. Теге кешеләр, йөзләре белән җиргә капланып, аның аягына баш ордылар. Аттан төшкән кеше араларыннан берсенең башына аягы белән тибеп торгызды да атын тотып торырга кушты. Калганнарына да нәрсәдер әйтеп кычкырды. Тегеләр, яткан җирләреннән торып, кызу-кызу дары мичкәләрен кире тәгәрәтә башладылар. Ул арада яңадан унлап атлы кеше, чабып килеп, манара алдына туктадылар. Алар атларыннан төшкәч, элек килгән кеше аларга нәрсәдер әйтте, һәммәсе манара эченә кереп югалдылар.

«Алар монда меләләр. Харап булдым!» дигән уй йөрәгемне ярып керде. Мин дер-дер калтырый башладым. Менә аста инде аларның аяк авазлары ишетелә... Хәзер менеп җитәләр... Баскычтан дөп-дөп басып менгәннәре якында гына ишетелә башлады... Уянып киттем. Күземне ачуга, иң элек күземә ташланган нәрсә — күлмәкләрен кыстырган, аякларына каюлы яшел читекләр, калын кәвешләр кигән абыстайлар булды. Тәвәккәл бүрекле маңка малайларын ияртеп, мышный-мышный менеп киләләр иде. «Фәхриҗамал! Фәхриҗамал! Ниямәстә эшләп калдың инде анда тагы!» — дигән ачы тавыш минем йокымны бөтенләй ачты. Мин тәрәзәдән тышка таба карадым. Шәһәр әүвәлге төсле үк җәелеп ята. Идел дә әүвәлге төсле кояш астында ялтырый, аның астында кечкенә-кечкенә генә пароходлар, баржалар йөриләр иде. Мин шуларга тагы бер тапкыр күземне йөртеп чыктым да тар юлдан азаплана-азаплана түбән төшеп киттем.

Текстны басмага
***Дания Заһидуллина** әзерләде.*

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНӘ

«Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле».

Габдулла Тукай,
«Уянгач беренче эшем»,
1913 ел, 14 март

«АЛТЫНГА КАРШЫ» (1911), шигырь. Әсәр XX гасыр башы Россия һәм татар җирлегендә тирән тамыр җәйгән, үзе белән күп бәла-казалар алып килгән, рухи-әхлакый кыйммәтләрне югалтуга этәргән капиталистик җәмгыятьне тәнкыйтьләүгә юнәлтелгән. Акча, байлык артыннан кууның аяныч нәтиҗәләре «мокаддәс җир йөзен яндыручы» ялкынлы «алтын, сары металл», «сары йөз», «сап-сары шәйтаннар» һәм Иблис белән чагыштыру, метафора һәм символларга корылган образ-сурәтләр ярдәмендә күрсәтелгән. Автор фикеренчә, матди байлыклар, акча, алтын туплауны идеал итеп куя җир йөзендәге барлык халыкларны һәлакәткә китергән: *«Бу халыкны шул бозадыр, шул котырта, аздыра, / Ялтырап, күзләрне чагып, тугры юлдан яздыра»*. Алтын җыю кешеләрнең акылларын томалый, яхшылыкны яманнан, гаделлекне ялганнан аера алмауга, вөҗдансызлык юлына этәрә: *«Һәр тараф, һәр җирдә халкың — шул металлның бәндәсе; / Күрмиләр хакны, чөн алтын һәр хәкыйкать пәрдәсе»*. Шигырь зур гомумиләштерү көченә ия. Ирония белән сугарылган соңгы бәйттә сары алтын хакимлегенең кешелек тарихындагы гуманистик кыйммәтләрне юкка чыгаруы, хәтта яһүд, христи-

Сәхифәне филология фәннәре докторы **ЗӨФӘР РӘМИЕВ** алып бара.

ан, мөселман халыклары диннәренең Изге Китапларын да рухи коллык тозагына төшәргә мәҗбүр итүе турында фикер әйтелә: *«Бу халыкча: зөһед, тәкъва, тугрылык та, дин дә шул: / Хәзрәти Коръән, Зәбүр, Тәүрат та шул, Инҗил дә шул!»*

Совет чоры әдәбиятчылары «Алтынга каршы» шигырендә «сары шайтан» образын фаш итүгә зур игътибар биргән рус язучысы А.М.Горький йогынтысын күрергә тырыштылар. Чынбарлыкта исә Тукайның сәнгатьчә фикерләве өчен җирлек вазифасын Шәрык чынбарлыгы үтәде. Шагыйрьнең Тәгалә, мәләкләр, шайтаннар, Иблис, гасыйлар, зөһедлек, тәкъвалык, хакыйкать, хаклык, Зәбүр, Тәүрат, Инҗил, Коръән кебек диннәр тарихыннан, ислам мифологиясеннән, Коръәннән алынган образ-сурәтләргә, исем-төшенчәләргә мөрәҗәгать итүе, алардан иҗади файдалануы моның шулай икәнлегенә ачык дәлил.

Кешелек җәмгыятендәге рухилык принципларын аяк астына салып таптаган алтын хакимияттен тәнкыйтьләү Шәрыктә Коръәннән үк башлана. Урта гасыр гарәп, фарсы, төрки әдәбиятларда бу темага бик күп шигырь-поэмалар һәм хикәятләр языла. Мөгаен, аларның иң күренеклесе һәм Тукай шигыре белән дә типологик охшашлыгы зур булган азәрбайҗан шагыйре Хаканиның (1120-1190) «Ике Гыйрак бүләге» поэмасындагы алтынга кол булуны тәнкыйтьләгән бүлектер. Җир тормышындагы газапланулар, җәфалануларның тамырлары байлыкка — алтынга барып тоташу турында Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр да үз хөкемен әйтеп калдыра. XX гасыр башында социаль контрастлар, вәхшәт белән тулган капитал дөньясын Яңа заман реализмы һәм романтизмы күзлегеннән фаш итүгә азәрбайҗан шагыйрьләре Г.Сабир белән М.Һади зур өлеш кертәләр. Аларның кайбер шигырьләренә Тукай тәкълид-нәзыйрәләр дә иҗат итә. Дөнья белән алтын идарә итә дигән фикер гасыр башындагы татар модернистик әдәбиятын да читләтеп үтми. Мәсәлән, «Мин төш күрдем» (1913) нәсерендә М.Хәнәфи бармак араларына алтын акчалар кыстырган «кызыл күзле, кып-кызыл киемле, кап-кара йөзле» сәер зат алдында «тезләр чүгеп», «сәҗдә кылып торучы», «ачлыктан гакылдан язган», «тире белән сөяктән» генә торган халык көтүе образ-символын иҗат итә. Нәсердәге «тезләр чүгү» реминисценциясе үзеннән-үзе Тукайның Мөхәммәд Һади иҗаты тәэсирендә язылган «Дөньяда торыйммы? — дип киңәшләшкән дустыма» (1907) шигырендәге *«Читен тормыш! — капиталга чукынмасаң, / Хәзрәтендә тезләр чүгеп укынмасаң»* дигән юлларны искә төшерә.

Шигырь (мәснәви) аа бб вв рәвешендә рифмалашкан, һәр юлы 15 иҗекле, 4 ритмик буынлы 8 бәйттән тора; гарузның рәмәл төрендә язылган. Кульъязмасы сакланмаган. Беренче мәртәбә «3 нче дәфтәр»гә (1907) кертелгән.

Чыганак

Тукай Г. Әсәрләр. Академик басма. — 1 том. — 2011. — Б.188.

Әдәбият

Халит Г. Тукай үткән юл. — Казан, 1962. — Б. 171; Ганиева Р.К. Сатирическое творчество Тукая. — 1964. — С.33.

Резеда Ганиева,
филология фәннәре докторы

ЯВЫЗ ИВАННЫҢ АЧЫ ТЕЛЕ

ФӘНЗАМАН БАТТАЛ,
сатирик язучы

Явыз Иванның, ягъни Иван Грозныйның тиранлыгы, кансыз һәм мәрхәмәтсез патша булганлыгы бөтен дөньяга мәгълүм. Башка халыкларга гына түгел, үз халкына да зур афәтләр китереп торган, миллионнарча кешеләрне корбан иткән, үз даирәсендәге бояр-кенәзләрне дә үз куллары белән җәзалаудан ләззәт тапкан, үз улын буып үтерүгә дә җөрьәт иткән канәчкеч зат икәнлеге бик күп тарихи китапларда чагылыш тапкан. Ләкин… бу очракта мин аның уңай сыйфаты — көчле сатирик та икәнлеге турында бер генә мисал китереп язмак булам. Төгәлрәк итеп әйткәндә, аның кулы белән язылган, мине кат-кат көлдергән үткен, ачы телле бер хаты турында бу бәян.

…Казан ханлыгын яулаганнан соң, Явыз Иванның Кырым ханлыгына һөҗүмнәре ешая бара. 1573 елда ул Русь белән Кырым арасындагы Донец шәһәрчегенә (хәзер аның Харьков шәһәренең бер өлеше булып калганлыгы, «йотылганлыгы» билгеле) гаскәрен, ягъни воеводасын җибәрә. Бу гаскәр тиз арада җиңелә һәм аның башлыгы Василий Грязнойны да татарлар әсирлеккә төшерәләр. Сорау алганда, ул үзенең бөек гаскәрбаш һәм Грозныйның кадерле кешесе, зур таянычы булуын, үзен сатып алу өчен, патшасының йөз мең тәңкәне дә түләячәген әйтә. Кыскасы, нәгърә ора, шапырына — чамасын белми мактана. Моны ишеткән кырымлыларда бик мөһим фикер туа:

— Әһә! Әгәр бу кадерле дә, кыйммәтле дә зат икән, димәк, бер ел элек урыслар әсир иткән Дивәебезне коткарып — Грязнойга алыштырып кайтарып була!

Дивәйнең кем икәненә килсәк, ул да кырымлылар хозурындагы кодрәтле гаскәр башлыкларының берсе. Чыгышы белән Нугай урдасыннан, атаклы Мансур нәселеннән. Бу нәсел биләгән җирләр Иделнең Урта һәм Түбән тирәлекләре арасында, Җаек елгасы һәм Урал таулар буйларында. Шик тә юк, Нугайдан да ярдәм алырдай зур шәхес. Инде әйткәнебезчә, ул да әсир һәм яткан-торган җире урыслар биләмәсендә...

Аларның карары болайрак була:

— Безгә акча кирәкми, Грязнойны Дивәйгә алыштырабыз!

Бу хакта, әлбәттә, Грязнойның үзенә дә әйтәләр. Шул хакта ул ялварып Грозныйга хат (послание) яза. Ягъни, Дивәйгә алыштырып, гомерен саклап калырга тырыша.

Ниһаять, әлеге хат Иван Грозныйга барып ирешә. Мөгаен, аны укыганда патша гарьләнгәндер һәм зәһәрлек белән кытыклана-кытыклана көлгәндер дә... Аннары, җавап итеп, беренче җөмләләрен яза башлагандыр...

«Гөнаһларың аркасында әсирлеккә төшүең турында язгансың; сиңа шул төс, Васюшка. Юлыңны белмичә, Кырым олысларында әрле-бирле йөрмәскә иде. Ә инде барып кергәнсең икән, ауда йөрүче сыман йоклап йөрмәскә иде. Син үзеңне этләрең белән урау юлларда куян эзләп йөрүче аучы дип уйлагансың, шуңа күрә сине кырымлылар үз ияреңә бәйләп куйганнар. Син бәлки Кырымда да минем белән ашагандагы кебек шаярырга ярый дип уйлагансыңдыр. Кырымлылар синекеләр кебек йокламый һәм назлы бикә кебек сезләрне әләктерә беләләр. Алар сезнең кебек чит ил чигенә җитү белән: «Өйгә кайтсак та ярый!» — димиләр. Әгәр дә кырымлылар сезнең кебек җебегән хатыннар (бабалар) булсалар, Мәскәүдә үк түгел, елга артында да булмаслар иде».

Фәһемле укучыга аңлашыладыр: «елга арты» диюендә Грозный әлеге Донец җирлегендәге Северский Донец елгасын күздә тоткан. Ә инде «Мәскәүдә үк түгел» дигән сүзләре Кырым ханы Дәүләтгәрәй явының 1577 елда Мәскәүне алуына һәм яндыруына ишарә...

Күренә ки, Иван үз дошманнарының көчле булуын таныган, үз гаскәрләренең күпчелеге «баба»лардан гыйбарәт булуын да аңлаган. Ачулы һәм зәһәрле булуы да нык сизелә — һәр җөмләсе мыскылга төрелгән. Хәер, посланиесен укуны дәвам итик:

«Син анда үзеңне бөек кеше дип игълан иткәнсең. Монысы, яшереп торасы юк, минем гөнаһларым аркасында. Князьләр һәм боярлар безнең атабызга да хыянәт итә башлаганнар иде. Ә без һаман сезнең кебек холопларны, хезмәт һәм дөреслек көтеп, үзебезгә якынайттык...»

Урысларда иң мыскыллы сүз ул — «холоп». Татарчага авыштырсак, тәлинкә ялап, ялагайланып гомер итүче кол яки адәм актыгы мәгънәсендә. Ә инде урысларның үзләрендә арт санның ярыгын ялаучы буларак аңлашыла... Менә син үзеңне бөек шәхес дип санап яшә-яшә дә өстәрәк утыручы түрәләреңнең синең хактагы чын, асыл фикерләрен, бәяләрен белеп кара әле, ә!? Мәсхәрәнең дә мәсхәрәсе бит!.. Күп, хәзер дә күп үзләрен дөньяның кендеге, Алланың кашка тәкәсе дип санаучы бәндәләр. Ә ахырдан аларны да, тәмәке төпчеген төкереп ташлаган кебек, тарих чүплегенә аткаралар. Хәер, моны аңлатудан файда юк шул. Ялаучылар (холоплар) гомер-бакый булган, хәзер дә күп, киләчәктә дә булачаклар...

«Әйе, синең дә якынайтылган булуыңны яшермибез, сине сатып алу өчен ике меңне бирербез. Моңа кадәр әле синең кебекләр илле сум гына тора иде. Ә инде йөз меңне падишаһлар (государьлар) өчен дә сорамыйлар һәм бирмиләр дә. Әгәр дә син үзеңне бәләкәй кеше дип игълан иткән булсаң, синең белән Дивәйне алыштыруны өмет итмәгән булырлар иде. Дөрес, Дивәйне үз патшасы да бәләкәй кешегә саный, ләкин синең өчен йөз мең алырга теләми, Дивәйне сорый: Дивәй аңа йөз меңнән дә кыйммәтрәк. Дивәйнең улына ул үз кызын бирде. Чөнки нугай кенәзләре һәм морзалары аның өчен бертуганнар. Дивәйнең исә үз кул астында да синдәйләр хисапсыз күп иде, Вася. Сиңа, иреккә чыккан сурәттә дә, Дивәй христианнарны әсир иткән кадәр татарларны кулга төшерү, әсир итеп алып кайту тәтемәячәк. Сине Дивәйгә алыштыру христианнар өчен файдага түгел бит. Син азат булсаң, кайтырсың да ятырсың. Дивәй исә синнән дә шәбрәк христианнарны йөзләп-йөзләп әсир итеп алыр. Шуннан безгә ни файда булыр?»

Әнә шундый зәһәрлек, көйдергеч сарказм белән көлә белгән Явыз Иван. Грязной үзе исән чакта ук аңа кемлеген ачыктан-ачык язып, «бөеклегеннән айныткан». Хәзерге зур түрәләр арасында да бар микән Грозный кебек үк сатириклар. Булсалар, дөньяны төрле әтрәк-әләмнәрдән азмы-күпме арындырып торырлар иде, ичмасам! Юктыр шул, юктыр… Барлыклары һич кенә дә сизелми… Грозный исә хатын шул ук рухта тәмамлый: «Инде син үзеңне чамадан югары итеп бәяләгәнсең икән, ул кадәр хакны ничек бирмәк кирәк?! Үз үлчәвеңне тияреннән чамасыз зур итеп күрсәткәнсең икән, — бу христианлыкка файда түгел, бәлки христианлыкны бөлдерүгә кайтып кала.

Әгәр син тәкәбберлегеңне дәвам итеп, христианлыкка каршы барсаң, Христос синең дошманың булыр».

…Василий Грязной үзен патшасының сатып та алмаячагын һәм Дивәйгә дә алыштырмаячагын катгый белдергән бу хатын хәбәр йөртүче атчабар (гонец) Иван Мясоедовтан кабул итеп ала. Шуннан соң тарихта бер генә эз кала: Кырым татарлары Грязнойның бик вак холоп икәнен аңлап, аны Грозныйга бик арзан бәягә сатып җибәргәннәр. Аннан соң нәрсә булганы тарихта калмаган. Кем белә, бәлки аны явыз патша үтертү өчен генә сатып алгандыр. Бәлки әле бер аулак почмакта үз куллары белән газаплап җәзалагандыр. Булмас, димәгез… Чөнки өстәгеләр өчен полководец дип йөртелүче затларны да, халык әйтмешли, тирескә-кәлҗемәгә әйләндерәләр бу илдә. СССР чорында гына да чекистлар йөзләрчә генералларны юк иттеләр, Якир, Тухачевский фамилияле маршалларны подвалларда айлар буе җәзалап аттылар. Бөек Ватан сугышында җиңүне тәэмин иткән, дүрт мәртәбә Советлар Союзы герое дәрәҗәсе бирелгән, иң затлы маршал саналган Жуковны да үзе исән чакта ук «аэайлап» бетерделәр, Ворошилов кебек легендар маршал-геройлар да үзләренең «кем икәнлекләрен» исән чакта ук аңлап, теге дөньяга вак кешеләр булып күчтеләр…

Шулай… Василий Грязной турында кем генә белә икән хәзер? Белсә дә кайбер тарихчылар гына беләдер. Исән чагында полководец дип йөртелсә дә, исемен Зур энциклопедиягә дә кертмәгәннәр…

БЕЗ ИСӘН!

АЙДАР ХӘЛИМ

Ташлар басты, ташлар басты безне,
Биш гасыр ташлардан изелсәң,
Таш күзеннән җандай чәчрәп чыгып,
Әйтү ләззәт икән:
Без исән!

Җимертелгән Шәһри Казан сыман
Атылырга рәткә тезелсәң,
Җәһәннәмнән кабат күтәрелеп,
Әйтү ләззәт икән:
Без исән!

Безне талап, алар баемады,
Хәер сорашалар — син күрсәң!
Без һаман бай, чөнки таңнан торып,
Милләтебез эшли —

Без исән,
Без исән!
Без исән!

Н.Гариф фотосы

ЙОЛДЫЗЛАР ТӨСТӘН ЯЗГАНДА...

РИФӘ РАХМАН,
галимә, шагыйрә, Ф.Хөсни исемендәге премия лауреаты

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК*

...Авыл да, аерылышуның хәсрәтле көннәре дә еракта калды, суды да булды, карары да чыкты. Аны, вакытлыча дип, Хуҗиәхмәт белән Чаллы төрмәсенә җибәрделәр. Җанбикәнең әле гаепсезлеге ачыклануга, Себергә сөрелми генә авылына әйләнеп кайтуына өмете юк түгел иде. Ай дигәндә ул да җимерелеп төште. Бердәнбер сөендергәне Хуҗиәхмәтнең үзеннән аерылып алынмавы иде.

Җанбикә күрәчәгенә күнгән, алдагысына ризалашкан, тынычланып калган кебек булгач, Томски дигән ерак бер кала якларына озатылачаклары турында хәбәр бирелде. Себергә юллары Чуенский аркылы дигәч, йөрәге тагын җилкенеп куйды Җанбикәнең. Олы юл аларның авыллары аша да узарга тиешле иде. Шул арада әнкәсенә хат язып салды, фәлән-фәлән вакытта чыгабыз, Гөлхәбирәне имезеп булса да китәрмен, сагындым, сөт төшкән күкрәкләремнең сызлавына да чыдар хәл юк, бәләкәчемне бер ашатсам, корыйсы булса да риза, диде.

Килененең соңгы сүзләреннән Гөләфтар карчык куркып ук китте. Аллам сакласын, диген, сүзне аны сөйли белсәң генә сөйлисе. Алай да ул хатка сөенде, тик Җанбикә Хуҗиәхмәт турында гына бер кәлимә язмаган иде. Шуңа гына эче пошты. Димәк, барыбер аерганнар, димәк, балакае кайдадыр шушында гына, балалар йортында дип уйлады. Анысы яхшыга гынадыр әле аның...

Менә этап белән Кызыл аланга да җиттеләр. Озатып баручы конвойдан юл буе ялына килгән иде. Авылда биш айлык сабыем калды, имезергә генә рөхсәт бирерсең дип, тәки күндерде Җанбикә.

Авыл башына җиткәнче үк, каторжаннар каршына чыгып басучылар арасында каенанасын ул бик тиз шәйләде. Кулында сабые — Гөлхәбирәсе иде. Шунда ук изү сәдәфләрен дә чишәргә кереште.

Сөйләшеп туя алмас шикелле иде Җанбикә, каенанасын күргәч, теленә бер сүз килмәде, бите буйлап яше акты да акты, үзе һаман сабыен имезүдә булды. Бик теләсәң дә, озак маташа алмыйсың, үз рәтеңне куып җитәргә кирәк. Гөлхәбирәне чупырып бер үпте дә җан-фәрманга каторжаннар артыннан йөгерде.

Җанбикә белә иде: авылны чыккан-

*Дәвамы. Башы журналның 7 нче санында

да, аны үз әнисе күтеп торачак. Алар алдан ук шулай сөйләштеләр. Бәлки, мәрхәмәте килеп, озата баручы берике минутка гына барысын да хәл алырга туктатыр. Алай дип уйлап та бетермәде, каторжаннар каршысына тыкрык урамнан Хөбби Нәфисәсенең йөгереп килгәне күренде:

— Шул кирәк аларга, улым, шул кирәк! Ире Солтанморат та адәм актыгы иде! Бирсеннәр кирәкләрен! Чересеннәр Ысталин устругларында! Бер минутка ялга туктатасы булма!

Егет телен тешенә кысты. Ахырда чәр-чәр килгән әнисенең сүзенә түзмәде:

— Бар инде, әнкәй, кайт, кемне нишләтәсен синнән башка да белерләр, — дип, аны терсәге белән генә юл кырынарак этеп җибәрде.

Җәй эссесеннән әлсерәгән, хәлдән тайган каторжаннар әле ерагайгач та, Нәфисәнең чәриләгәне ишетелеп торды. Җанбикә моңа аптырамады. Хатын-кызның ачуы ирләрнекеннән дә яманрак икәнлекне ул белә иде. Нәфисә — иренең яшьли яратып йөргән кызы, әмма, Солтанморат ерактагы алтын приискаларына эшкә китеп, зимагурлыктан озак кайтмаган бер вакытта, алмасаң алмадың инде дигән сыман, картаеп калудан куркып, авыл көтүчесе Әхмигә ябешеп чыккан иде.

Йортсыз-җирсез Әхмине әбибабалары тегермән буасы янындагы иске өйдә яшәтмәде, билгеле. Кияүнең үзеннән битәр, кызлары Нәфисәне жәлләделәр. Өрми-сукмый үстерсеннәр дә авылның иң соңгы хәерчесенә, анда да ябештереп кенә биреп җибәрсеннәр, имеш. Алай гына булмый әле ул. Кеше сүзенә карап торырга ярамас дип, малайлары Ваһапны башка чыгарырга атап салган йортлары бар иде, никахын-мазарын уздыргач, шул йортка керттеләр дә утырттылар.

Ата-анасы кулыннан да ычкынгач, байлыгы гына түгел, торыр урыны да булмаган Әхмине үзенеке иткәч, болай да телгә-эшкә төшеп калганнардан түгел Нәфисә тагын да шәбәебрәк китте — йорттагы бар эшне дә, властьны да үз кулына алды. Өйләнгәч, Әхмигә тәмам көн калмады. Алай да ир түзде, тамагы туклыкка, күте корыга эләккәнгә бик сөенгән иде, шуларны кабат югалтмас өчен түзде. Өй борынча ашап йөргән, тегермәнче йортында кыш уздырып яшәгән Мәзгытдин карт оныгы гына булса да, андый язмышка кызыкмады. Бабасы үлгәч, болай да бу хәлдән котылырга уйлап йөри иде, җай чыкты: сиңа кияүгә чыгыйм әле дип, тәкъдимне Нәфисә үзе ясады.

Ризалашты. Ризалашмый, нишлисең?! Авылның иң беткән кызы да бармас, дип яшәгән бер вакытта күрер күзгә чибәр, эшкә булган Нәфисәнең аның мунча кадәр, анда да кеше генә биреп торган йортына килергә теләве күкләрдән иңгән бәхет кебек иде. Чыгуын чыга да, аннан ары нишләрләр, ничек көн итәрләр, дип баш ватырга да өлгермәде, инде бабасы Хөббибулла үз өенә үк алып кайтып утыртты. Узган гомеренең бер истәлеге итеп, ичмаса, көтүче чыбыркысын алыйм дип, ишек катындагы кадакка үрелгән иде, кулын шунда ук тартып төшерде:

— Кияү, инде син моннан соң Хөббинекеләрнеке буласың. Чыбыркы өстерәп, көтү дә куып йөрмисең, аның белән бала кыйнап та үстермисең.

Мәзгытдин агайдан калган тәлинкә, чәйгүн ише нәрсәләр бар иде — шуларны гына агач савытка җыеп салдылар да, Хөббибулла карт җигеп килгән арбага чыгарып утырттылар. Аннан авыл янындагы юл буйлап кына Кызыл аланның икенче башына элдерделәр. Каторжаннар атлаган Себер тракты Нәфисәне кияү йортыннан атасыныкына шөлдерле атларда кире алып кайткан юл иде.

Солтанморатны онытa алмыйча, көн уйлап, төн уйлап яшәсә дә, Әхмигә чыгуның да уңай яклары булып куйды.

Патша төшерелеп, дөньялар үзгәргәч, Әхмәдулла кебек ярлы-ябагайга көн килде. Алай да Ваһапка салынган шәп йортта көн иткән Нәфисә эчтән генә шүрли, байлыгыбыз яманнар күзенә чалынмасын дип, эчтән генә сыза иде, шуңа да һәр заман үзен — ата коммунарчы, ире Әхмине гомере авыр тормышта изелеп узган бер адәм итеп күрсәтергә тырышты. Инде дә колхозлар ныгый, әз генә хәллерәк көн итүчеләрнең дә бар нәрсәсе тартып алына барганда, күкрәк сугып кычкыра торганга әверелде:

— Минем Әхмием, Аллага шөкер, кеше өлешенә кереп яшәмәде. Авылдашларыннан талап, байлык та җыймады. Хәл кадәр хезмәт итте, бил бөкте үзләренә. Инде Әхмигә дә көн килер вакыт, аның белән без кеше шикелле яшәп калыйк!

Әхми, чыннан да, байлыкка да, кеше өлешенә дә кызыга торганнардан түгел иде. Хатыны булмаса, Хөббибулла картның малаена салынган йортына да килеп яшәгән булыр иде микән?! Ярлы-гыйбай булса да, хатынының бу чәриләүләре аңа ошамады, әмма дә ләкин туктатырга да базмады.

Кызылларныкын белмәссең, әле кайчан гына тегермән йортында көн иткән Әхми дип тормаслар, сары бүрәнәләрдән салынган йортыннан тартып чыгарырлар да өтерманенә дә илтеп тыгарлар. Хатыны Нәфисәнең, җай чыкканда, Әхминең тормыш төбеннән көчкә күтәрелгән бер кеше икәнлеген лыбырдавы, бер карасаң, аның файдасына иде.

Солтанморатның яшь чагында, әле сәвиткәчә хатыны Нәфисә артыннан сөйрәлүен белсә дә, аңа да үч сакламады Әхмәдулла. Нәрсәсен үчләшәсең? Борын астына мыек төртеп килгәндә, кем кемне сөймәгән дә, кем кемне кочмаган?! Ул Нәфисәгә өйләнеп өлгерсә, хәзер менә Әхми һаман да чыбыркы күтәреп көтү артыннан йөрүдә булыр иде бит.

Әхминең Солтанморатта үче булмаган кебек, ул да Әхмигә карата яман ният белән яшәмәде. Әле приискада яткан чагында Нәфисәнең кияүгә чыгуы хакында авылдашларыннан килеп җиткән сүзгә дә үпкән-кочкан җилгә очкан, дип җавабын әйтте дә бетерде. Дөрес, хәбәр яңа чакта йөрәге көймәде түгел, көйде, әмма Солтанморат сер бирә торганнардан түгел иде. Торабара сөйгәнен югалту хәсрәте аның күңелендә дә басылды. Авылда кызлар кияүгә иртә чыга. Егетемне көтәм, дип сазаган кыз булып калуың да бар. Нәфисә дөрес эшләгән булыр. Солтанморат үзе дә аннан башка кемне күргән дә, аның белән нәрсә эшләгән соң әле?!

Әрәмәдә — карама, егермедән узган кызга кыз булса да карама, дигән әйтемне бик яхшы белә иде егет. Инде Нәфисәгә унҗидесе тулып узган. Җитмәсә, Солтанморат тиз генә өйләнергә ашыкмый, планында, бераз акча туплагач, Бохара якларына китеп, зур белем алу уе да бар.

Егетнең хыялларын уникенче елгы җан өшетерлек хәбәрләр түгел, унҗиденең октябрь җилләре кисте. Ахырдан аңа сөенде генә. Укып бетереп, авылга зур мулла булып кайтса, эшләре тагын да яманрак буласы икән. Ярый артыгын укымаган, алтын кубышкаларына кызыгып эшләгән дә эшләгән... Әле болай үзе тир түгеп, атасы кул көче белән туплаган байлыкка көнләшеп караучылар да юк түгел.

Бохара-Мисыр якларында зур укуларда булып кайтканнарның гына түгел, Казан мәдрәсәләрен тәмамлаган хәлфә-мөдәррисләрнең дә эше яманнан булды. Хәмидулла абзый һәр намазында Әлмөхәммәт хәлфәне догадан калдырмады. Намазлыкларын җыеп, караватының аяк башы ягына тастарлап салып куйганда, еш кына әйтә торган иде:

— Мескен хәлфәнең алмашка кияргә күлмәге булмаса да алдылар. Алдылар, аттылар. Авыл халкына ни зыяны

тигән инде аның? Балаларын яманлыкка өйрәткәнме? Әти-әниләренә каршы котыртканмы? Хәреф таныткан да, язу яздырган гына бит…

Мулла-мөдәррисләрне Кызыл аланнан куганнарын Солтанморат та яхшы хәтерли. Кеше күрмәгәндә генә әнисе Гөләфтар чапан кесәсенә ун тәңкә акча шудыртырга кушкан иде аңа. Салуын салды. Калага китеп, атна-ун көн дә яшәмәгәч, бик тиз суд булып, озак та тормый атылгач, ул ун сумнан аңа нинди файда булды икән? Анысы да мәет күмгән солдатлар кулына гына эләккәндер инде аның. Әгәр дә мәгәр күмгән булсалар… Хәмидулла карт белеп тели: урынын оҗмахлардан гына ит, шәһитләр кавеменнән сана инде, Ходаем.

Нәфисәнең егеттән алда өлгереп гаилә коруы, чыннан да, яхшыга гына булган. Ул, тегендә-монда сугылып туйганнан соң, авылга кайтып, туплаган акчасына ата-ана йортын ныгытып өлгергәндә, Нәфисәнең олы баласы Нурәхмәт әлеге дә баягы Әлмөхәммәт хәлфәгә йөри башлаган иде. Инде дә Нурәхмәткә унтугыз тулган, солдат хезмәтенә алынып, Себергә этап сакчысы итеп куелган иде.

Солтанморат үзе бик соңлап, гражданнар сугышларын кичеп, исән-имин кайткач, утызы тулгач кына өйләнде. Нәфисә белән алар яшьтиләр иде. Әнкәсе Солтанморатны 1895нең июлендә дөньяга китерүенә ай да узмаган, Нәфисә аваз салган. Икесенең дә кендек әбиләре Солтанморат хатыны Җанбикәнең анасы — Хәмдениса карчык, имеш. Карчык, дип, ул чагында әле йөгереп йөргән яшь хатын. Җанбикәне ул үзе дә соңлабрак, абый-апалары аякка баскач кына, Солтанморат бәхетенә алып кайткан.

Җанбикә кыз-кыркын арасында күренә башлаганда, Солтанморат егерме җидесен тутырып килә, чынчынлап авылга кайтып төпләнгән иде инде. Кызга нибары унбиш дип тормады, ахириләре аша әйттерде: егетләр белән чуаласы булмасын, бераз үссен генә, димче җибәртеп, үземә алып кайтып утыртам мин аны!

Шаярып кына әйткән кебек тә иде, нәкъ шулай булып чыкты. Унсигезе тулды гына дигәндә, Җанбикә Хәмидулла абзаларының көтеп алган килене булып яшәп тә китте.

Болай җиңел генә әйтелгәч тә, Шәйдәүләтнең Григорий абыйсы белән авылга җибәрелгән вакытлар иде бу. Комсомоллар җыелышына чакырган кызлар арасыннан күзе шунда ук Җанбикәгә төште. Кыз җыелышка бер килде, ике… Өченчесендә егет түзмәде, комитетчылардан сорады: кем кызы, исеме ничек? Җанбикәгә бу вакытта унҗиде яшьләр чамасы булган. Егетләр кыз турында бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр. Солтанморатның әйткән сүзе барлыгын да, артыннан йөргәнлеген дә ирештерделәр. Шәйдәүләтне болар гына туктатырлык түгел, кыз күңеленә бик нык кереп утырган иде.

Шул көннән йокысы качкан комсомол башлыгы Җанбикә дип йокыга китте, Җанбикә дип йокыдан уянды. Эшләр кызу, коллективлаштыру гамәлләренең кызган бер чагы булмаса, бер-бер нәрсә дә кылган, кыз артыннан ныграк та чапкан булыр иде, әмма тәүге озатуында ук Җанбикәнең сүзен аяк астына ташлавы горурлыгына тиде. Тагын сүз катып карады, тагын… Аннан кулын тәмам селтәде. Кулны селтәргә була, тик кызның гүзәл йөзен күңел түреннән сызып атарлык хәлдә түгел иде.

Инде Солтанморат гүзәл Җанбикәне түренә дә алып кайтып утырткач, Шәйдәүләткә башлы-күзле булу — телəгəненə өйләнү юлы бикләнде. Егет актив җыела торган бай йортының бер бүлмәсендә яши иде. Аның уенча, кызга аннан да тиңрәк юк һәм, нәкъ менә аңа чыга-нитә калса гына, балда-майда йөзәчәк иде дә…

Нәфисәләр авылның теге башында яшәгәч, Җанбикәнең соңгы вакытта Нурәхмәтне бер дә күргәне булмады. Солтанморатның элек күз төшереп йөргән кызларын, аларның корган гаиләләрен бер дә тикшерү гадәте юк иде. Үзенә бала имезергә рөхсәт биргән солдатны Нәфисә малае булыр дип ул башына да китермәде. Әнисе каршыларына чыгып чәриләмәсә, аның шулай икәнлеге беленми дә калган булыр иде.

Этапны Чаллыдан озатканда, бик ныклап әйттеләр: юл озын, авыллар аша узасыз, андый җирләрдә тукталып тору юк. Әле дә ярый Себергә китүчеләр күп түгел, араларында берсе генә татар кешесе, анысы да Җанбикә үзе иде.

Төрмә киеменнән булса да, Нурәхмәт Җанбикә апасын таныды, тик таныганлыгын сиздермәскә карар кылды. Дус бар, дошман бар, дигәндәй… Ул да авылдашы үзен төсмерләгәндер дип уйлаган иде, ялгышкан булып чыкты.

Кызыл аланга җитәрәк, Нурәхмәтнең йөрәге кысылды, яшь булса да, кан басымнары күтәрелде. Ул Җанбикә апасының авылда имчәк кызы калганлыгын да, малаеның, анасыннан тартып алынып, балалар йортына тапшырылганлыгын да белә. Каршыларына чыгып тормасалар ярар иде, дип бик тә теләгән иде, ишеткәннәрме, хәбәр җибәрелгәнме — чыкканнар. Озын буйлы, какча гәүдәле Гөләфтар түтәйне ул Җанбикә апасыннан да алдарак шәйләп алгандыр әле. Каторжаннарның сул ягыннан барыйм, эндәшмәсә җиңелрәк булыр дип уйлаган гына иде, Җанбикә аңа үзе дәште:

— Улым, татар малае бит син, тыңла сүземне, каенанам сабыемны тотып, юл кырына килсә, әз генә имезеп алырга рөхсәт итәрсең, җәме?..

Нурәхмәт җавап кайтармады. Ул әле уйлый иде. Рөхсәт итсә, берәрсенең чагып куюы да бар. Итмәсә, хатын да, сабый да кызганыч. Әлмөхәммәт хәлфәсе эти-әнисенә әйтә торган булган: сабый хакы — Алла хакы, имеш. Ярый әле балагызны сабыйдан ук мәптеккә китергәнсез, кечкенәдән кергәнне бернәрсә чыгара алмый ул, дип. Хәлфәгә бик аз йөрергә өлгерсә дә, әйткәненнән дә, укытканыннан да файдасы тиде. Нурәхмәт Нәфисә балалары арасында иң акыллысы булып үсте. Аң-белемгә дә күңеле ята, эшкә дә кулы килә, ата-анасына гына түгел, күрше-күләнгә дә, карт-корыга да бик миһербанлы иде.

Дөнья бүген болай, иртәгә тегеләй ул дип уйлады Нурәхмәт. Риясыз Әлмөхәммәт хәлфәсен алып киттеләр дип кенә картлар да намаз укудан туктамады, яшьләрнең дә бисмилласы авызларыннан тәмам төшмәде. Көндезен флаг күтәреп, коммунага китсәләр дә, кич кайткач, күпләрнең качырып намаз укуларын сизә иде ул. Дөрес, хәреф танымаган этисе диннән хәбәрсез булган кебек, әлифне таяк дип тә белмәгән әнисе Нәфисә дә мәҗбүриләп гадәтенә кертелгән намазны үзбашка яши башлагач ташлаган иде. Заманы ул түгел дип, Нурәхмәтне дә кулы бисмиллага күтәрелгән саен кисәтә килде. Тик егет намаз-ниязлы ук булмаса да, Әлмөхәммәт хәлфәсе сүзеннән чыгарга курка, нинди генә эшкә тотынса да, эченнән булса да бисмилла әйтми калмый иде.

Алланы бүген кире кагарлар, иртәгә, кем белә, таныйрлар… Бүген болай, иртәгә тегеләй ул дип уйлады кабат Нурәхмәт, алдына гына караган килеш бара-бара. Сөйләшмичә дә баргач, башын булса да какмагач, егет риза түгел дигән фикергә килгән иде, Җанбикә ялгышкан икән. Бераздан ул аның колагына гына пышылдап диярлек әйтә куйды:

— Апа, мин күрмәмешкә салышырга, алгарак китәргә тырышырмын, син тиз генә имезеп ал, әмма юлыңны

дәвам ит инде, безгә туктарга кушылмаган.

Җанбикә монысына да бик риза иде. Нинди туктау! Сабыен кочагына алып барасы булса, атна буе аякта торырга риза лабаса! Судта берара ул бу хакта сүз катарга да уйлаган иде. Әнә бит күпләрнең сабыйларын аермыйлар, тәпи киткәнче, бер яшькә кадәр янында тоталар. Аннан әнкәсенең сүзе исенә төште. Үз исәнлегеңне кара, без кеше арасында, ничек тә яшәп калырбыз, дип язган иде ул хатында. Ходай көн биргәнгә юнь бирер. Себер салкыннарына тилмерткәнче, ягарга утыны булган, абзар артында бакчасы яшәреп торган йортта калуы яхшырактыр да әле. Каенанасына да иптәш кирәк бит. Әле Солтанморатларның хәлләре ни белән бетә — белмәссең.

Нәфисәнең һаман да:

— Улым, туктатма, хәлдән тайганчы барсыннар! — дип чәриләгәне бөтен авылга ишетелеп торырлык булса да, улы Нурәхмәткә рәхмәт: сабый яшен үз өстенә алмады, бала имезгән хатынның да сүзен аяк астына салмады.

Нурәхмәтне танымавына аптырарлык та түгел. Егет ни әнисенә, ни әтисенә охшамаган иде. Ниндидер таныш чалымнар бар шикелле иде аның йөзендә. Бу як бабасы Хөббибулла дип әйтсенме, әллә соң Мәзгытдин картка тартыммы? Ачык кына төсмерләп бетерерлек тә түгел. Иманлы кешенең йөзендә нур була, ди торганнар иде, шулдыр, ахрысы, дип уйлап куйды эченнән Җанбикә.

Шулай... Сүзеңне бер генә боз... Китә дә китә икән ул... Нурәхмәт авылның икенче очында инде Хәмдениса карчыкның чиләк күтәреп басып торганын күрде. Якынгарак килгәч аңлашылды: мескеннәрне тамак ялгатырга дип, аш күтәреп чыккан икән. Алъяпкычының түш кесәсенә ипи телемнәре тыккан, кулында — чүмеч.

Хәмдениса түтиләр Нурәхмәтләрдән ерак яшәми. Аның аларга кайрак, балта ише нәрсәләр сорап керештергәне бар иде. Олы кешегә тагын ничек каршы төшәсең?! Урыс каторжаннар янында усалрак күренеп:

— Хватит болтать! Быстрей-быстрей! — дип кычкырса да, Җанбикәгә татарчалап. — Барган көйгә генә инде, Җанбикә апа, барган көйгә! — диде.

Әнкәсе Хәмдениса нәрсә эшлисен алдан ук исәпләгән, ахрысы. Ачның күзе икмәктә булыр, дигәннәр. Ашны мулдан, барысына җитәрлек, көнләшеп, тавыш куптармаслык алып чыккан. Кызы белән бер кәлимә сүз сөйләшергә җае юк: әле бер каторжанга, әле икенчесенә, әле Җанбикәсенә аш каптыруда иде. Ипиләрне берсенә дә биреп тормады, кызы кесәсенә генә тыкты:

— Юл хәлен белеп булмый, әле алга таба ашарсыз.

Ризык каптыра-каптыра бара торгач, чиләкләр бушап калганчы, чакрым шае ара узылган. Соңгы тамчысын диярлек чүмечендә сузганда, Хәмдениса карчык үкереп елап ук җибәрде:

— Инде аерылышабыз ук мыни соң?! Туйганчы карап та кала алмадым йөрәк парәмне! Күрешергә генә язган булсачы, кызы-ы-ым, бәгырькә-е-е-ем!

Нурәхмәт Хәмдениса апасын туктатты. Моннан да арысын ул рөхсәт итә алмый иде. Әле кайчан гына нәкъ менә Нурәхмәтнең озата баруына күңеле булган, кызын күрүенә, үзенә дә, иптәшләренә дә ризык ашата алуына сөенгән карчык, теләгенә ирешә алмаган бер кеше шикелле, сөмсере коелып, яулык почмагы белән күз яшьләрен сөртә-сөртә, алабута үскән юл кырында калды... Аның, теләсә дә, этап артыннан ни алга барырлык, ни буш чиләген күтәреп өенә кайтырлык хәле калмаган иде.

Ахыры киләсе санда.

ЛИРОН ХӘМИДУЛЛИНГА 80 ЯШЬ

ТЫЙНАК ХОЛЫКЛЫ, БАСЫНКЫ ТАБИГАТЬЛЕ...

Танылмыйдыр кеше гәрчә тышыннан,
Танып була аны кылган эшеннән...

Дәрдмәнд

Лирон Хәмидуллин — «Юлда» исемле хикәяләр, «Дала иртәсе» исемле повесть китаплары, башлыча милләт язмышына бәйле шәхесләргә багышланган нәсер, очерк кебек әсәрләр тупланган «Офыктагы рәшәләр», «Ак төннәр хәтере», «Күңелдә калганнар», «Кичке шәфәкъ» һәм башка әдәби җыентыклары белән әдәбият сөючеләргә таныш автор. 2003 елда татар һәм рус телләрендә нәшер ителгән «Дәрдмәнд» фотоальбомының, Татарстан китап нәшрияты тарафыннан милләтебезнең бөек шәхесләренә атап рус телендә чыгарыла башлаган сериядән «Дэрдменд» китабының да авторы ул. Аның әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеге иҗатташлары һәм рәсми оешмалар тарафыннан да танылган дип беләбез. Лирон Хәмидуллинга «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә. Ул Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге әдәби бүләгенә лаек, Казанның 1000 еллыгы медале белән бүләкләнгән.

Лирон аганың эшчәнлегенең тагын бер әһәмиятле юнәлеше әдәби тәрҗемә, әдәби арадашлык өлкәсенә карый. Татарстан Язучылар берлеге карамагындагы тәрҗемәче-арадашчылар секциясен ун еллап җитәкләү дәверендә аның тарафыннан унике роман, повесть, хикәя китаплары тәрҗемә итеп чыгарыла. Нигездә ул төрки кардәшләребез — казах, үзбәк, каракалпак телләрендәге әсәрләрне үз телебездә бәян итүгә өстенлек бирә. Шул ук елларда аның тырышлыгы белән башка телләрдә безнең язучыларның аерым әсәрләре тупланган китаплар да нәшер ителә: казах телендә — «Татар повестери» тупланмасы, каракалпак, үзбәк, рус телләрендә — «Татар гүрриңлери»,

«Йиллар вә йуллар», «Пробуждение» исемнәрендә хикәя җыентыклары.

Узган чорларның күренекле шәхесләреннән Закир Рәмиев-Дәрдмәнд, Мирхәйдәр Фәйзи, Фәйзулла Туишев, Габделбарый Баттал, Муса Җәлил, Шакир Мөхәммәдьяров һ.б. иҗади һәм җәмгыяви эшчәнлегенә, тормыш-көнкүрешләренә багышланган эзләнүләре дә Лирон аганың уңышлы бер эшедер. Ул бигрәк тә Татарстаннан бер читтәрәк, башлыча Оренбург төбәгендә гомер кичергән шәхесләрнең язмышын ачыклауга үз өлешен кертә. Аның эшчәнлегенә багышланган «Тыйнак табигатьле каләмдәшебез» мәкаләсендә мәрхүм академик Миркасыйм Госманов болай дип яза: «Лирон Хәмидуллинның иҗатында махсус тәкъдир итүгә лаек бер юнәлеш бар. Ул — элекке чор күренекле әдипләребезнең тормыш юлларын, мирасларын өйрәнүгә багышланган эзләнү һәм бастырып чыгару эшләре. Әдипнең шушы юнәлештәге эшчәнлеген игътибарга алып, мин Лиронны «Шәхесләребез» сериясендә чыгарга тиешле «Бертуган Рәмиевләр» исемле фәнни-биографик китапны әзерләү эшенә чакырдым... «Бертуган Рәмиевләр» китабы эчтәлекле, күргәзмә материалларга бай һәм зәвыклы булып чыкты... Бал корты кебек гел эзләнүләрен, шаушусыз гына нәтиҗәле эшләвен дәвам иттерүче Лирон Хәмидуллин өлеше дә бар анда...»

Бүген без сиксән яшен тутырып килүче, исем-аты матбугат битләрендә даими рәвештә күренгәләп торучы язучы Лирон ага Хәмидуллин белән әңгәмә корып утырабыз.

– Лирон ага, моннан илле бер ел элек Сез, Оренбургның дала ягыннан Казан каласына килгәнсез. Ул вакытта инде Сезгә егерме тугыз яшь була. Аңа чаклы өч ел хәрби хезмәттә булгансыз, тимер юлчы һөнәрен үзләштереп, эшләп тә алгансыз. Казанга Сез нинди уй, хыяллар белән килдегез?

— Иң элек «Оренбург даласыннан» дигән төшенчәгә тукталып үтик. Рус әдәбиятында да Пушкиннар заманыннан бирле бик еш кабатлана торган төшенчә инде ул. Олуг шагыйрьнең «Капитан кызы» әсәре вакыйгаларына бәйле рәвештә тумадымы икән ул атама дип тә уйлыйм. Самара, Саратов өлкәләре табигатенә бәйле рәвештә дә шул ук сүзләрне кабатлап була ич. Оренбург төбәгендә шыр даладан тыш, биек-биек таулар да, урманнар да җитәрлек.

Миңа унбер яшь тулганчы, без әтиемнең туган авылында — Зур Чирмешән елгасы буендагы Иске Төгәлбугада яшәдек. Әтиемнең сугышта үлгән хәбәре килгәч, әнинең үз авылында яшәүче апасы да шундый ук хәбәр алгач, әниләр ятим калган

биш малайны бергә тәрбияләргә булалар. Ул балалар арасында мин иң өлкәне — «әйдәп йөртүчеләре» идем. Без унөч ел — мин һәм уртанчы энем Илдус Орск шәһәренә барып эшкә урнашканчы бергә яшәдек.

Казанга алып килгән беренче хыял — күпчелек милләттәшемә хас хыялдыр ул: татар театрлары эшләгән, татар матбугаты нәшер ителгән үзәккә якынрак булырга теләү хыялы. Мин үземне балачактан китап дөньясына табынган кеше дип саныйм. Безнең өйдә китап сүзенә табыну йоласы мин туганчы ук барлыкка килгән. Әбием, мәрхүмә, Габделҗәббар Кандалый исеме белән бәйле Пәрау авылында туа, ишан хәзрәтләре йортында тәрбияләнгән кыз бала була. Кияүгә төшкән авылында аны оста мөнәҗәтче буларак олылыйлар, «абыстай» дип йөртәләр иде. Үз анам да, ике арага кереп, өч ел чамасы яшәп киткән үги анам да сугышка чаклы башлангыч сыйныфларда укыттылар. Икесен дә әбием «китап җене кагылганнар» дип искә ала иде. Шул рәвешле, мин дә мәктәпкә йөреп укый башлаганчы ук хәреф танырга өйрәндем. (Бала чагыма бәйле вакыйгалар «Балачак әдипләре» белешмә китабының III томында тулырак бәян ителә).

Кулга каләм алып, үз күңелемдә туган фикерләрне башкалар белән уртаклашу теләге илленче еллар ахырында тугандыр дип уйлыйм. Шул елда Орск шәһәрендә русча иҗат итүче каләм әһелләренең «Әдәбият түгәрәге» оештырылды. Тыныч кына тыңлап утыручы буларак, вакыт-вакыт ул түгәрәк утырышларында да катнашкаладым. Ул әдәби түгәрәк утырышларына татарлардан без өчәү йөргән идек. Өченчебез, яшь шагыйрь Шәрәф Әхмәмәтев, 1960 елның җәендә Уфага китеп барды. Шигырьләре матбугатта күренә башлады. Мине дә Уфага килергә үгетләде. Килдем. Ләкин башкорт әдәбиятын начар белүемне, әдипләрдән Мостай Кәрим белән Нажар Нәҗмине генә тануымны аңлагач, мин аннан китәргә ашыктым һәм 1961 нең гыйнвар урталарында нурлы Казаныбыз җиренә аяк бастым.

– Казан тормышына тиз генә ияләшеп китә алдыгызмы соң? Кемнәр белән аралаштыгыз?

—Армиядә хезмәт иткәндә, хәрбиләр газетасында кечерәк хәбәрләрем күренгәләгән иде. Казанга килгәч тә «Татарстан яшьләре» егетләре белән таныштым. Шамил Рәкыйпов, Тәүфыйк Сәгыйтев, Дамир Шәрәфетдиновны, «Азат хатын»да баштарак бүлек мөдире, соңрак җаваплы сәркатип булган Хәсән Сарьянны каләм чарларга өйрәнүдә беренче булышчыларым дип таныйм. Казанга килгәч тә беренче танышкан, беренче аралашкан каләм ияләре шулардыр. Шул язда ук Әмирхан ага Еники белән дә якын мөнәсәбәтләр урнаштырылды. Мин аның һәр әсәрен яратып укый идем. 1961нең март ахырларында хәзерге Милли китапханәдә өч язучының яңарак нәшер ителгән әсәрләре турында фикер алышу кичәсе оештырылды. Габдрахман Әпсәләмов белән Фатих Хөсни әсәрләре турында кемнәр чыгыш ясаганлыкны хәзер хәтерләмим. Ә.Еникинең «Йөрәк сере» повесте һәм соңгы елларда язылган хикәяләренә карата фикер әйтүчеләр арасында Сарьян белән мин дә бар идем. Җавап сүзендә дә Әмирхан ага ешрак безнең исемнәрне телгә алды. Сарьян белән якыннанрак аралашып китүебезгә дә шушы кичә сәбәпче булды. «Милләт язмышына, әдәбиятка карата үз фикерең, тормыш тәҗрибәң бар. Син

хикәя язарга өйрәнергә тиешсең», — дип, ул минем күңелне җилкендереп торган иде. Башлангыч ике хикәям яшь язучыларның әдәби үрнәкләрен берләштергән «Яшьлек таңы» җыентыгында 1964 елда, шактый күләмле «Дәгъва» исемлесе ике елдан соң «Кайнар хисләр» китабында басылып чыктылар. Ул китапларның мөхәррирләре дип башка кешеләр күрсәтелсә дә, минем хикәяләрне кабул итүче, корректуралары белән таныштыручы Рәис Даутов булган иде. «Уңышлы башлангыч бу», — дип, күңелне күтәрердәй беренче сүзләрне әйтүче дә ул иде.

– Әллә әдәби тәрҗемә өлкәсендә эшләргә дә ул киңәш иттеме?

— Юк. Әдәби хезмәтнең ул өлкәсенә керешкәнче, инде минем кемдер тарафыннан яртылаш кыскартылган, үзем өчен әһәмиятле саналган «Дәгъва», «Казан көнлекчеләре» исемле күләмле хикәяләрем кертелмәгән «Юлда» китабым да, Орскида яшәү дәверендә үк туплый башлаган «Дала иртәсе» дә дөнья күргәннәр иде. Бервакыт Зәки ага Нури миңа: «Син Казагыстанда дүрт ел укыгансың, андагы кардәшләребезнең горефгадәтләрен бераз беләсең. Безгә алар белән элемтәләрне ныгытасы бар. Берәр әсәрне тәрҗемә итәргә алынмыйсыңмы?» — диде. Уйлап йөргәннең соңында мин аңа казахлар тарихының аерым мизгелләрен дә чагылдырган ике повестьны эшләргә ниятем барлыгын белдердем. Шул рәвешле, Әнвәр Әлимҗановның ике бәяны «Отрар хатирәсе» исеме белән 1974 елда минем тәрҗемәдә басылып чыкты. Аннары инде Саин Моратбәковның (анасы безнең милләттән) берничә әсәрен туплаган «Әрем исе», дүрт авторның бәян һәм хикәяләрен берләштергән «Җәйләүдә» китаплары, үзбәкчә язучы милләттәшебез Әсгать Мохтарның «Чинара» романы, Василь Быковның сугыш вакыйгаларын чагылдырган, СССР Дәүләт бүләгенә лаек булган ике әсәрен берләштергән «Һәйкәл» китаплары татар укучысына ирештерелде. Җәмгысы унике елда унике китап тәрҗемә итеп чыгардым шикелле. Китап нәшриятында мөхәррир булып эшләү елларында тагын йөздән артык китапка минем каләм көче керде дип беләм. Авторларның күпчелеге редактор хезмәтеннән канәгать булганлыкларын белдерәләр иде.

– Хәзер ни дип әйтер идегез: кирәкме бүгенге көндә тәрҗемә әсәрләр? Кирәкме татар әдәбияты башка халыкларга?

— Шәхсән үзем сиксәненче еллар урталарыннан бирле тәрҗемә эшләре белән шөгыльләнмим диярлек. Дөрес, авылдашым, тарихчы галим Җәмил ага Гыйльманов бик үтенеп сорагач, аның Бөек Ватан сугышына багышланган «Без сугышта юлбарыстан көчлебез» китабын тәрҗемә итеп биргән идем. Шуннан соң инде үземнең әсәрләрне туплап чыгаруга өстенлек бирә башладым. 1990 елда Дәрдмәндкә багышланган «Офыктагы рәшәләр» документаль повестена өстәп берничә хикәя һәм очерклар китабын нәшер иттем.Бер әдәбият та башка әдәбиятлар белән аралашмыйча, үз казанында гына кайнап озак яши алмый. Тәрҗемә әдәбият кирәк. Иң әүвәл ул әдәбият сөючеләр — матур әдәбиятны укучылар өчен кирәк. Шул ук вакытта, интернет челтәре эшләп торган бер чорда, тәрҗемә әдәбиятның күләме һәм саны бик чикләнгән булырга тиеш, минемчә. Үрнәк алырдай яки татар әдәбиятында күтәрелмәгән темаларга багышланган әсәрләрне генә

сайлап алу зарур. Ә татар әдәбиятын чит телләргә тәрҗемә итеп бастыруны, киресенчә, арттырырга кирәктер. Безнең чын классикларыбызның сайланма әсәрләрен бүгенге көндә иганәчеләр ярдәменә таянып та, тәрҗемә итеп, дөньяга таратып булыр иде, мөгаен. Шул ук вакытта хөкүмәт тә ул эштән читтә калырга тиеш түгел. Китап сәүдәсе — аз керемле тармак. Андый эшкә һәркем алынмаячак. Ул тармак үз фидакарьләрен, язма мирасны ихластан үз иткән яңа чор Кәримиләрен, Шәрәфләрен, Рәмиев һәм Хөсәеневләрен көтә. Кардәш телле әдәбиятны да онытмыйк. Без бер-беребезгә карата теләктәш тә, терәктәш тә булырга тиешбез.

– Сез озак еллар – 1967-1983 елларда – СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры. Гаять мәшәкатьле, тынгысыз урын: язучыларның тормыш-көнкүрешен кайгыртып, ял итәргә, иҗат итеп кайтырга юлламасын табасы, туган-үлгәнен кайгыртасы... Әдәби сүзнең көче, язучыларның дәрәҗәсе әле бар еллар...

— Әйе, ул вазифаны мин бик теләп һәм тырышып башкардым. Миңа кадәр эшләүчеләрдән фәкать Хәсән Сарьян гына Мәскәү идарәсе белән тыгыз элемтә тота. 1964-1965 еллар аралыгында — бер ел чамасы эшләгән ул. Сөнгатулла Сафиуллин 1955-1967 елларда ул вазифаны башкарса да, СССР Литфонды белән элемтәсе начар була. Үзе үк: «Мин Мәскәүгә бер дә бармадым», — дип әйткән иде. Мин исә Мәскәүдә еш булдым, Литфонд идарәсе хәл итә алмаган мәсьәләләрне чишү өчен, СССР Язучылар берлеге оешмасына мөрәҗәгать иткән чакларым да булды. Мәсәлән, 1967 елның көзендә безнең берлеккә дә машина кирәклеген дәлилләп, УАЗ — фургон автомобилен алуга ирештем. Язучыларга фатир мәсьәләсен дә ярыйсы ук уңышлы хәл иттек ул елларны. Һәр ел саен диярлек СССР Литфонды шул фондтан 30дан алып 100 мең сумгача акча бүлеп бирә иде. Шәһәрнең һәм Татарстан хөкүмәтенең план бүлекләренә хат-юлламалар языла, алар фәлән хәтле сумманы кабул итеп була дигәч, шәһәр башлыгыннан имза — рөхсәт алып чыгасы, аннан соң Татстрой идарәсенең рөхсәтен аласы була иде. Шәһәр башлыгы белән Татстрой җитәкчеләре мине генә кабул итми, күкрәгенә депутат билгесе таккан Зәки Нури яки Гариф Ахунов белән барабыз. Шул рәвешле, 14 имзалы документлар әзер булгач, Мәскәүгә илтеп тапшырасың. Мин эшләгәндә, язучыларга йөздән артык фатир алдык. СССР Литфондыннан фатирлар алу өчен дистә меңәрләп алынган соңгы акча 1983 елда булды. Мин ул эштән киткәч, андый мәшәкатьле эш белән шөгыльләнүче булмады.

– Лирон ага, Ходай Тәгалә Сезне иҗат шатлыгы, олуг хезмәт, кешеләрнең хөрмәте, гаилә бөтенлеге белән бүләкләгән, тормыш иптәшегез Дания апа белән 45 ел матур гомер итәсез (ул да озак еллар Язучылар берлегендә хисапчы вазифасын башкарды), балаларыгызга, үзләре әти-әни булгач та, ата терәге, әти җылысын тоеп яшәрлек озын гомер биргән. Бу, мөгаен, Мирхәйдәр Фәйзи, Дәрдмәндләрнең Сезгә булган рәхмәтедер. «Игелек җирдә ятмый», ди бит халык мәкале. Татар әдәбиятының Сезнең кебек тырыш, фидакарь затлары туплаган, бөртекләп җыйган мирасы кадерләп саклансын иде.

Әңгәмәдәш —
Гөлзадә Бәйрәмова

ГЪИКАБ
[җәза, үч]

МӨХӘММӘТ ӘМИН

Чыкты һиҗрәтдин җиде йөз илледә,
Төште галәмгә хараблык зилзилә [җир тетрәү].
Үзе — аксак, гакълы — ахмак, фетнәдә
Золымыны изһар [җир тетрәү] кылды һәр йирә [һәр җиргә].
Күб гъөләмә вә мөшаихләр [шәехләр] шәһит
Булдылар һәм дин ислам нур илә [нуры белән].
Дарелислам [ислам дөньясы] фетнәсендин, бел гъәйан,
Булды вәйран [җимерелде], акты йәшләр хәүф илә.
Ни җәуаб бирер хода кашыда ул,
Сорса алла шиддәт-ү [катылык] гъикаб илә.
Йа илаһым, әйлә ул бәндәңне сән
Ахирәттә залим-ү җаһил [әшәке, надан] илән.

Кол Шәриф мәчете хәрабәләре. Нияз Хаҗиәхмәтов

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

Рәхмәт, язмыш,
илгә һәм халыкка
әйтер сүзле иттең:
– Мин әйттем!

Мөдәррис Әгъләмов

ҮЗ ХАЛКЫҢНЫ ҮЗ ИТСӘҢ, ЯТ ХАЛЫККА КОЛ БУЛМАССЫҢ*

ГҮЗӘЛ НӘБИУЛЛИНА, ЛИЛИЯ ГЫЙЛӘҖЕВА,
филология фәннәре кандидатлары

Халык белән даулашсаң,
Халыкны каян табарсың?..
«Идегәй» дастаны

Әдип вә галимнәре булмаган кавем — бәхетсез, мәшһүр кемсәләрен оныткан халык — көчсез, әдәбияты булмаган милләт — рухсыз.
Ризаэддин Фәхреддин

Никадәр гаҗәптер ки, бер адәмнең хәленә мәрхәмәт итәрбез дә, бер миллион адәмчә бер милләткә мәрхәмәтебез юктыр.

***

Милли патриотизм исә, — гаҗәеп эшләргә сәбәпче булып, һәр олуг эшләрнең башлангычыдыр.
Муса Акъегет

Иванушка-Абдулкалар теләсәләр ничек уйласыннар, әмма меңьеллык тарихы булган, башкаларныкыннан бер дә калышмаслык кабилияте булган, тырышып, сакланып килгән дине, гадәтләре булган, үзенең язуы, әдәбияты, җыры, көе булган, гасырлар буенча мәктәп һәм мәдрәсәләре булган бер милләтнең бернәрсәсе дә бервакытта да чүпкә чыкмый, чыга алмый! Аны чыгару Иванушка-Абдулкалар кулыннан килә торган эш түгел.

***

Бер милләтнең теленең җуялуы әдәбиятының җуялуы — димәк улып, әдәбиятының җуялуы да рухының бетүе дигән сүздер.
Фатих Әмирхан

Халык — зур ул, көчле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.

***

Караны яз кара дип
һәм игътираф
[үзенең гаебен тану] ит акны ак,
Бакма һич кәс [кеше] хәтренә,
милләтең дәртенә бак.

*Сәхифә «Дөньяда сүзем калыр» (Татарстан китап нәшрияты, 2012 ел) китабы нигезендә даими алып барыла.

***
Бара милләт зәгыйфь,
абыныр-абынмас,
Сүнә яшьләрдә ут,
кабыныр-кабынмас.
Кичә якты вә милли бер
күңелдән
Бүген тычкан утыдай
нур табылмас.

***
Җилбер-җилбер йөрмәс идем,
Җил тавышын сизмәсәм;
Өзлеп такмак әйтмәс идем,
Үз халкымны сөймәсәм.

***
Азмы какканны вә сукканны
күтәрдем мин ятим?!
Азрак үстерде сыйпап тик
маңлаемнан милләтем.

Габдулла Тукай

Халыкка файдалы булган эш үзеңә дә файдалы.

Хөсни Кәрим

Сөй гомерне, сөй халыкны,
сөй халыкның дөньясын,
Без үләрбез, билгеле,
тик үкенечкә калмасын.

Сәгыйть Сүнчәләй

Нинди зур көч — читтә үз-үзеңне
Халкың белән бергә хис итү!

Муса Җәлил

Халыкныкы халыкта саклана.

Әмирхан Еники

Халыктан акыллы кеше булганы юк әле.

Габдрахман Әпсәләмов

Әшәке кешеләр була,
Әшәке халык булмый;
Әшәке тарихчы була,
Әшәке тарих булмый.

***
Суларында балык,
Урманында киек,
Җырын саклап калган
Халык җаны бөек.

Гамил Афзал

Һәр халыкның үз теле, ул телнең үзенә генә хас моңы, матурлыгы була.

Ләбибә Ихсанова

Халыкны халык иткән, дөньяга таныткан сыйфат — аның күңел байлыгы, теле, сәнгате.

Гариф Ахунов

Кеше үлә— халык үлми.

***
Җир йөзендә бары ике нәрсә үлемсездер — истәлек һәм хәтер.

***
Үз халкыңның шанлы тарихына, милләтеңнең казанышларына, кылган мактаулы гамәлләренә кинәнеп яшәү, халкың өчен горурлану — менә ни озын гомерле итә милләтне!

Мөсәгыйт Хәбибуллин

Татарларда сөенеч тә, кайгы-хәсрәт белән авыр шик-шөбһәләр дә өйгә сыймыйлар, борынгы болгар бабайлар, кара кайгы иңгәндә яки салават күпередәй балкып куаныч килгәндә, дөньяга яңа җан иясе— бәбәй туганда, тирмәдән чыккан-нар да, иярсез атка сикереп менеп, җайдак җилдергәннәр, киң Идел ярына басып җырлаганнар, җир сел-кетеп, тыпыр-тыпыр биегәннәр, һич югында, кайгыдан бал эчкәннәр.

Аяз Гыйләҗев

Халык, үзенең телен ясаганда ук, иң газиз әйберләргә ике яки өч кенә аваз сарыф итеп сүз ясаган.

Мөхәммәт Мәһдиев

Күпләргә мәгълүм: татар кайгыны уртаклаша белә, хәлгә керә белә, кирәк чакта ярдәм кулын суза, елаша, кайгырыша. Зыялыларда аеруча калку чагыла бу сыйфат. Әмма татар якыннарының уңышын кичерә алмый. Мизгел эчендә йөз сиксән градуска борыла да куя. Көнчелек — татарның канында. Ул ана сөте белән керә. Шуңа күрә аның тамырын корыту да бик авыр. Ихтимал, мөмкин дә түгелдер.

Марат Әмирханов

Әгәр дә милләтне көчле итеп, бөек итеп күрәсең килә икән, иң беренче булып аның көчен таны, шул милләтнең баласы булуың белән горурлан.

***

Милли чикләнгәнлек дип сөйләнүче татарлар — космополитлар койрыгына ябышкан тигәнәкләр ул.

Туфан Миңнуллин

Көчләп кереп булмый
Халык йөрәгенә.

***

Тураерга биле булса,
Күтәрергә иңе булса,
Авызында теле булса —
Димәк, әле халык исән!

***

Үз милләтеңнең һәр гадәте җанга якын ул.

Фәнис Яруллин

Милләт, никадәр шигъри җанлы, шигърияткә никадәр якын булса, шулкадәр үлемсез, озын гомерле була. Шигърияттән ераклашкан саен, милләт тә мәңгелектән ераклаша, гомере дә кыскара бара. Баласыннан әкияте киткән милләт үлемгә юл ала...

Айдар Хәлим

Татар булсаң, татар бул, дошманыңны ватар бул.

***

Татар-башкорт халкы ул — бер бөркет.

***

Еларга яшь калмагач, татарлар гел елмаеп үлә.

***

Татар бар җирдә хәтәр юк, хәтәр бар җирдә татар бар.

Рабит Батулла

Татар шул тарлыгы белән үзен бетерә.

***

Татар — юаш, басынкы, кайгылы халык. Аңа азат тиз генә килмәс.

Тәлгат Галиуллин

Үз ярмаңны, әйдә, үзең яр,
татар!
Алучы бар, ә бирүче юк сиңа.
Шак-шок шакый тәрәзәңне
бу дөнья —
Гайрәтле чакларыңны сагына.

***

Елгаларның яры икәү була,
Татар өчен, ахры, бер генә:
Ирен чылатасы суларыбыз
Без килгәнче кибеп өлгерә.

***

Ялган булып су төбенә
батасы бар,

Әгәр хаклык өскә
калкып чыкмаса.
Дошман таптар каберләрдә
ятасы бар,
Халкым болай
бер-ике ел йокласа.

Рәшит Әхмәтҗанов

Ул хәлен беләсең килсә —
кешеләр йөзенә кара.
Җир хәлен беләсең килсә —
гөлләр күзенә кара.
Үз хәлең беләсең килсә —
халык сүзенә.

Равил Фәйзуллин

Башка халыкны савып яшәргә күнеккән кавемнең рухы сына, табигате ялкаулана, мие сыеклана да, үзен гали, бөек, асыл кавем дип исәнгери. Тирә-яктагы чынбарлыкны аермас хәлгә килә, ялган бөеклегеннән исереп яши.

Флүс Латыйфи

Йолкынсаң да тамырың калсын,
Тамыр корытучының үзен җил алсын.

***

Көтү акылы, ни дисәң дә, коллектив акыл инде, көтү акылы булган милләтләр җиңеп бара. Кысла, чуртан, аккош арбасы һаман да безгә кала…

***

Кунак ашы кара-каршы: тарихны кеше тудырса, кешене дә тарих тудыра.

***

Татар бай: моңга бай.
Калганы: ай-һай…

Бикә Рәхимова

Үз халкыңнан акыллы итеп күлә белмисең икән — алынма! Мыскыллап, мескенгә калуың бар.

***

Татар егете, рус кызына өйләнәм дип, кияүгә чыга.

***

Яһүд баеса, татар көенми. Татар баеса, татар сөенми.

***

Тел, Моң, Хәтер — рухның таяныч нигезе. Шушы өч бергәлекне таркату өчен, басып кергән илнең иң тәүге дини маягы булып кабынган манараларын аударалар.

Тел — милләтнең җанын сугарып торучы чишмә.

Моң — милләтнең үз-үзенә юаныч бирү, үсендерү дәрте.

Хәтер — үткән зурлыклар иңенә басып, киләчәккә омтылу офыгы.

Өч тармак, өч тамыр, өч кодрәт бергәлеге…

***

Рух — милләтнең фидаи җаны, максатлы омтылышы, үзеннән югарырак сикерә алу мөмкинлеге. Рухи кодрәт ул — бөгелгәндә дә бөгелмәү, егылганда да егылмау, чигенгәндә дә чигенмичә яшәү тантанасы.

***

Гүя үз-үзенә үч итә:
Ничә гасыр буе, чимал булып,
Төрле кавемнәрне үрчетә.

Марсель Галиев

Җаным — татар, илем — урыс...
Илдус Гыйләҗев

Гасырлардан килгән хәтер ул — моң,
Безнең хәтер, татар хәтере.
Роберт Миңнуллин

Астрологлар фани дөньяда яшәүче бар халыкны, инкубатор чебешләре ише санап, унике йолдыз астына бүләргә тырышалар. Унике төрле язмыш вәгъдә ителәә, унике ассортиментлы бәхет, унике канатлы өмет һәм унике төрле яңалык! Йолдызнамәләрне язсалар да, бары тик унике халыкка гына бүләргә тиешләр. Җир йөзендә чама белән алты миллиард кеше яши дип исәпләсәк, шуны унике йолдызлыкка бүләсе бар... Шулай итеп, астрологларның күк капусындагы йолдызнамәнең һәр йолдызына 500 миллион кеше туры килә. Ә бу инде — үзегез беләсез— уртак бәхетле, уртак өметле һәм бертөрле язмышлы 500 миллион кеше дигән сүз!
Камил Кәримов

Үзе богаулы,
үзе чыбыркы тотар —
бусы булыр чын татар.
Акъегет

Милләтеңә мәхәббәт хисләреннән дә бигрәк, аның белән горурлану хисләре өстә тору фарыз.

***

Үрчү-тудыруның төп чыганагы булган хатын-кыз — милли байлык... Аның физик тазалыгы, әхлагы, җисеме һәм рухи сафлыгы дәүләт-милләт кайгыртуында, һәркемнең кайгыртуында булырга тиеш...

***

Акылсызлыкны һәм бозыклыкны «тауар хәленә җиткереп», табыш һәм керем исәбенә яшәгән милләтне, халыкны, дәүләтне Аллаһ каргышы барыбер тота...

***

Милли үзаң — бөтен бер халыкның үз-үзенә читтән карый ала белүе... Киләчәккә бару өчен, үз аты, үз арбасы һәм иң мөһиме — үз юлын таба белүе... һәм югалтмавы...

***

Милләт һәм милләтләрнең атасы юк — баласы гына бар.

***

Милли мескенлек — телсез калу. Тел булмагач, ишеткәнне, күргәнне, белгәнне дә әйтеп булмый. Кирәкне сорап, булганны биреп булмый... Телсезлек — бөтенләй бетү билгесе.

***

Илен җуйган, телен җуйган халык мәңге бәхетсез.

***

Илсез милләт — телсез халык.
Мескенрәк кем бар тагы?

***

Чит кавемгә, чит милләт кешесенә кияүгә кыз бирү — аларның милләтен үрчетү, көчәйтү, куәтләндерү.

***

Милләт «ихтыяҗы» дигән пәрдәгә ышыкланып, керем артыннан куган, шөһрәт артыннан куган кемсә — милләткә иң күп зыян салучы.

***

Дәүләтле халыкның гына тарихы бар…

***

Дәүләтен җуйган милләтнең үзаңы зәгыйфь, диненнән язган милләтнең үзаңы бөтенләй юк.

***

Милләтеңне яклап бер сүз әйталмасаң әйтмә, әмма аны һичбер хурлама.

Мөхәммәт Мирза

Елгаларны ансат буып була, ә халыкның авызын томалап булмый бит ул.

***

Халык күтәргән кешене җиргә ташлау авыр ул.

Вахит Имамов

Үксез халык буламыни —
Тарихыңны җуймасаң.
Сүзсез халык буламыни —
Телне тегеп куймасаң?!

Факил Сафин

Халыкка күсәк күтәрмә, хаклыкның башын ярырсың.

Нәбирә Гыйматдинова

Булмаса халыкның
Әгәр дә үз Иле,
Илбасар телендә
Җыр язар шагыйре.

***

Татар, дигәч, Иблис тә алтатарга үрелә, ди.

Газинур Морат

Татар, нәрсәне булса да аңламаса, бу милли түгел, безгә хас түгел һәм моңа мохтаҗлыгыбыз юк, дияр.

***

Сез һәрвакыт нәтиҗә белән сәбәпне бутыйсыз. Тормыш начар булганга күрә, халык шундый, дисез. Дөрес түгел. Киресенчә, халык шундый булганга, тормыш начар!

Зөлфәт Хәким

Коллар без — үзара хан булып кыланабыз,
Үзебез ятлардан телебезне теләнәбез.

Ркаил Зәйдулла

Үзе теләп бетә бара халык.

***

Татар нигә берсен берсе ашый?—
Ике татар өчкә бүленә?!

Нур Әхмәдиев

«Алтын куллы», «алтын йөрәкле» дигән исем алучы милләттәшләребез арасында милләт үсеше өчен алты тиенлек өлеш кертмәүчеләр дә бар.

***

Хисләр белән тулы, кыерсытылган татар күңелендә һәрчак бер өмет уты янды — ул бәйсез татар дәүләте төзү. Чөнки аңа чаклы ирексезләп тагылган «ватан» кышлар кебек салкын, күзләр кебек көйсез, ташлар кебек җансыз иде.

Нурулла Гариф

Нишлисең, мескен халыкның язучылары бәхетле була алмый.

Марат Кәбиров

Гомер буе «Халкым!» диеп
Янып-көеп яшә дә,
Синең исемең тирбәлер
Рәшәдә…

Ленар Шәех

ЯҢА КИТАПЛАР

ФАТИХ ӘМИРХАН: ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕ, ИСТӘЛЕКЛӘР, ӘСӘРЛӘР, АНАЛИЗ ҮРНӘКЛӘРЕ, ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕ

/ Проект авторы һәм төз. Т.Р.Шакирова. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. — 247 б. — Тиражы 4 000 данә.

Китап Фатих Әмирханның юбилеена — тууына 125 ел тулуга багышлап әзерләнгән. Ул язучы һәм аның иҗаты хакында шактый тулы һәм кызыклы мәгълүматларны үз эченә ала.

XX йөз башы татар әдәбиятында яңарышны әйдәп барган, үз алдына милли әдәбиятны үзгәртү, Европа әдәбиятлары баскычына күтәрү максатын куйган Фатих Әмирхан тормышы белән дә, иҗаты белән дә милли мәдәнияттә аерым урын тота. Зыялы, укымышлы егетнең аяксыз калып, гомерен коляскада уздырырга мәҗбүр булуы, ләкин язмышы белән килешмичә, әдәбият, публицистика, журналистика, әдәбият белеме, тәнкыйть, мәктәп-мәдрәсәләрдә укыту методикасы кебек күп өлкәләрдә зур эшләр башкаруы, матур нәтиҗәләргә ирешүе үзе үк гражданлык батырлыгы үрнәге булып тора. Ә инде әдәби иҗатына килсәк, «Хәят» повестеннан, милли әдәбиятыбызда беренче фантастик әсәрләрдән булган «Фәтхулла хәзрәт» повестеннан, яки авторның «Кадерле минутлар», «Бер хәрабәдә», «Ул үксез бала шул!» кебек хикәяләреннән, инкыйлабтан соңгы әдәби барышта илдәге үзгәрешләрне тәнкыйтьләп, алардан көлеп иҗат ителгән «Шәфигулла агай» повестеннан, яңа татар драмасы үрнәкләре — пьесаларыннан башка татар әдәбияты тарихын бәяләргә, тикшерергә, хәтта күз алдына китерергә мөмкин түгел.

Укучы игътибарына тәкъдим ителгән китап күптөрле материалларны бергә туплап эшләнгән. Монда Ф.Әмирханның тәрҗемәи хәле дә, Р.Г.Әмирханов төзегән нәселнең шәҗәрә агачы да, аның хакында истәлекләр дә җыйналган. Шулай ук әсәрләре: җиде хикәясе, «Хәят», «Шәфигулла

агай», «Фәтхулла хәзрәт» повестьлары туплап бирелгән. Күпсанлы бай фотоматериаллар арасында Фатих туган йорт сурәте, Әмирханның дуслары, аның белән бәйле кешеләр фотосурәтләре бар.

Китапта Ф.Әмирхан иҗатына гомуми күзәтү һәм аерым әсәрләренә анализ үрнәкләре чагылыш тапкан. Шулай ук дәрес эшкәртмәләре бигрәк тә укытучылар өчен файдалы булыр.

Гомумән, китапның эшләнеше, бизәлеше аерым бер игътибарга лаек: битләрнең эпиграфлар, аңлатмалар, төгәлләштерүләр рәвешендә бүленгән икенче ягы текстларны кабул итү, файдалану эшен җиңеләйтә. Бу китап эшчәнлекләре белем-тәрбия бирү белән бәйле кешеләр өчен менә дигән ярдәмлек булыр дип уйлыйбыз.

МУХАМЕДЬЯРОВ Ш.Ф.
СОЦИАЛЬНО-ЭКОНОМИЧЕСКИЙ И ГОСУДАРСТВЕННЫЙ СТРОЙ КАЗАНСКОГО ХАНСТВА (XV – ПЕРВАЯ ПОЛОВИНА XVI ВВ.). — Казань: Изд-во «Ихлас», Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2012. — 276 с.+ 4 с. вкл. — Тираж 500 экз.

Күренекле татар тарихчысы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, тарих фәннәре кандидаты, 170тән артык фәнни хезмәт авторы Шамил Фатыйх улы Мөхәммәдьяровның (1923-2005) бу китабында 1951 елда Мәскәүдә уңышлы яклаган шул ук исемдәге кандидатлык диссертациясе бирелгән.

Керештән тыш китап алты бүлекне берләштерә. Автор I бүлекне урта гасыр тарихи чыганакларын тикшерүгә багышлаган. Ш.Ф.Мөхәммәдьяров ул заманда билгеле булган барлык төр чыганакларга да аларның тарихи кыйммәтен ачыклап бәя бирә.

«Казан ханлыгының хуҗалыгы» исемле II бүлектә тарихи чыганакларда ханлыктагы хуҗалык тармаклары турындагы мәгълүматларга тәнкыйди бәя бирелә. Китапның Казан ханлыгында җир биләү системасы турында фикерләре зур игътибарга лаек. Биредә автор шулай ук игенчелектә кулланылган хезмәт кораллары, игенче хуҗалыгында бакчачылык, умарта тоту, аучылык, балык үрчетү тармакларының урыннарын билгели.

Фәнни яктан иң әһәмиятле бүлекләрнең берсе булган «Феодал җир биләү» дип аталган III бүлектә автор,

Сафагәрәй ханның 1523 елда Шәех Әхмәткә, аның туганнарына тарханлык хокукы биргән ярлыгы һәм 1565-1568 елгы Писцовая кенәгә язмаларын анализлап, фәндә яңа фикерләр әйтә. Биредә ханлыктагы җир биләү системасы берничә төргә бүленеп карала һәм һәрберсенең төп сыйфатлары аерып чыгарыла. Алар — ханның биләмәләре, эре феодал җир биләүчеләрнең утарлары, төп җирбиләүчелек формасы булган сөергал система.

IV бүлектә сүз ханлыкның төп халкы булган игенчеләр хуҗалыгы һәм аларның хокукый хәле турында бара. Бу фәнни мәсьәләне галим Казан ханлыгында ни өчен крепостное право булмаган дигән сорауга җавап бирүдән башлый. Игенчеләрнең (крестьяннарның) җир биләү үзенчәлекләре, дәүләт файдасына алар башкара торган йөкләмәләр һәм түләгән салымнар турында фикерләре аеруча кызыклы.

«Казан ханлыгында һөнәрчелек һәм сәүдә» темасы китапның V бүлегендә ачыла. Автор тарафыннан татар феодал шәһәренә бәя бирелә, ханлыкның башкаласы булган Казанда алыш-биреш һәм товар җитештерү үзенчәлекләре яктыртыла, эчке һәм тышкы сәүдәнең төп юнәлешләре һәм динамикасы, ил икътисадына транзит халыкара сәүдәнең йогынтысы, бу өлкәдә Бөек Мәскәү кенәзлегенең роле һ.б. турында сөйләнелә. Ханлыктагы һәнәрчелекнең торышы хакында Ш.Ф.Мөхәммәдьяров күбрәк археологик табышлар, матди чыганаклар нигезендә фикер йөртә.

Китапның соңгы, VI бүлеге Казан ханлыгының сәяси төзелешенә багышланган. Автор бу теманың кыскача историографиясен яктыртканнан соң, ханлыкның оешу мәсьәләсен, дәүләтнең югары хакимият һәм югары идарә органнарын, җирле хакимият һәм идарә институтларын тасвирлый.

Казан ханлыгы тарихы белән кызыксынучылар өчен Ш.Ф.Мөхәммәдьяров тарафыннан төзелгән һәм китапка кушымта итеп бирелгән «Хәзерге ТАССР территориясендә болгар археологик истәлекләре», «ТАССР җирләрендә болгар-татар ташбилгеләренең таралышы», «Казан ханлыгының үзәк өлеше» исемле карта-схемалар, 1523 елгы Сәхибгәрәй ярлыгының татарча һәм русчага тәрҗемә текстлары да укучы өчен кызыклы булыр дип уйлыйбыз.

Язылганына инде ярты гасырдан артык вакыт үтеп, текстта марксистик-ленинчыл идеология йогынтысы тоелса да һәм кайбер тарихи күренешләр, фактлар сыйнфый көрәш концепциясенә нигезләнеп бәяләнсә дә, талантлы тарихчының бу хезмәте үзенең фәнни әһәмиятен җуймаган.

Илдус Заһидуллин,
тарих фәннәре докторы

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

5 СЕНТЯБРЬ КӨННЕ АЛТАЙ КРАЕ БАШКАЛАСЫ БАРНАУЛ ШӘҺӘРЕНДӘ, АЛТАЙ ДӘҮЛӘТ УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ГЫЙЛЬМИ СОВЕТЫ ЗАЛЫНДА, БЕРЬЮЛЫ ӨЧ ЗУР ФӘННИ ҖЫЕН ЭШЕН БАШЛАДЫ: ЕВРАЗИЯ ДАЛАЛАРЫ АРХЕОЛОГИЯСЕНЕҢ II ХАЛЫКАРА КОНГРЕССЫ, III БОЛГАР ФОРУМЫ ҺӘМ II «ИДЕЛ-АЛТАЙ» ФОРУМЫ.

Фәнни җыеннарны оештыручылар Алтай дәүләт университеты, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты һәм Казан (Идел буе) федераль университеты иде.

Фәнни җыеннарның ачылышында котлау сүзләре белән Алтай крае губернаторы урынбасары Ю.Н.Денисов, Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе М.Ш.Шәймиев, Алтай дәүләт университеты ректоры С.В.Землюков, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Р.С.Хәкимов һәм Казан (Идел буе) федераль университетының Тарих институты директоры Р.Р.Хәйретдинов чыгыш ясадылар. Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе М.Ш.Шәймиевкә Алтай дәүләт университеты шәрәфле докторы исеме бирелде; профессорлар Н.Н.Крадин, Ф.Ш.Хуҗин и И.Фодор докладлары зур игътибар белән тыңланды.

Тәнәфестә университетның «Universum» галереясында археологик табышлардан торган «Урта гасырлар Алтае» дип аталган күргәзмә ачылды.

Пленар утырыш тәмамланганнан соң, галимнәр 6-7 сентябрь көннәрендә Алтай Республикасы чигендә урнашкан «Стик-Тревел» туристлык комплексында уздырылган сессияләрдә докладлар белән чыгыш ясадылар.

«Дала социумының үзенчәлекләре: антропология һәм мәдәният», «Төрки чорга кадәр һәм төрки чорда Евразия далаларында мәдәни берлекләр оешу», «Евразия далаларында этномәдәни бәйләнешләр», «Евразиянең дала өлешендә иртә һәм җитлеккән урта гасырлар чорында хәрби эш», «Евразиянең дала өлешендә X-XIII гасырларда шәһәр мәдәнияте, сәүдә юллары», «Евразиянең дала өлешендә яшәгән халыклар дөнья мәдәнияте контекстында» дип аталган секцияләрдә докладлар ясалды, бу өлкәләрдә соңгы вакытлардагы ачышлар турында сөйләнде, фикер алышулар булды.

8 сентябрь көнне галимнәр Алтай Республикасындагы борынгы тарихи һәйкәлләр белән танышты.

Чит ил археология мәктәпләреннән Кытай, Япония, Болгария, Молдавия, Украина, Белоруссия, Венгрия, Польша галимнәре бар иде. Россиянең археология фәнни үзәкләре Казан, Чиләбе, Мәскәү, Самара, Уфа, Кемерово, Владивосток, Горно-Алтайск, Иркутск, Томск һ.б. шәһәрләрдән килгән вәкилләрдән гыйбарәт булды.

Форумда киләчәктә күчмәннәр җәмгыятьләрен өйрәнүче һәм төрле илләрдә яшәүче галимнәрнең очрашу-аралашуларын җайга салу турында да эшлекле сөйләшү булды.

5-11 СЕНТЯБРЬДӘ КАЗАНДА ХАЛЫКАРА VIII МӨСЕЛМАН КИНОФЕСТИВАЛЕ БУЛЫП УЗДЫ.

Билгеле булганча, быел фильмнарны Мәскәүдән килгән комиссия сайлап алды. Аның составында танылган сценарист Гаделша Агишев, «Россия» телеканалындагы «Мусульмане» программасы режиссёры һәм җитәкчесе Василий Антипов һәм Россиянең кино белгечләре һәм кино тәнкыйтьчеләре гильдиясе Эксперт советы әгъзасы Светлана Хохрякова бар иде. Сайлап алу комиссиясе хөкеменә 55 илдән 300дән артык фильм җибәрелде. Нәтиҗәдә, 20 илдән тулы һәм кыска метражлы документаль фильмнар, тулы метражлы нәфис фильмнар) 40 фильм гына сайлап алынды. Шулай итеп, агымдагы елның фестиваль фильмнарын Һиндстан, Төркия, Иран, Казахстан, Кыргызстан, Финляндия, Польша, Бәхрәйн, Венесуэла, Занзибар, Берләшкән Гәрәп Әмирлекләре, Россия, Татарстан һ.б тәкъдим итә. Сицилия, Йәмән һәм Монтенегро форумда беренче тапкыр катнаша. Казаннан фестиваль программасына Фәрит Дәүләтшинның «Эт» исемле тулы метражлы нәфис фильмы, Илдар Ягъфәровның «Югалган» исемле кыска метражлы нәфис фильмы һәм Сергей Яковлевның «Проломнаядагы аптека» исемле кыска метражлы документаль фильмы кертелде.

Фестивальдә «Иң яхшы анимацион фильм» дип — Россиядән «Яшәгән ди, булган ди әни» фильмы (режиссёры Анна Артемьева), «Иң яхшы кыска метражлы нәфис фильм» дип — «ЦИА йорты» фильмы һәм Ираннан «Яңгыр тавышы» фильмы; «Иң яхшы тулы метражлы документаль фильм» дип — «Занзибарның музыка клубы» фильмы, «Иң яхшы кыска метражлы документаль фильм» дип Кыргызстаннан «Бәхет бишеге» фильмнары табылды.

«Тулы метражлы нәфис фильмның иң яхшы сценарий өчен» бүләккә — «Әбү, Адәм улы» фильмы өчен Һиндстаннан Сәлим Әхмәд; «Тулы метражлы нәфис фильмның иң яхшы оператор эше өчен» бүләккә — «Бер шакмак шикәр» фильмы өчен Ираннан Хәмид Хаҗи Әбү Әмир; «Тулы метражлы нәфис фильмда иң яхшы ир-ат роле өчен» бүләккә — Төркиядән «Яшерен тормыш» фильмында уйнаган Әхмәд Ментас Тайлан; «Тулы метражлы нәфис фильмда иң яхшы хатын-кыз роле өчен» призына «Бер шакмак шикәр» фильмы өчен Ираннан хатын-кыз актерлар ансамбле лаек булды.

ТР Президентының «Кино сәнгатендә гуманлылык өчен» махсус призы шулай ук Иранга китте. Ул «Сечкан» һәм «Шаяннар» кыска метражлы документаль фильмнары өчен режиссёр Мөхәммәд Гали Хазхемзехига тапшырылды. «ТЮРКСОЙ» халыкара төрки мәдәният оешмасының махсус бүләге — татар мультфильмнарын эшләүче рәссам Сергей Киатровка, фестивальнең генераль иганәчесе призы — тамашачы призы «Югалган» (реж. Илдар Ягъфәров, Россия, Татарстан) фильмы өчен бирелде. Шулай ук Россиядән тәкъдим ителгән «Команда» фильмы (Казанның «Рубин» футбол командасы турында) һәм Татарстаннан «Проломнаядагы аптека» фильмы фестивальнең махсус призларына лаек булды.

Быел фестиваль тарихында беренче тапкыр фестивальнең партнёрыннан иң яхшы нәфис фильм өчен 150 мең сум күләмендә акчалата приз тапшырылды. «Антика» төзелеш фирмасы бу бүләккә Ираннан «Бер шакмак шикәр» фильмын лаек дип тапкан. Иран быелгы кинофорумга барлыгы 80ләп фильм тәкъдим иткән.



1552 елда Казан шәһәрен камап алу. Айрат Ситдыйков реконструкциясе

Индекс 54132